Безнең МИРАС
НАШЕ НАСЛЕДИЕ
11
ноябрь 2019
ISSN:2500-011X
ФӘННИ-ПОПУЛЯР, ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ДОКУМЕНТАЛЬ ЖУРНАЛ

СӘҮДӘГӘР ӘХМӘДУЛЛА ӘХМӘТОВ ЙОРТЫНЫҢ ТӘРӘЗӘ ЙӨЗЛЕКЛӘРЕ. ТОМСК ШӘҺӘРЕ

# Башкортстан сәфәре

10-12 октябрь көннәрендә татар зыялылары Туймазы һәм Уфа шәһәрләренә сәяхәт кылды. Сәфәр Башкортстанның 100 еллыгы һәм тарихыбызда тирән эз калдырган күренекле шәхесләрнең юбилейлары уңаеннан, Бөтендөнья татар конгрессы ярдәме һәм Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин җитәкчелегендә оештырылды.

Фоторепортажны **beznenmiras.ru** сайтыннан карарга мөмкин.

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар – гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.

Дәрдемәнд


Безнең Мирас 12 +

11 (311)

**ноябрь 2019**

1991 елның апреленнән башлап «Мирас», 2012 елның маеннан, «ТАТМЕДИА» АҖ тарафыннан кабат гамәлгә куелып, «Чын мирас» исемнәре белән чыкты. 2014 елның маеннан «Безнең мирас» итеп үзгәртелде.


21

46 **ЕКАТЕРИНБУРГТАГЫ «ТАТАР КВАРТАЛЫ» ҺӘМ СӘҮДӘГӘР АГАФУРОВЛАР.** *Лариса Коновалова*

94 **ГОМӘР БӘШИРОВ КӨНДӘЛЕГЕННӘН**

# ЭЧТӘЛЕК


ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР...

3 **Дәрдемәнд**

ТАРИХИ МИРАС

4 **Этрусклар – Рим остазлары.** *С.Шәмси*
12 **Татар бистәләренең шанлы тарихы**
13 **Йорт-Орыдагы чат татарлары музее**
16 **«Алты авыл» татарлары һәм бертуган Хәмитовлар.** *И.Биккинин*
21 **Томск йомышлы татарлары Кузнецск крепосте төзелешендә.** *Ә.Аширов*
26 **Сембердәге татар бистәсе.** *Р.Вилданова*
32 **«Сибирия» газетасында Томск шәһәре татарлары тормышы.** *Р.Шәрәфиева, Л.Гобәйдуллин*
39 **Томскида татар театры тарихы.** *Н.Савельева*
42 **Челтәрле дә бизәкле**
46 **Екатеринбургтагы «татар кварталы» һәм сәүдәгәр Агафуровлар.** *Л.Коновалова*
53 **Екатеринбургтагы борынгы татар зираты**

ТАТАР ГАМЕ

56 **Көрәшчеләр.** *Р.Сәгъди*
64 **Фәрит Мадьяров шигырьләре**
65 **Өстәлемдәге китап – тарих ядкаре.** *Х.Габидуллина*

ДИНИ МИРАС

67 **Ислам дөньясы.** *Габдерәшит Ибраһимов*

ӘДӘБИ МИРАС

72 **Күл – күз яше.** *С.Сүнчәләй*
77 **Дәрдемәнднең барланмаган иҗат үрнәге.** *Л.Хәмидуллин*
81 **Абакамның көтепханәсе**
83 **Хөсәен Мирза.** *Ф.Бурнаш*
88 **Сириннең публицистик поэмасы.** *Ә.Шәрипов*
90 **Халыкара сугышка каршы Конгресста Сириннең сөйләгән беренче речe.** *Сирин*

Баш мөхәррир
**Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ**
**(Ләбиб Лерон)**
(843) 222-09-83 (17-92)

Баш мөхәррир урынбасары
**Фирдәвес Зарифуллин**
(843) 222-09-83 (17-93)

Киңәшче идарә
**Ирада Әюпова**
*(ТРның мәдәният министры)*
**Айрат Зарипов**
*(ТР Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе)*
**Андрей Кузьмин**
*(«ТАТМЕДИА» АҖ генераль директоры)*
**Рөстәм Мөхәммәдиев**
*(«Татнефть» ААҖ генераль директоры урынбасары, «Рухият» фонды рәисе)*
**Айдар Сәлимгәрәев**
*(Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча Республика агентлыгы җитәкчесе)*
**Васил Шәйхразиев**
*(ТР премьер-министры урынбасары, БТК Милли Шурасы рәисе)*

Редколлегия
**Ислам Әхмәтҗанов**
**Марсель Әхмәтҗанов**
**Альберт Борһанов**
**Разил Вәлиев**
**Рәдиф Җамалетдинов**
**Фәнзилә Җәүһәрова**
**Ринат Закиров**
**Фәйзелхак Ислаев**
**Зиннур Мансуров**
**Ким Миңнуллин**
**Гөлчәчәк Нәҗипова**
**Данил Салихов**
**Сөмбел Таишева**
**Рафаил Хәкимов**
**Ирек Шәрипов**
**Лотфулла Шәфигуллин**

Җаваплы мөхәррир
**Ленар Гобәйдуллин**
89196911406

Дизайнер һәм биткә салучы
**Диләрә Нәүрүзова**
(843) 222-09-83 (17-93)

Корректор
**Дания Фәйзуллина**
(843) 222-09-83 (17-93)

Бүлек мөхәррире
**Ләйсән Данилова**
(843) 222-09-83 (17-92)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре,
Декабристлар урамы, 2 нче йорт
Электрон почта:
**yanamiras@mail.ru**

**«Безнең мирас» (Наше наследие)**
**Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал (на татарском языке)**

## ОЧТЫ ДӨНЬЯ ЧИТЛЕГЕННӘН

94 **Гомәр Бәширов көндәлегеннән**

## ХӘТЕР САНДЫГЫ

96 **Дин кушканча яшәде.** *Н.Гыйләҗева*
100 **Сурәтле хатирә.** *Ә.Фәйзрахманов*
102 **Истә, һаман да истә!**
104 **Мәктәпләр һәм сабакташлар.** *Л.Лерон*

## СӘНГАТИ МИРАС

109 **Борынгы татар милли музыка уен кораллары.** *Р.Гыйләҗев*
112 **Тукайга якынаю юлында.** *Ә.Зарипов*

116 **«Безнең мирас» хәбәрләре**
118 **Мирасворд**
119 **«Безнең мирас» елъязмасы.** *Ноябрь*

Заказ №О-2897. Тираж – 2800 данә. Формат 70х108 1/16.
Басарга кул куелды: 23.10.2019.
Чыгу көне: 30.10.2019.
Журнал айга бер тапкыр чыга. Бәясе ирекле.

Журнал 2012 елның 17 апрелендә Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ПИ №ФС77-57844 нче таныклык белән теркәлде.

**Чыганак-текстларда авторларның стиле, шул чор лексикасы һәм орфографиясе саклана.**
Мәкалә авторларының фикере редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин. Редакциягә юлланган язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә. Журналга кергән язмаларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.
Типография гаебе белән киткән хаталар өчен редакция җавап бирми.
Андый хаталар булса, техник контроль бүлегенә 519-44-61
телефоны белән хәбәр итә аласыз.

Бу санда Л.Гобәйдуллин, Л.Лерон төшергән, авторлардан һәм «Татар-информ»нан, Татарстан Милли музееннан, «Татар энциклопедиясе» томнарыннан, Кукмара туган якны өйрәнү музееннан алынган фотосурәтләр, җиде томлык «Татар тарихы»ннан рәсемнәр файдаланылды.

**«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.**

Тышлыкның 1 нче битендә – **Сәүдәгәр Әхмәдулла Әхмәтов йортының тәрәзә йөзлекләре. Томск шәһәре, Татар урамы, 46 нчы йорт. 1902 ел.**
Ленар Гобәйдуллин фотосы

Безнең мирас №11 ноябрь 2019

# ДӘРДЕМӘНД
*(23.11.1859 - 09.10.1921)*

***

Гөрләгән сулар башында,
Тыңлагыз, шунда үтәр –
Йөрсә сыктап таң-сәхәрләр
Моң-сагышлардан хыял.
И, туган илнең һавасы,
Рәнҗемә, зинһар, кутәр!
Рәнҗемә, зинһар, кутәр!

Ни газизрәк – бу ватанмы?
Аһ, туган каумем газиз!
Ул мөкаддәс кан белән ул
Изге сөткә ни җитәр!..
Сөт калыр, ватан китәр!
Сөт калыр, ватан китәр!

***

Мөгзе бар куйның бары да кучкар түгел,
Очкан кошның барысы да шоңкар түгел.
Кемнәр әйтмәс шигырьне, әйтер берүк,
Чуканлаган аксак ишәк тулпар түгел. ■

Безнең мирас №11 ноябрь 2019

# ЭТРУСКЛАР – РИМ ОСТАЗЛАРЫ*

Солтан Шәмси

### ЭТРУСКЛАРНЫҢ УНИКЕ ШӘҺӘР-ДӘҮЛӘТ КОНФЕДЕРАЦИЯСЕ

Этрускларда беркайчан да бер үзәктән идарә ителгән дәүләт булмаган. Бу халыкның яртысы Кече Азиядәге Лидия дәүләтеннән корабларга төялеп бәхет эзләргә Урта диңгезгә чыгып китә. (Аларның ни сәбәпле үз ватаннарын ташлап читкә чыгып китүен алдагы бүлекләрдә аңлатып үткән идек). Этрускларга, яңа ватаннарын тапканчы, Урта диңгез буенча шактый җирләр-илләр кичәргә туры килә. Һәм, ниһаять, алар Италиянең көнбатышындагы бер өлкәгә килеп урнашалар. Хәзерге көндә этрусклар (тирреннар) килеп урнашкан җир Тоскана өлкәсе дип атала. Лидия патшасының Тиррен атлы улы җитәкчелегендәге бу халыкның корабларда Лидиядән туп-туры Италиягә килеп урнашуы галимнәрнең күбесендә күп сораулар һәм шик уята. Чыннан да, Кече Азия белән Италиянең көнбатыш ярлары бер-берсеннән бик ерак араларда тора. Бу юлны үтү өчен, тирреннарга (этрускларга) әүвәл Эгей диңгезеннән чыгарга, Борынгы Грецияне әйләнеп узарга туры килгән. Италиягә килеп җиткәч тә алар анда тукталып кала алмаганнар, чөнки Италиянең көньягында да, Сицилия утравында да грек колонистлары һәм җирле халыклар, кабиләләр яшәгән. Күрәсең, алар Италия белән Сицилия утравы арасындагы тар Мессина бугазы аша үтмәгән, юкса, бу зур вакыйга антик чор грек чыганакларында чагылыш тапмыйча калмас иде. Тирреннарга Сицилия утравын көньяктан әйләнеп узарга туры килгәндер, күрәсең. Кайбер галимнәр соңрак чорда этрусклар буларак дөньяга танылган тирреннар, Италиягә килеп урнашканчы, күпмедер заманнар Сардиния һәм Корсика утрауларында яшәгәннәр, дигән фикердә торалар. Моны археологлар да раслый. Чыннан да, тирреннарның Италиянең көнбатышындагы яңа ватаннары Этрурия җирләренә турыдан-туры килеп урнашуы күп сораулар тудыра. Алар башта Сардиния һәм Корсика утрауларында күпмедер вакыт яшәп, тирә-юньдәге вазгыятьне, нинди халыкларның кайда яшәвен ныклап өйрәнергә, килеп төпләнерлек буш җирләр булу-булмавын ачыкларга тиеш булгандыр. Мондый эш бервакытта да барысын ачыкламыйча, уптым-илаһи гына башкарылмый. Алар бит вакытлыча яшәү өчен җир эзләмәгән, яңа ватан-дәүләт кору өчен табигать шартлары уңайлы, елга-сулары, урманнары булган ил эзләгән. Һәм Италиянең урта бер җирендә

---

Дәвамы. Башы журналның 7 нче (2019) санында.

*Фәнни-популяр тарихи бәян.



Этрускларның сәүдә корабы

алар үзләренә кулай бер өлкәне эзләп тапкан һәм шунда килеп төпләнгән. Әмма этрускларга кадәр Италиягә тугандаш халык пеласклар да килеп урнашкан булган. Этрускларны греклар элекке гадәт буенча һаман тирреннар дип атасалар да, җирле кабиләләр аларны «тусклар» дип атый башлаган. Шуннан этруск атамасы килеп чыккан. Шулай Италиядә тиздән югары мәдәнияткә ирешәчәк, үзенчәлекле гүзәл цивилизация төзиячәк Этрурия дигән ил барлыкка килгән.

Этрускларның күршесендә сабалар, умбрлар, латиннар, фалисклар, италиклар, самнитлар, пиценнар, лигурлар һ.б. кабиләләр яшәгән. Шунысы кызык, этрусклар яңа җирләргә килеп урнашканда, күрше кабиләләр белән каршылыклар чыгып, бәрелешләр булдымы икән? Этрускларга иң якын торган кабиләләр умбрлар һәм Тибр елгасының икенче ягында урнашкан сабалар белән латиннар була. Әмма ике арада бәрелешләр булу-булмавы турында тарихта теркәлгән хәбәрләр юк. Шулай да этрускларның төньяктагы Арно белән көньяктагы Тибр елгалары арасына килеп урнашуы тыныч шартларда узган булса кирәк. Бәлки, ут күршеләре, килеп урнашучыларның мәдәни һәм хәрби яктан үзләреннән өстен булуын күреп, аларга каршы корал күтәрүдән тыелып калганнардыр. Ничек кенә булмасын, этрусклар б.э.к. IX-VIII гасырларда бу җирләргә килеп урнаша һәм яңа ватаннарында үз тормышларын үзләренчә кора башлый.

Табигый, яңа Ватанда әүвәл авыллар барлыкка килә. Халык игенчелек, терлек асрау, йөзем үстерү, бакчачылык белән шөгыльләнә. Этруриянең кайбер җирләре тормыш алып бару өчен бик уңайлы булса да, аерым өлкәләрдә коры калкулыклар арасындагы үзәннәрдә бизгәк авыруы тараткан черкиләр белән мыжгып торган сазлыклар җәелеп яткан. Илнең көньягындагы җирләр кайчандыр аткан вулканнардан барлыкка килгән туф катнаш туфрак хасил иткән. Андый туфракны эшкәртү, иген игү шактый кыенга туры килгән. Этрусклар, яңа ватаннарында тормыш кору өчен, канаулар казып, сазлыкларны киптерәләр, зур көч куеп, җайсыз җирләрне рәткә китерәләр. Әлбәттә, бу эшләр озак елларга сузылган.

Безнең мирас №11 ноябрь 2019

Халыкның күпчелек өлеше иген игү белән шөгыльләнә. Җирләр аксөякләр кулында була. Ул заманда Этруриядә ике катлам – җир биләүче аксөякләр һәм аларга хезмәт итүче халык кына билгеле. Сәүдә итеп көн күрүчеләр, металлургия белән шөгыльләнүчеләр соңрак барлыкка килә. Гади авыл кешеләре җир эшкәртә, иген игә, терлек асрый, ә кирәк чакта, кулларына корал тотып, төрле сугыш-бәрелешләрдә катнаша.

Этрусклар бодай, борай, арпа, солы, җитен, йөзем үстерәләр, яхшы сыйфатлы шәраб ясыйлар. Әмма халыкның төп туклану продукты бодай белән борай була. Алардан тәмле ботка пешерәләр. Терлекчелек өлкәсендә этрусклар сыер, сарык һәм дуңгыз асрау белән шөгыльләнәләр. Атлар исә этрускларда изге хайван саналган, алар сугышларда файдаланылган. Җирне сукага икешәр үгез җигеп




Этрускларның Италиядәге колонияләре (карта А.И.Немировскийның «Этруски. От мира к истории» китабыннан алынды)

эшкәрткәннәр. Сарык сөтеннән сыр ясаганнар. Әмма аларның кымыз эчүе турында мәгълүмат юк. Бәлки аларда кымыз ясау шөгыле гомумән булмагандыр.

Йөзем үстерү, шәраб ясау гадәте этрускларга Италиянең көньягында урнашкан Кампанья өлкәсеннән килгән. Гомумән шәраб этрусклар җәмгыятендә аерым урын алып торган. Аны аксөякләр генә эчә алган, бу исә кешенең җәмгыятьтә тоткан урынын билгеләгән. Б.э.к. III гасырда Этруриянең югары сыйфатлы шәраблары хәтта Борынгы Грециядә дә билгеле була.

Этрусклар көнкүрешендә җитен дә зур роль уйнаган. Аннан сыйфатлы тукымалар тукып, киемнәр теккәннәр, зонтиклар ясаганнар, корабларның җилкәннәре дә җитен тукымадан тегелгән. Италиядә лимон үстерү этрусклардан таралган. Тора-бара зәйтүн агачлары үстерү, зәйтүн маен куллану гадәткә кереп киткән. Этрускча май «елива» дип атала. Шуннан «еливана», ягъни «олива мае» дигән гыйбарә барлыкка килгән.

Ул заманда Этруриядә калын урманнар күп булган. Анда имән, бүк, чикләвек, ак инҗир, дүле (армут, груша), алма, караҗимеш (слива) һәм башка агачлар һәм куаклар үскән. Б.э.к. IV гасырда яшәгән грек философы Теофраст сүзләренә караганда, Этрурия урманнарында үскән бүк агачларының биеклеге утызар метрга кадәр җиткән һәм шул агач кәүсәсе корабларның су астындагы килен ялгамыйча ясарга мөмкинлек биргән. Кораблар төзергә нигездә имән, бүк һәм ак чыршы агачлары файдаланылган.

Этрускларның оста металлурглар булуын билгеләп үтмәсәк, дөрес булмас иде. Алар бронзадан һәм тимердән яхшы кораллар, уңайлы авыл хуҗалыгы кирәк-яраклары ясаганнар. Хәтта сабаннары, сукалары да берничә төрле булган. Этрусклардан Сасерна атлы галимнең авыл хуҗалыгы буенча фәнни хезмәт язуы билгеле, ул шулай ук медицина һәм гигиена белән дә шөгыльләнгән. Соңрак дәвердә Рим галимнәре аның хезмәтләреннән өзекләр китерә торган булганнар.

Шәһәрләр барлыкка килгәнче, этруск аксөякләре табигать кочагында үз утарларында яшәүне кулай күргәннәр. Тора-бара шәһәрләр барлыкка килгән. Һәр шәһәр аерым дәүләт саналган, шуңа күрә аларны шәһәр-дәүләтләр дип атау дөресрәк булыр. Һәр шәһәр-дәүләтнең аксөякләр катламы сайлап куйган үз патшасы – лукумоны булган. Шулай итеп, Этруриядә унике төп шәһәр-дәүләт конфедерациясе үсеп чыккан. Аларның һәркайсы мөстәкыйль рәвештә яшәгән. Гомумән унике шәһәр-дәүләттән торган Этрурия тарихта гаҗәп күренешне тәшкил итә. Борынгы дөньяда күп халыкларда унике саны ниндидер изге, сокраль мәгънәгә ия дигән караш яшәгән. Күк йөзен унике өлешкә бүлеп карау, унике йолдызлыктан торган Зодиак, унике айдан торган ел, ике унике сәгатьтән торган тәүлек, хәтта Гайса пәйгамбәрнең (г.с.) унике шәкерте-апостолы, бритлар короле Артурның Түгәрәк Өстәл Орденын тәшкил иткән унике рыцаре (б.э.ның VI гасырында), Библиядәге Израиль халкының унике ырука бүленеше һ.б. Грек философы Платон да үзенең «Дәүләт» дип аталган хезмәтендә идеаль дәүләтне 12 өлешкә бүлә.

«Бу ясалма системада, – дип яза А.И.Немировский, – галәмнең 12 өлешкә бүленеше турындагы идеаль нигезгә корылган күзаллау яткан кебек үк, җәмгыятьнең дә шундый бүленештән торуын күзаллау күренеше ята. Этрускларның Умбрия җирләрендә унике шәһәр-дәүләт төзегәндә шул нигезгә таянып эш итүләре һәм соңрак чорда Төньяк Италиядә һәм көньяктагы Кампаньядә дә унике шәһәр төзүләре аларның Кече Азия төбәкләре белән гаять тыгыз бәйләнешләрен ап-ачык күрсәтүче дәлил булып тора» (Нем., 111).

Галимнең бу фикере этрускларның Кече Азиядән күчеп килүе һәм Галәмнең 12 өлешкә бүленеше турындагы күзаллауларны фәкать анда яшәгән дәвердә

үзләштерүләре хакында сөйли сыман. Борынгы заманда Кече Азиядәге Кария белән Фригиядә 12 шәһәр берлеге булган һәм аларның унысының исеме грек колонияләре исемен йөртмәгән икән.

Этруриядә шәһәрләр төзү тигез генә бармый. Кайсы алданрак төзелеп бетә, кайсы соңрак барлыкка килә. Шулай итеп, Этруриядә унике төп кала үсеп чыга. Бу шәһәрләрне этрусклар үзләренең беренче үзәкләре дип саныйлар. Һәр шәһәр аерым һәм мөстәкыйль дәүләт саналса да, аларның бөтен Этруриягә уртак мәсьәләләрне хәл итү өчен җыелып киңәшә торган үзәк шәһәре – Вольсиния дә була. Биредә алар Этруриянең төп патшасын сайлап куйганнар, шулай үзләрен бер халык итеп тойганнар. Әлбәттә, Вольсиниядә сайлап куелган патша башка шәһәр-дәүләтләр тормышына кысылмаган, аның хозурына бөтен ил өчен гомуми булган мәсьәләләрне хәл итү өчен генә җыелганнар.

Италиянең уртасындагы Этруриядә б.э.к. V гасырда иң борынгылардан саналган Тарквини (Таркна), Цере, Вея, Вульчи, Вольсиния, Клузий, Вольтерра, Ветулония, Популония, Кортона, Арреций, Перузия кебек унике шәһәр-дәүләт конфедерациясе барлыкка килә. Әлбәттә, шәһәрләр унике генә булмый, тик санап кителгәннәре илнең шәһәр-дәүләтләр конфедерациясен тәшкил иткән.

Тиррен диңгезе ярларында урнашкан шәһәрләрнең үз портлары да барлыкка килә. Мәсәлән, Цере шәһәренең Пирги порты, Тарквининың – Грависки порты, Клузийның, ул Этруриянең урта бер җирендә, диңгез ярыннан еракта урнашса да, Коза (басым беренче иҗеккә төшә) дигән үз порты була.

Этрурия шәһәр-дәүләтләренә, аларның нинди җирдә, нинди табигать шартларында урнашуына карап, икътисади яктан махсуслашу хас. Мәсәлән, Популония шәһәре каршындагы Ильва утравында казылма байлыклардан тимер һәм бакыр чыганаклары табылганнан соң, бу шәһәр-дәүләт рудадан метал эретү, металлдан тормыш-көнкүрештә кирәк нәрсәләр кою, эшкәртү белән шөгыльләнергә керешә. Шулай ук рудадан эретелгән металл белән сәүдә итә башлый. Клузий шәһәр-дәүләтенең ил уртасындарак урнашуын әйтеп узган идек. Ул, мәсәлән, нигездә авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерү белән шөгыльләнә, аны үз порты Коза аша чит илләргә озата. Этруриянең көньягында урнашкан Цере шәһәр-дәүләте һөнәрчелек һәм диңгез сәүдәсе алып баруы белән дан тота. Илнең калын урманнар белән капланган өлкәләрендә урнашкан шәһәр-дәүләтләр төзелеш һәм кораблар ясау өчен агач материаллары хәзерләү белән шөгыльләнә. Кыскасы, һәркайсы, табигать шартларының, тирә-юньдәге җирләрнең нинди булуына карап, үз икътисадын шул шартларга көйли.

Этруск телендә «спура» – «шәһәр» һәм «спурестрес» – «гражданлык» дигән сүзләр булуга таянып, галимнәр этрусклар җәмгыятенең шактый югары баскычта торганлыгын ачыклаган. «Гражданлык» хокукына шәһәрдә яшәүчеләр генә ия булмаган, бу хокук шушы шәһәр-дәүләт составына кергән авыл халкына да бирелгән. Дөрес, әлеге бу хокукка бары тик этрусклар гына ия булган, әмма тора-бара, әйтик, б.э.к. II гасыр урталарыннан италиклар, умбрлар һәм башка халык вәкилләре дә «ирекле гражданнар» санала башлаган. Шулай моңарчы крепостной хәлендә яшәгән башка халык вәкилләренә дә ирек һәм җирләр бүлеп бирелгән. Алар шәһәр-дәүләтнең ирекле гражданнарына әверелгән, кайберләре хәтта дәүләт органнарына да сайлап куела башлаган.

Этруриянең һәр шәһәр-дәүләтендә патша сайлап куелган, дигән идек. Шәһәр-дәүләт идарәчесе «лукумон» дип аталган. Бу сүз Этруриядән төрки мәдәниятләргә

Фил сөягеннән ясалган кәнәфи-тәхеттә утыручы шәһәр-дәүләт патшасы – Лукумон сурәте. Б.э.к. VI гасыр

дә үтеп кергән. Мәсәлән, Гаяз Исхакыйның «Локман хәким» дип аталган тирән эчтәлекле фәлсәфи хикәяте «Лукумон-Локман» традициясенә нигезләнеп язылган.

Галимнәр өчен Этрурия шәһәр-дәүләтләренең сыйнфый катламнар структурасын ачыклау шактый катлаулы мәсьәлә булып чыккан. Б.э.к. I гасырда яшәгән Рим шагыйре Вергилийның «Энеида» поэмасындагы дүрт юл әлеге мәсьәләгә бераз ачыклык кертә шикелле. Бу вакытта көчәеп киткән Рим ирекле Этрурияне яулап ала, этрусклар йотыла, акрынлап телләрен югалта. Әмма алар төзегән цивилизация, мәдәни казанышлар римлыларда соклану уята. Шагыйрь үзе дә этрус事 этрускларның Төньяк Италиядәге колониясе Мантуя шәһәрендә туа һәм шул хакта, илһамланып, мондый юллар яза:

«Мантуя! Предками славишься ты, но не единого рода.
Рода имеешь ты три, по четыре племени в каждом.
Ты же сама их глава, сильная кровью этрусской».

Бу юллар нәрсә турында сөйли соң? Димәк, Мантуя шәһәрендә этрусклар ыруы ул вакытта да абруйлы, «этруск каны белән көчле» урын алып торган. Шәһәрне өч төп ыругка бүлү системасы этрусклар заманыннан калган. Бу хакта А.И.Немировский кызыклы фикер әйтә: «Этрусклар ритуалы» нигезендә барлыкка килгән Римда да

шундый ук өч триба (ыруг) булган һәм алар төрле этнослардан торган. Әмма борынгы заманда ук урнашкан фикер нигезендә, андагы өч триба (ыруг) – Тацилар (Таҗилар), Рамнар, Луцерлар – барысы да этруск кавеменнән булганнар...» (Нем., 107).

Этруриянең шәһәр-дәүләтләре үзләренең яшәү дәверендә зур үзгәрешләр кичерә. Әүвәлге чорда алар башында сайлап куелган, бөтен халык тарафыннан хөрмәт ителгән һәм зур хакимияткә ия булган патшалар торса, соңгы чорда Рим басымы астында шәһәр-дәүләтләр мөстәкыйльлекләрен югалталар, ә патшалар исә акрынлап хөрмәтле урын биләүче затларга әвереләләр. Хәер, башка бер бүлектә бу хакта әле җентекле сүз алып барырбыз.

## ПАТША ГАЛИҖӘНАПЛАРЫ – ЛУКУМОННАР

Этруск шәһәр-дәүләтләре патшаларының сайлап куелуын әйтеп узган идек. Шик юк, аларны өске катлам вәкилләре, җирбиләүчеләр, хәрбиләр, югары дәрәҗәдәге дин әһелләре сайлап куйган. Патшаның аны башка кешеләрдән аерып торган билге-атрибутлары да билгеле. Беренчедән, патшаның күчереп йөртелә торган уңайлы кәнәфие-тәхете булып, ул һәрвакыт фил сөягеннән ясалган тәхеттә утырган килеш идарә иткән. Бу кәнәфи-тәхетне фәнни әдәбиятта «курульное кресло» дип атыйлар, тик «курульный» сүзенең төбенә төшеп аңлатып кына тормыйлар. Уйлап карасаң, «курульный» сүзенең нигезен төрки сүз тамыры «кур-кор» тәшкил итә түгелме соң? Телебездә «кур-кор» тамырыннан ясалган сүзләрне байтак табып була. Мәсәлән, кору, корылтай, корылма һ.б. Табигый, лукумон-патша һәрвакыт нәрсәне дә булса кора, гамәл кыла, карарлар чыгара. Татарда, кешенең берәр эше барып чыкмаса: «Коргансың икән!» – дип, аңа шелтә белдерү гадәте дә бар. Кыскасы, лукумонның затлы кәнәфи-тәхеткә утырган килеш төрле мәсьәләләрне хәл итүен «кору» сүзе белән аңлатып буладыр. Шуңа күрә этруск патшалары «курульное кресло»да утырган килеш идарә иткәннәр. Римда идарә иткәндә дә шундый ук кәнәфи-тәхеттә утырганнар.

Патшаны аерып торган икенче билге-атрибут аның өске киеме – алтын җепләр белән пальма яфраклары чигелгән пурпур (кызыл) тога булган. Тога – этруск сүзе, ул «tegere» (тегере) сүзеннән ясалган. Бу сүз «каплау» мәгънәсенә ия икән, ягъни патшаның тәнен каплаучы кием. «Патша кулында хакимият билгесе скипетр да булган, аның очына канатларын җәйгән бөркет сыны беркетеп куелган. Этруск телендә бөркет «антар» дип аталган, ул изге кош саналган. Әгәр дә этрускларның Кече Азиядән күчеп килүләрен искә төшерсәк, Анатолия халыклары мифларында бу кошның Кояш-алла хәбәрчесе булуы ачыкланыр иде» (Нем., 114).

Патша билгесе-атрибутларының иң соңгысы – «фасция» дип аталган. Нәрсә соң ул фасция? Бер бәйләм каен яки карама агачы чыбыклары эченә ике яклы балта тыгып калдырып, аны ике төштән кызыл каешлар белән бәйләп куйсаң – фасция килә дә чыга. Балтаның ике үткен йөзе чыбыклар бәйләменнән чыгып торган. Бу шактый гаҗәп нәрсә этрускларда хакимият билгесе саналган. Чыбыклар һәм балта патшаның җәза бирү хокукын белдергән. Патша берәр җиргә барганда аның алдыннан һәрвакыт сул иңенә фасция салган дәүләт хезмәткәре – ликтор атлаган. Боргы (быргы) кычкыртып, аның килүен хәбәр итеп торганнар. Патшаның башында алтыннан ясалган имән яфраклары һәм имән әкәлеләре белән бизәлгән таҗ да булган. Этрускларда имән изге агач саналган. «Римда Тарквинилар (Таркна) нәселеннән чыккан патшалар хакимлек иткәндә анда бер зур имән үсеп утырган, агачның изгелеген этрускча язылган таблица күрсәтеп торган. Болар барысы да бер нәрсә турында сөйли: «этрусклар таҗы» патша хакимиятенең изгелеген белдергән һәм әлеге таҗ патша хәзрәтләренең күктәге баш

алла Тиннең җирдәге вәкиле икәнлеге турындагы ышануларга бәйле булган» (Нем., 113). Патша-лукумоннар көнчыгыш халыкларына хас очлары өскә карап торган аяк киемнәре дә кигәннәр. Этруск патшаларының барлык билге-атрибутлары соңыннан Рим консуллары һәм императорларының хакимият билгесенә әверелгән.

Этруриядә патшаның вәкаләтләре сәяси, икътисади һәм дини өлкәләрне колачлаган булса кирәк. Әлбәттә, беренче чиратта ул үзен сайлап куйган өске катлам ихтыяҗларын кайгырткан, бер үк вакытта рекле халык катламын яклаучы буларак та үз вазыйфаларын үтәгән. Этрусклар үз патшаларына зур хөрмәт күрсәткәннәр. Патша үзе дә халыкны тугыз көнгә бер тапкыр кабул иткән, төрле мәсьәләләрне тикшереп, аларны хәл иткән. Моннан тыш, ул дин өлкәсендә дә зур роль уйнаган, этрускларның изге китапларын саклаучы вәкаләтләрен дә үтәгән, дин әһелләре (жрецлар) белән бергәләп, дини йолалар үткәрүдә катнашкан. Аның хәтта, төрле могҗизаларга аңлатма биреп, илне хәвеф-хәтәрләрдән саклауны сорап, аллаларга мөрәҗәгать итү хокукы да булган.

Ике йөзле балта турында махсус әйтеп үтәргә кирәктер. Ул этрускларда патша хакимиятен генә чагылдырмаган, үлем символы буларак та кабул ителгән. Гомумән, ике йөзле балта, аның грек телендә сакланган исеме «лабрис», хакимият билгесе буларак, Борынгы Дөньяда киң таралыш алган. Без аны Эгей диңгезе һәм Анатолия төбәкләрендә дә очратабыз. Шулай ук ике йөзле балта-лабрис Крит патшаларында да хакимият билгесе саналган. Дөрес, Криттта балталар түгәрәк йөзле булган. Этрускларда ике йөзле балтаның патша хакимиятен белдерүе очраклы күренеш түгел. Аның нигезендә Борынгы Дөньяда, Урта диңгез буйларында киң таралган төрки цивилизацияләр традициясе ята булса кирәк.

Этрускларның «triumpe» (триумпе) сүзе латин теле аша «триумф» рәвешендә бөтен дөньяга тарала. Гадәттә, аны Рим империясеннән калган сүз дип кабул итәләр, чөнки Рим императорларын яки сугышта зур җиңүгә ирешкән гаскәр башлыкларын империя башкаласында зур тантана оештырып каршы алганнар, аны зурлау, данлау мәрасиме үткәрелгән. Триумфаторга, сенатның махсус карары нигезендә, төрле дәрәҗәләр бирелгән һәм, шунысы кызык, бирелгән дәрәҗәләрнең, затлы билгеләрнең барысы да диярлек этруск патшаларын данлау тантанасыннан күчереп алынган булган.

Этруск патшасы да мондый тантаналар вакытында өстенә пурпур тога, башына алтын таҗ киеп, кулына хакимият билгесе булган скипетр тотып, үзен хөрмәтләргә җыелган халык алдыннан узган. Мондый триумф-тантана гадәттә патшаның тәхеткә утырган чагында, сугышта зур җиңүгә ирешүенә багышлап яки ил күләмендәге берәр зур вакыйга уңаеннан уздырылган. Патшаның, этрусклар күзаллавынча, баш алла Тин сыман, дүрт ат җигелгән арбага-квадригага басып халык алдыннан узуы аңа бирелгән хакимиятнең изге сыйфатка ия булуын аңлаткан.

Этрускларда патшабикә дә дәүләт тормышында зур роль уйнаган. Патшабикә, патшаны һәм дәүләтне саклаучы аллаларга багышлап, махсус алтарьларга корбаннар китергән. «Ул Эгей диңгезе һәм Анатолия төбәкләрендә таралыш алган «изге никах» концепциясен чагылдыручы зат саналган» (Нем., 116).

Форсаттан файдаланып, шуны да өстик: дини карашларга бәйле патша белән патшабикәне берләштерүче «изге никах» турындагы күзаллауларны без Шумер цивилизациясендә дә очратабыз. Мондый ышанулар Борынгы Дөньяның күп цивилизацияләрендә таралган булгандыр, күрәсең. ■

# ТАТАР БИСТӘЛӘРЕНЕҢ ШАНЛЫ ТАРИХЫ

***12-13 сентябрь көнне, Бөтендөнья татар конгрессы ярдәме, Татар төбәген өйрәнүчеләр җәмгыяте, Томск өлкәсенең татар мәдәнияте үзәге һәм Томск шәһәре татар милли-мәдәни автономиясе катнашы белән, биредә «Татар шәһәр бистәсе: үткәне, бүгенгесе һәм үсеш перспективалары» дигән темага Бөтенроссия татар төбәк тарихын өйрәнүчеләр форумы узды. Әлеге чарада Россиянең төрле шәһәр һәм авылларыннан, чит илләрдән 200гә якын галим, төбәкне өйрәнүче һәм музей белгечләре катнашты. Форумга Идел буе төбәкләреннән махсус вагон белән барган 54 делегат, Томскидан кала, Новосибирск өлкәсендәге һәм Екатеринбургтагы милли тормыш белән дә танышты.***

Форум вакытында Әстерхан, Сембер, Казан, Ижау, Свердловск, Төмән, Тара, Новокузнецк, Семипалатинск, Екатеринбург, Омск һәм башка шәһәрләрдәге татар бистәләре турында кызыклы чыгышлар булды. Журналыбыз сәхифәләрендә әлеге чарада яңгыраган берничә чыгышның текстын һәм сәяхәтебез барышында күргәннәрне бәян итәбез.

*Форумнан фоторепортаж белән* ***beznenmiras.ru*** *һәм* ***tatar-congress.org*** *сайтларыннан таныша аласыз.*

Безнең мирас №11 ноябрь 2019

# ЙОРТ-ОРЫДАГЫ
## *чат татарлары музее*

Төбәкне өйрәнү форумында катнашучылар Новосибирск өлкәсендәге иң борынгы татар авылы Йорт-Оры – Умарда булды. Тарихи мәгълүматларга караганда, анда инде VIII гасырдан бирле чат татарлары яшәгән.

Мәчет һәм музей төзелешләрендә башлап йөрүче кеше – шушы авылда туып-үскән элеккеге хәрби офицер, өлкә күләмендәге «Чат татарлары мирасы» һәм Йорт-Орыдагы «Иман» мөселман оешмалары җитәкчесе **Навил әфәнде Шаһабетдинов**.

Йорт-Орыда «Чат татары утары» дип аталган тарихи-мәдәни комплекс узган елның җәендә ачылган. Биредә чат татарының карагай агачыннан салынган йорты, чоланы,

мунчасы, бакчасы, җәйге йорты, коесы, мал абзары урнашкан. Өй эчендә себер татарларының яшәү рәвеше чагылыш тапкан – түр яктагы сәкесе һәм акшарлы миче, бишеге һәм чиккән мендәрләре, сандыгы һәм савыт-сабасы урын алган. Шулай ук ханнар-морзалар гына кия торган затлы җилән-чапаннарны да күрергә, хәтта киеп тә карарга мөмкин. Йорт-Оры татарлары көмештән үзләре ясаган алка

һәм чулпылар да бар. Чоланда исә себер татарларының бөтен эш кораллары – тоташ өянкедән каеп ясаган җиңел кәмә-каеклары, ишкәкләре, балык тоту өчен җәтмә һәм кармаклары, арба һәм чаналары, ау капкыннары, агач тырмалары, тимер сәнәкләре тезеп яки элеп куелган.

Татар утары Новосибирск шәһәренең туристлык маршрутына кертелгән, биредә каек-кәмәләр ясау, милли ризыклар әзерләү буенча да мастер-класслар үткәрелә.

***PS.*** *Журналыбызның 6 нчы санында (2019) Фәүзия Бәйрәмованың бай мәгълүматлы «Чат татарлары» исемле мәкаләсе басылып чыккан иде. Шунлыктан, тарихка тирән кермичә, фоторепортажны гына тәкъдим итәбез. Фотолар –* ***beznenmiras.ru*** *сайтында.* ■

Безнең мирас №11 ноябрь 2019

# «АЛТЫ АВЫЛ» ТАТАРЛАРЫ ҺӘМ БЕРТУГАН ХӘМИТОВЛАР

Ирек Биккинин



*XIX гасырдан Пенза губернасының Чембар өязендәге Качкару (Кутеевка), Кикын (Кикино), Мәчәли (Мочалейка), Тәләтен (Телятино), Решитен (Решетино), Кабыйлкын (Кобылкино) исемле татар авылларын «Алты авыл» дип атап йөрткәннәр. Нәкшбәндия тарикаты шәехе Әбделкәрим Пензави, морзалар нәселе вәкилләре Муса һәм Заһир Бигиевләр, атаклы төрек генералы Шакир-паша Яваев, Госманлы империясенең дәүләт эшлеклесе Мәхмәт Кани-паша, язучы Муса Акъегет һәм эшкуар, әстерхан татарлары лидеры Әнвәр Алмаев кебек мәшһүр шәхесләр биредә туып үскән.*

Татарлар, һәрвакыт мобиль булып, башка урыннарга җиңел генә күчеп киткән. Пенза губернасы – хәзерге Пенза өлкәсе һәм Мордовия Республикасы татарлары да һиҗрәтне күп күргән: башта морза һәм йомышлы татар буларак читкә хезмәткә китсәләр, XIX гасырда, җир аз булу сәбәпле, туган җирне калдырырга мәҗбүр булганнар.

Мишәр татарлары Россия империясенең көньягына һәм көнчыгышына – Дон, Төньяк Кавказ, Урта һәм Түбән Идел буе, хәзерге Татарстан һәм Башкортстан, Урал арты, Казакъстан җирләренә күпләп күченгән. Европа, Финляндия, Балтыйк буе илләренә, хәтта Кытайга да китүчеләр булган. Мәсәлән, Байкал арты краеның элеккеге губернаторы Равил Гыйниятуллинның бабасы белән әбисе – пенза татарлары. Алар әүвәл Кытайга китеп, Хайлар шәһәрендә яшәгән, ә аннары Россиягә әйләнеп кайткан һәм Читада төпләнгән.

Күченүчеләрнең язмышлары төрлечә була: кемдер читтә байлык туплый, кемгәдер

Томск өлкәсе архивында Серебряково авылының 1858 елгы халык санын теркәү кенәгәсе




бәхет эллә ни тәтеми, ә кайберәүләр юлбасарлар кулына килеп эләгә. Әлбәттә, Пенза губернасыннан ерак Себергә үз теләге белән китмәгән татарлар да бар. Әйтик, Хәмидулла Васькин – алпавытларны һәм чиркәүләрне талап, барлык мал-мөлкәтне хәерчеләргә һәм ятимнәргә бүләк иткән шәхес. Аны, Ростов-на-Дону губернаторының өч атын урлаганы өчен, Иркутскига сөрәләр. Әмма нәселләре Пенза губернасыннан чыгып, Себердә зур уңыш казанган иң мәртәбәле шәхесләр – абыйлы-энеле Хәмзә һәм Кәрим Хәмитовлар. Хәмзә – Томск губернасы ахуны, ә аның энесе Кәрим губернаның иң мәшһүр хәйриячесе була.

## ҺИҖРӘТ ДУЛКЫННАРЫ

Мин Хәмитовлар турында Шадринскидан Ренат Мусин мөрәҗәгать иткәч кенә белдем. Ренат күп еллар буе үз нәселе Кутуевлар, туган авылы Тархан (хәзер ул Мордовиягә керә) һәм Пенза губернасыннан булган Хәмитовлар турында материаллар җыю белән шөгыльләнә иде. Ул үзенең бабасы Мөхәммәдәмин Хәмитовның һәм башка туганнарының да Кемерово өлкәсенең Тисуль районындагы Серебряково авылында яшәгәне турында хәбәрдар. Шулай ук Томск губернасында яшәгән Хәмзә һәм Кәрим Хәмитовлар турында да белә.

Төбәкне өйрәнүче Таһир Абдрахманов белән, нәсел шәҗәрәсен төзүдә аңа ярдәм итү өчен, Пенза губернасындагы татар авылларының ревизия материалларыннан Хәмитовлар гаиләсен эзли башладык. Нәтиҗәдә, бу нәселнең Чембар өязендәге Решитен авылыннан (хәзерге Пенза өлкәсенең Пачелмский районы) икәнлеге ачыкланды.

1853 елда «Алты авыл»дан Решитеннең гади, әмма шактый гыйлемле крестьяны Мөхәммәдәмин Хәмитов җитәкчелегендәге зур кәрван – 305 кеше (154 ир-ат, 141 хатын-кыз) ерак Томск губернасына китә һәм Мариинск өязендәге Серебряково исемле яңа татар авылына нигез сала. Шуны да искәртик: 1858 елгы Чембар өязенең халык санын алу кенәгәләреннән мөһаҗир ир-атларның гына исемен белергә мөмкин, ә күпме хатын-кыз күченгәнен ачыклар өчен, шул өяздәге алты авылның 1850 елгы һәм Серебряковоның 1858 елгы «Ресвиские сказки» материалларын актарып, чагыштырып карарга туры килде.

2017 елда мин, шәхси машинам белән Пензадан озын юл узып, Серебряково авылына бардым. Андагы җирле татарларның «Алты авыл»га хас булган төмән-инсар шивәсендә сөйләшүен ишетеп таң калдым.

Без Кемерово өлкәсенең иң көнчыгышындагы Тисуль районында татарлар күченгәнче үк Серебряково исемле рус авылы булган һәм милләттәшләребез шунда килеп кушылган гына, дип уйлый идек. Әмма, Пенза архивында эзләнә торгач, авылның исеме Качкару авылындагы (хәзерге Пенза өлкәсенең Белинск районы) Серебряковлар гаиләсе фамилиясеннән барлыкка килгәне ачыкланды. «Алты авыл»дан күченгән аталы-уллы Ибраһим белән Габделмалик Серебряковлар гаиләсе иң ишлесе – 22 кеше

булган икән. Мөгаен, алар яңа җирне алданрак барып күрүче һәм рәсми документлар белән шөгыльләнүче дә булганнардыр.

Томск өлкә архивында саклана торган 1858 елгы халык санын теркәү кенәгәсендә Серебряковода Пенза губернасыннан күченгән 44 гаилә яшәве теркәлгән, әмма Качкарудан чыгып киткән Зәбир Абушахманов гаиләсе исемлектә юк – кая киткәнлеге билгесез. Аның каравы, 1853 елда күчеп китүчеләр исемлегендә булмаган ике гаилә бар. Исем-фамилияләренә караганда, бу гаиләләр дә «Алты авыл»дан. Аларның берсе 1856 елда Иркутск губернасындагы сөргенлеләр арасыннан килгән дип күрсәтелгән.

Серебряковога нигез салган пенза татарларыннан 1845 елда Себергә сөрелгән ике гаилә дә бар. Болар: Мәчәлидән – Каратевлар һәм Качкарудан – Мельгизиннар. (Серебряково авылында алар Гафаров фамилиясе белән язылган.)

Серебряководагы зур янгыннан соң, берничә гаилә Лепсинская (хәзерге Казакъстан) станицасына юл тота. Аларның бер буын вәкиле – Казакъстанның күренекле нейрохирургы Габделхак Солтан улы Габделхаликов (1941-1994).

Хөкүмәтнең «Аз җирле дәүләт крестьяннарын күп җирле урыннарга күчерү буенча өстәмә кагыйдәләр турында»гы 1843 елгы указы нигезендә, күченү факты расланганнан соң, мөһаҗирләргә 10 сумнан 60 сумга кадәр акчалата пособие бирелгән. Алар дүрт елга салымнардан азат ителгән, аннары дүрт ел буе салымны яртысы күләмендә генә түләгәннәр; өч чакырылышка кадәр рекрут йөкләмәсеннән азат ителгәннәр. Күченүчеләрне юлда ашату, авыручыларның сәламәтлеген кайгырту мәсьәләләрен дә хөкүмәт үз өстенә алган. Килеп төпләнгәннән соң, крестьяннарга икмәк, печән, эш атлары һәм хезмәт кораллары бирелгән. Әлбәттә, бу кагыйдәдә вәгъдә ителгәннәрнең барысы да идеаль дәрҗәдә гамәлгә ашырылган, дип әйтеп булмый.

***

Шуны да билгеләп үтәргә кирәк: Серебряково – «Алты авыл» халкы күпләп күченгән икенче урын. Саратов губернасының Царевск өязендәге Бәхтияр авылына (хәзерге Волгоград өлкәсенең Идел районы) беренче күченү күпкә масштаблырак булган. 1839 елда Бәхтияргә 254 ир-ат китә, 1841-1846 елларда тагын 100 ир-ат күченә, ягъни 354

Автор әлеге мәкаләне язар өчен Пензадан Кемерово өлкәсендәге Серебряково авылына кадәр 3 мең чакрымнан артык юлны шәхси машинасында уза

ир-ат һәм якынча шулкадәр үк хатын-кыз. Болар барлыгы 700дән артык кеше дигән сүз. Авылның исеме җир кишәрлекләрен бүлү белән шөгыльләнүче Решитен кешесе Бәхтияр Яхин хөрмәтенә аталган.

Әмма бу татарларның барысы да Бәхтиярдә калмый. Кайберләре 10 чакрым читкә – Актүбә елгасының түбән агымындагы җирләргә күченеп, Малай (Маляевка) авылына төпләнә. «Алты авыл»дан күчеп килүчеләрнең тагын бер өлеше Идел буйлап Әстерханга кадәр төшә һәм, кулай урын табып, Яңа Әскәр авылына (хәзер Әстерхан өлкәсенең Нариман районы) нигез сала. Бу авылга күченүчеләрнең күбесен элеккеге солдатлар тәшкил итә.

Серебряковога һәм Бәхтияр авылларына китүчеләр исемлеген чагыштырып карасак, алар арасында туганнарның шактый күп икәнен күрәбез. Абыйсы үз гаиләсе белән Бәхтияргә китсә, бертуган энесе исә Серебряковога барып төпләнгән. Аржухановлар, Васильевлар, Канеевлар, Курмашевлар, Мамлеевлар, Нагаевларның да нәселе, шулай итеп, ике якка аерылган.

***

Мөхәммәдәмин Хәмитовның гаиләсе Решитеннән киткән вакытта шактый зур – 9 кеше тәшкил итә. Хатыны Хәлимә Бәхтиярова белән биш ир баласы – Мөхәммәтҗан, Йосыф, Хәнәфия, Хөсәен һәм Хәмзә, ике кызы – Хәдичә һәм Инбигешсөл була. Соңрак Хәмитовлар гаиләсендә тагын ике ир бала – Хәнәфия (1855) һәм Мөхәммәдкәрим (1863) – Кәрим бай дөньяга килә.

Себергә һиҗрәт кылучылар үзләре белән имам итеп Мөхәммәдәмин Фәтхулла улы Курмашевны (1837-1916) да алалар. Уфада тукталыш ясап, Диния нәзарәтендә имтихан бирдереп, мөфти Габделвахит Сөләймановтан имам итеп кую турында указ бирүен үтенәләр. Мөфти имтихан ала, әмма указны Себердә яңа мәхәллә теркәлгәч кенә бирәчәген вәгъдә итә. 1865 елда Мөхәммәдәмин Курмашев, Уфага барып, Серебряково мәхәлләсен рәсми теркәтә һәм мөфти Сәлимгәрәй Шаһгәрәй улы Тәвкилевтән (1862-1885) муллалык турында указ алып кайта.

Бу тарих 1928 елның 16 декабрендә имзаланган ахун Хәмзә Хәмитов автобиографиясендә бәян ителә. Аннан аңлашылганча, М.Курмашев Серебряковода булмаган арада, мулла вазыйфасын вакытлыча Мөхәммәдәмин Хәмитов башкара. Мөгаен, ул Решитендә яшәгән чорда 1842 елда вафат булган шәех Габделкәрим Пензавидан белем алгандыр.

## БЕРТУГАН ХӘМИТОВЛАР

Хәмзә Мөхәммәдәмин улы Хәмитов 1874 елда, ягъни 23 яшендә Бохара мәдрәсәсен тәмамлап, туганнары янына – губерна башкаласы Томскига килә һәм шәһәрнең имамы, ахуны, соңрак губернаның ахуны булып эшли.

Шуны да искәртик, бу вакытта Томск губернасы шактый зур булып, хәзерге Алтай краен, Кемерово, Новосибирск һәм Томск өлкәләрен, Казакъстанның төньяк-көнчыгышын, Красноярск краеның көнбатыш һәм Омск өлкәсенең көнчыгыш җирләрен үз эченә ала.

М.Хәмитовның Кәрим исемле улы да дини белем эсти, татар теленнән кала, төрек, рус, урду, гарәп һәм фарсы телләрен үзләштерә. Әмма аның күңелендә имам яки тәрҗемәче булу теләге түгел, ә эшмәкәрлек дәрте кайный. Кәрим, күп телләр белүеннән файдаланып, Томскига килгән чит ил сәүдәгәрләре, азиялеләр белән руслар арасында арадашчы хезмәтен башкара.

Тобольск-Томск юлы аша Бохара, Ташкент һәм Кытай белән сәүдә бара, ел саен

сәүдә кәрваннары үтә. Россиянең төрле почмакларыннан сәүдәгәрләр кеш, тиен, төлке мехлары алып килә һәм ефәк, чәй, кипкән җиләк-җимеш сатып ала.

Кәрим сәүдә эшчәнлегенең асылына бик тиз төшенә һәм, башлангыч капитал туплар өчен, тайгадагы алтын приискларына эшкә китә. Биредә ул остяклардан (хант һәм манси) алган җәнлек тиреләрен Бохара, Коканд, Ташкент һәм Кытай сәүдәгәрләренә сата башлый. Шулай итеп, Кәрим Хәмитов төбәктәге иң бай татар сәүдәгәренә әверелә. 1899 елда, 36 яшендә ул Томскиның икенче гильдия сәүдәгәре дәрәҗәсенә ирешә.

Кәрим байның иң зур хыялы атлар үрчетү була. Ул токымлы атлар сатып ала һәм аларны үрчетү белән шөгыльләнә башлый. Томскидан утыз чакрым читтә көтүлек җирләрен һәм умарталыгын да булдыра. Атлары бөтен Россия империясе буйлап тарала. 1904-1905 еллардагы Рус-япон сугышы Кәрим байга зур табыш китерә – аның атлары армия ихтыяҗлары өчен күпләп сатып алына. Кәрим байның атларны Ерак Көнчыгышка үзе озатып баруы да билгеле.

1900 елда Томскиның Хәмзә Хәмитов муллалык иткән мәчете янып харап була. Кәрим бай 1901 елда яңа мәчет төзелешенә нигез сала. Шулай итеп, 1904 елда – Кызыл, 1913 елда Ак мәчет ахун Хәмзә Хәмитов җитәкчелегендә һәм Кәрим бай Хәмитов акчасына төзелеп бетә. 1904 елда атаклы татар сәүдәгәре үз гаиләсе өчен шәһәрдәге иң затлы йортны салып куя. Хәзерге көндә бу бинада Томск өлкәсенең татар мәдәнияте үзәге урнашкан.

1907 елда Кызыл мәчет янында мәдрәсәнең яңа таш бинасы төзелә, мөселман хатын-кызлары өчен дә уку йорты ачыла. Кәрим бай төзетеп калдырган су каланчасы озак еллар дәвамында Татар бистәсе халкын гына түгел, ә шәһәрнең үзәк районында яшәүчеләрне дә эчә торган су белән тәэмин итеп тора.

1909 ел башында губернатор Томск мөселманнарының «Тәрәккыюн ислам» – хәйрия җәмгыяте уставын раслый. Аны оештыруда һәм нәтиҗәле эшчәнлегендә дә төп рольне Кәрим Мөхәммәдәмин улы Хәмитов башкара. Җәмгыять Сабан туйлары, төрле спектакльләр оештыру белән шөгыльләнә, ярлыларга матди ярдәм күрсәтә. 1913 елда 700 данә китап фонды (500е – татар телендә) булган китапханә-уку бинасы ачыла. Уку йортына рус һәм татар телләрендәге 40 газета яздырыла.

Революциядән соң, Хәмитовлар гаиләсе өчен коточкыч көннәр башлана. Сәүдәгәр, хәйрияче, җәмәгать эшлеклесе Кәрим бай Хәмитов 1919 елның 31 августында, 56 яшендә 9 баласын ятим калдырып, инсульттан вафат була. Яңа Совет власте Хәмитовларның йортын тартып ала, 39 яшендә тол калган Мотаһара Латыйп кызы Вахитовага, балаларын ияртеп, Үзбәкстанга китәргә туры килә. Ул 1971 елда Ташкентта вафат була.

1917 елның 25 мартында революционерлар карамагындагы Томск мөселман бюросы ахун Хәмзә Хәмитовны Кызыл мәчет имамы итеп вакытлыча гына – яңа имам табылганчы калдыра, ә мәзин Кармеевны (шулай ук Серебряково авылыннан) бөтенләй үк урамга куып чыгаралар. Татар урамындагы йортыннан мәхрүм ителгән данлыклы ахун Ак мәчет подвалында яши һәм 1930 елда мәчет ябылганчы, имам ярдәмчесе булып эшли башлый.

1930 нчы елларда Кызыл мәчет ябылгач, гыйбадәт залы кино күрсәтү өчен файдаланыла, аннары анда аракы заводы урнаша. Хәзерге вакытта Кызыл мәчет тә, Ак мәчет тә мөселманнар карамагында. Томск татарлары Кәрим бай һәм Хәмзә Хәмитовларны онытмый: аларның бай мирасын өйрәнеп, татар мәдәниятен һәм гореф-гадәтләрен саклау буенча даими эш алып бара. Кәрим байның оныклары Себернең төрле шәһәрләрендә, Мәскәүдә һәм Үзбәкстанда яши. ■

Безнең мирас №11 ноябрь 2019

# *Томск йомышлы татарлары* Кузнецк крепосте төзелешендә

Әнвәр Аширов*

*Россиядә, Болгавыр дәвер тәмамланганнан соң, тәхеткә патша Михаил Федорович Романов утыртыла. XVII гасыр башында яңадан тернәкләнә башлаган рус дәүләте үз чикләрен Көнчыгыш Себер киңлекләренә кадәр ныгытырга, яңа җирләрне яулап алырга омтыла. Хакимият империячел рух белән яна: дәүләт составына кергән яки күршетирәдә генә калган бар халыкны, кабиләләрне бербөтен итеп берләштерергә, төрле салымнар түләтеп, казнаны баетырга хыяллана. Яңартылган дәүләтнең барлык структуралары да шуңа җигелә.*

Кузнецк шәһәре. XVII гасыр

Кузнецк ныгытмасын төзү тарихы хөкүмәт сәясәтен тырышып-тырмашып, хәтта патшага яхшы булып күренү өчен төрле әләк-ялганнардан да тартынмаган воеводалык администрациясе эшчәнлеге һәм, әлбәттә, ясак түләүчеләрнең санын арттыру ихтыяҗы белән тыгыз бәйләнгән. Табигый, җирле себер халкыннан ясак җыярга җибәрелүчеләр гади  халыкның һәм аксөякләрнең көчле каршылыгына дучар булган. Кузнецк татарларыннан ясак җыярга омтылулары, әмма эшнең барып

*__Әнвәр Айсеевич Аширов__ – Кемерово өлкәсендәге Новокузнецк шәһәренең «Чулпан» мәчете имам-хатыйбы, төбәкне өйрәнүче.

Кузнецк крепосте. XIXгасыр

чыкмавы хакында воеводалар Мәскәүгә менә ниләр җиткерә: *«И преж сего, Государь, кузнецкие люди ясаку тебе, государю, платили не сполна, недособолишка худые, которые в твою государеву казну непригодятца»*.

Бүгенге Новокузнецк Томьның уң һәм Кондома елгасы тамагының сул ярларында Томск йомышлы татарлары һәм руслары тарафыннан терәк пункт буларак төзелә. Бу җирнең күп кенә кабиләләре, шул исәптән телеутлар, теленгитлар, калмыклар һәм шорлар XVII гасыр башындагы рус документларында «кузнецк татарлары» дип аталган. Крепость төзүчеләр килгән вакытта алар телеут яки кыргыз кенәзлекләренә салым түләгән. Шуңа күрә дә Томь, Мрас-су һәм Кондом елгалары буенда яшәүче кузнецк татарларыннан салым җыярга килүчеләр еш кына ике кулны селкеп, бернинди мех һәм тимер эшләнмәләрсез кире әйләнеп кайта торган булган. Бу вакытта Көньяк һәм Көнбатыш Себердә кыргызларның да хакимияте ныгый. Әмма казаклар, томск татарлары белән бергә, воеводалар, патша хакимияте куйган бурычны тугры үти: кыенлыкларга да карамастан, Томь елгасының югары агымындагы җирләрне һәм кабиләләрне буйсындырырга омтыла.

Кузнецк татарларына оештырылган һәр сәфәр шактый зур мәшәкатьләр тудыра. Томск воеводалары В.Волынский һәм М.Новосельцевлар 1610 елда Мәскәүгә зар-интизар белән тулы хат юллыйлар: *«До кузнецких, государь, до ближних волостей ходу 7 недель, а идти, государь, все до них пусто. И многие, государь, служилые люди и томские татарове, которые ходят в подводах, помирают на дороге с голоду»*.

Рус воеводаларының комсызлыгы кыргызларны чыгырыннан чыгара. 1614 елда алар Томск крепостена һөҗүм итәргә мәҗбүр була, җирле татарларга һәм рус авылларына зыян сала. Әлеге вакыйгадан соң, воеводалар Себер приказына (Себернең яулап алынган җирләре белән идарә итә торган оешма) Томь елгасының югары агымы буенда крепость төзергә, дигән бурыч куялар.

1616 елда татар җирләренә яңадан ясак җыючыларны җибәрәләр – алар да буш кул белән әйләнеп кайта. Булдыксыз томь казагы Иван Теплинский патшага менә ниләр әләкли: *«Меня холопа твоего, (татары) ограбили и платье поснимали и санапал (ружье. –* ***Авт.****) и саблю отняли»*.

Шулай берничә мәртәбә кузнецк татарларыннан ясак җыярга маташып

Кузнецк крепосте капкасы. Хәзерге күренеш

уңышсызлыкка очраганнан соң, Томск воеводалары Мәскәүгә тагын үзләренең моңзарлары тулы хәбәр җибәрә һәм бу хат Кузнецк нытытмасына нигез салуны тизләтә. 1617 елда Мәскәүдән төзелеш эшләрен башлап җибәрергә рөхсәт бирелә: *«Велено поставити острог в Кузнецах или где пригоже; для осторожные ставки, велено людей послати изо всех сибирских городов» по 10 человек стрельцов, «а велеть им на тое службу выбиратьца самим»*. Чыганактан аңлашылганча, шәһәр төзелешендә томь татарлары гына түгел, түмән һәм верхотурск (Тура елгасының югары агымындагы өяздә яшәүче) татарлары да катнашкан, дип фикер йөртә алабыз.

Кузнецкны читтән килгән казаклар һәм аларның отрядлары, татарлар гына төзегән, дип санау дөрес түгел. Яңа җирләрне яулап алу, үзләштерү һәм саклау эшенә төньякта яшәүче аучы кабиләләр дә ярдәм итә. Биредәге йомышлы кешеләрнең егерме процентка якынын аба татарлары – абалар, ягъни Аба елгасы буйларында яшәп, казак хезмәтенә кергән татарлар тәшкил итә. Абаларның кенәзе Базаяк 1608-1609 елларда ук рус патшасына тугрылыгын белдерә. Кайчандыр биредә Аба шәһәрлеге дә булган. Хәзерге Новокузнецк читендәге Абашево, шәһәр составындагы Иске Абаш һәм Абагур поселоклары, Томь елгасы уртасындагы Абаш утравы, Том елгасына коя торган Аба һәм Абашев елгаларының һәм Абашевский микрорайонының да атамалары аба татарларыннан килә.

1617 елның көзендә (җирле кавем ирләренең ауга китүеннән файдаланып түгелме икән? – ***Ред.***) воевода Остафий Харламов җитәкчелегендәге 45 кешелек йомышлы казаклар төркеме Томскидан Кондом елгасы тамагына Кузнецк ныгытмасы төзер өчен юлга чыга. Әмма кар иртәрәк төшү һәм Себернең көчле салкыннары юлчыларны Тюлюберск волостенда тукталырга мәҗбүр итә.




Томь елгасы буенда Кузнецк шәһәре һәм аның тирәсендәге җирләр. С.У. Ремезов китабыннан. XVII гасыр ахыры

[Кузнецкая старина. Новокузнецк: 400 лет в истории России. – Томск; Новокузнецк: Изд-во Том. ун-та, 2018]

Томск воеводасы, казакларның хәле мөшкеллеге һәм кышлауга туктаулары турында хәбәр алгач, татар кешесе – гаскәрбашы Осип (Йосыф) Кокорев һәм воевода Малчан Лавров җитәкчелегендәге казакларны һәм томь татарларының яңа төркемен җибәрә. Высокий поселогы һәм Смирновка авылы арасында – крепостьтан 7-8 чакрым ераклыктагы «Йосыф тавы» нәкъ менә Осип (Йосыф) Кокорев исеме белән бәйле булырга тиеш. Татар тарихына бәйлелеген оныттырырга теләп булса кирәк, хәзер бу урынны «Бабий пуп» дип кенә атап йөртәләр.

Шулай итеп, 1618 елның 18 февралендә татар егете җитәкчелегендәге отряд Томскидан юлга кузгала. Кышлау урынына килеп җиткәч, татарлар үзләренең тапкыр һәм зирәклекләрен, һөнәргә осталыкларын күрсәтәләр: бөтен төркем өчен чаңгы, кар чаналары ясап бирәләр. Табигатьнең кырыслыгына карамастан, татарлар, йөрәк җылысын, күтәренке рухны саклап, мөшкел хәлдә калган казакларга ярдәм итә. Тюлюберск волостенда берләшкән отряд, ныгытма төзү өчен кулай урынны карап, Абинск волостена туктала. Бу вакытта Томскидан Кузнецкка кадәрге юлны чаңгыда яки җәяү 6-7 атна узганнар.

Төзелеш эшләре тиз һәм ашыгып башкарыла. Яз башында төп эшләр тәмамлана – диварлар торгызыла, түбә ябыла. Ныгытма төзелеше тәмамлангач, Осип Кокорев һәм Молчан Лавров җитәкчелегендәге ярдәмче отряд Томскига кайтырга карар кыла. 1618 елның 3 маена нисбәтле тарихи чыганактан: *«Татарский голова Осип Кокорев, да Молчан Лавров доложили воеводам о построении крепости на земле кузнецких татар, сказав, что божьею милостью в Кузнецких волостех на усть Кондомы реки с томскими, и с тюменскими, и с верхотурскими с конными людьми острог поставили, и крепость зделали, и кузнецких волостей людей под государеву царскую руку привели... И ясаку Остафий прислал из Кузнецкого острогу с Осипом, да с Молчаном, что у него было в зборе»*, – дигән юлларны укыйбыз. Хәбәрнең азагында гаярь татар ирләренең

яңадан крепостька озатылуы хәбәр ителә: *«Мы в новой Кузнецкой острог Остафью Харламову в перемену [послали] татарского голову Осипа Кокорева; да сына боярского Бажена Карташева, да с ними томских служивых людей пеших казаков на годовую 8 человек мая в ... день».*

Бояр углы Бажен Карташев Алтын Урда чорында яшәгән, Ишәй елгасы буенда җир биләмәләре токкан татар морзасы Акмай Картыш нәселеннән булырга тиеш. XVII гасырда Карташевлар стольник һәм стряпчий булып хезмәт иткән. Фамилиянең нигезендә төрки-татар «кардәш» сүзе ята.

Яңа төзелгән Кузнецк кирмәнендә Харламов җитәкчелегендәге 45 казак тулаем төпләнеп калганмы яки Осип Кокорев һәм Бажен Карташев җитәкчелегендәге 8-10 кешелек гарнизон килеп хезмәт иткәнме – төгәл билгесез. Томск воеводаларының кенәз Куракинга хатындагы: *«Остафию Харламову с служивыми людьми, которые ныне в Кузнецком остроге, велели быти из Кузнецкого острогу в Томской город»,* – дигән сүзләргә ышансак, яңа крепостьта татар егетләре җитәкчелегендәге төркем генә калган, дип уйларга була.

Шулай итеп, архив чыганаклары нигезендә, без кузнецк татарлары җирендәге Новокузнецк шәһәрен гаять кырыс шартларда йомышлы татарлар салган һәм саклаган, дип төгәл әйтә алабыз. 1651-1652 елларда гарнизонны саклар өчен йомышлы аба татарларыннан да махсус төркем оеша.

Шәһәрнең барлыкка килү тарихын җентекләп өйрәнү нәтиҗәсендә, фәнни әйләнешкә кертелмәгән шактый гына чыганаклар һәм кулъязмалар барлыгы ачыкланды. Г.Ф.Миллер, И.С.Фалькның Себер халыклары тарихы һәм этнографиясе буенча экспедиция материаллары безнең өчен зур чыганак булып тора. Архивларда эзләнү вакытында кузнецк татарлары җирендә яки аларның күршесендә яшәүче башка халыклар турында да яңа мәгълүматлар табылды. Әмма шунысы шиксез: Россия дәүләтчелеге формалашу тарихында җирле халыкның телен, гореф-гадәтләрен, урнашу урынын яхшы белгән йомышлы татарлар һәм аларның җитәкчеләренең роле бәһаләп бетергесез зур.

***Редакциядән.*** XVI гасырда һәм хәтта совет чорында да Россия хөкүмәте батыр, гаярь, эшлекле, тылмачсыз да ярты дөньяны аңлаган татар халкын үзе белән бер үк телдә сөйләшкән кардәш, әмма башка географик киңлектәге татар һәм башка төрки халыкларны яулап алу, кан коеп буйсындыру сәясәтендә уңышлы файдалана. Элеккеге каһанлык һәм татар ханлыклары җирләрендә яшәп, үзләрен төрки-татар дип санаган әлеге кабиләләр үзара берләшеп, дус һәм милли мәсләкләренә тугры яшәсәләр, кем белә, бәлки тарих тәгәрмәче бөтенләй башка юлдан киткән булыр иде. Бу мәкаләдә ачы тәҗрибәдән туган хакыйкатьнең бер мисалын, ягъни төрки кавемнәрнең таркаулыгын, томск йомышлы татарларының ясаклы кузнецк татарларын империя составына кертү юлындагы көрәшен күрәбез. 1920 нче елларда үзбәкләргә каршы җибәрелгән татбригада да әлеге тарихи процессның логик дәвамы – кан кардәш халыкларны берсе өстенә икенчесен «өстерү» сәясәтенең бер мисалы булып тора.

Кайчандыр Себернең чын хуҗалары булып, элек татар, ә соңрак шор, телеут һәм теленгит дип аталган төрки кавемнәрнең хәле бүген аеруча мөшкел. Россиядә шорлар –13 мең, телеутлар – 2700, теленгитлар 3800 кешегә калып килә. Томскида узган Төбәкне өйрәнүчеләр форумы вакытында культурология докторы, профессор **Надежда Доржу кызы Ултургашева** Кемерово өлкәсендәге шор авыллары проблемасы, аеруча аларның күмер сәнәгатьчеләре тарафыннан кысрыклануы турында ачынып сөйләде. ■

# СЕМБЕРДӘГЕ *татар бистәсе*

Римма Вилданова[1]

*Сембер шәһәренең яңадан төзелгән яки юкка чыккан Миллионная, Буа, Казан, Полевая, Провиантовая, Лесная, Лосевая урамнарында Әхмәтов, Габдрахманов, Рәхмәтуллов, Ишуков, Тимербулатов, Хәбибуллин, Җәләлетдинов һәм Хөснетдиновлар кебек дистәләгән татар гаиләләре яшәгән. Кызганыч, аларның күбесе хакында мәгълүмат сакланып калмаган диярлек.*

Бүгенге кала җирләрендә Идел буе Болгарстаны дәүләте чорында үк борынгы бабаларыбыз яшәгәнлегендә бернинди шик юк. XVII гасырда патша хакимияте көньяк, ягъни шул чор чыганаклары язганча, «кыргый дала» күчмәннәренең һөҗүменнән саклану өчен, Сембер чик буе ныгытмасы төзегән вакытта 50 йомышлы татарга җир




1864-1926 елларда татар зираты шәһәрнең төньягында, Кирпеч сарайлары һәм Казан почта юлы арасында урнашып, үр белән әйләндереп алынган була. Хәзер бу тирәдә икенче мәхәллә мәчете эшли. Картадан Сембердәге «Татар бистәсе»н – Миллионная, Буа, Казан, Полевая, Провиантовая, Лесная, Лосевая урамнарын, татарлар сәүдә иткән Ярминкә һәм Базар мәйданнарын күрергә мөмкин

[1] **Римма Камил кызы Вилданова** – Ульяновск дәүләт университеты президенты ярдәмчесе, тарих фәннәре кандидаты.

кишәрлекләре бүлеп бирә. 1648 елда оешкан Сембер шәһәрендә милләттәшләребез XIX гасырның беренче яртысыннан гына аерым урамнар һәм квартал булып берләшеп яши башлый. «Татар бистәсе» Россия дәүләтенә тугры хезмәт итүче татар хәрбиләреннән һәм якындагы авыллардан күчеп килгән кешеләрдән оеша. Хәрбиләрнең шактые, хезмәт иткән урыннарында гаилә корып, балалар тәрбияләп яшәп калсалар, кичәге игенчеләр көнлекче булып ялланган яки һөнәрче һәм сәүдәгәр буларак тормышын җайга салганнан соң, гаиләләрен дә бирегә чакырган.

Баштагы елларда татарларның рухи-мәдәни үзәге, ягъни мәчет вазыйфасын Лосевая (хәзерге Федерация) урамында яшәүче Ильясовның хуҗалыгында урнашкан намаз йорты башкара. Сембер шәһәренең дәүләт тарафыннан тәгаенләнгән беренче рәсми мулласы Ягъфәровның бурычы мөселман хәрбиләрнең дини-рухи тормышын кайгырту була. Ир-атларның саны 200 кешедән артып киткәннән соң, 1853 елда сәүдәгәр Курамша Акчурин акчасына губернадагы бердәнбер таш мәчеткә нигез салына. Ягъфәровтан соң мулла вазыйфасын Вәлиулла Габделгафаров дәвам итә. 1864 елдан мәзин Шаһидулла Яхиев, соңрак аның нәселе вәкилләре була. 1872 елда мәчет янәшәсендә мәктәп тә эшли башлый.

Шәһәр үсә барган саен, татарларның да саны ишәя. А.А.Кузнецов язуынча, бер дистә ел эчендә (1877-1887) милләттәшләребезнең саны дүрт мәртәбә арта – 253 кешедән 1055 кешегә җитә. Шәһәргә күчеп килгән татарлар шәхси йортларга, кунакханәләргә, аеруча Габдрахман Әбелхановныкына урнаша. 1895 елгы хәбәрче язуынча, «...барлык башка милләт кешеләре дә нык руслаша, үз миллилекләрен югалта – ир-ат һәм хатын-кызлар рус телендә сөйләшәләр. Мишәрләр, милли киемнән йөрсәләр дә, тел ягыннан тулысынча руслашуга якынлашып киләләр».

Татарлар күпләп яшәгән Лосевая урамы

Безнең мирас №11 ноябрь 2019

Лосевая урамындагы (хәзерге Федеральная) татар йортлары.

Аста – ТАССРның атказанган артисты Сәет Булатов (1898-1970) туган йорт

С.Л.Прозоров мәгълүматына караганда, 1860 елда шәһәрдә 305 мөселман яши, ә 1897 елда – 2191, 1917 елда исә татарларның саны 3 меңнән артып китә. Бу – барлык шәһәр халкының 6 проценты дигән сүз. Татарлар үзләренең сату-алу эшендә осталыгы белән аерылып торган һәм, башка милләтләр белән чагыштырганда, алар арасында эшкуарларның саны күбрәк булган. Сәүдәгәрләр нигездә мануфактура, галантерия, колониаль товарлар, тәм-том, тире, ат иярләү өчен кирәк-ярак, җиләк-җимеш, йон һәм аяк киемнәре белән сәүдә иткән. Сембер ярминкәсе турындагы хисапта татарлар сата торган аяк киемнәренең байлыгы турында языла. Бохара товарлары белән Әстерханнан килгән әрмән һәм татарлар сәүдә иткәнлеге, әмма милләттәшләребезнең аеруча күп булып, күбесенең ярминкәдә берничә лавка тотуы теркәлә. А.В.Ястребов үз истәлекләрендә: «Зур Саратов урамында подвалчылар тезелеп киткән. Көньяктан китерелгән, папирос кәгазенә төрелгән җиләк-җимешне алардан сатып алырга мөмкин. Болар белән татарлар сәүдә итә», – дип искә ала.

1860 нчы елларда шәһәрдәге беренче гильдия өч сәүдәгәрнең барысы да татар булганлыгы мәгълүм. Курамша Абдулла улы Акчурин, Хәсән Сөләйман улы Акчурин һәм Исхак Измаил улы Алеевларның даны чит төбәкләргә дә тарала. XIX гасыр ахыры-XX гасыр башында Сембер шәһәрендә, Акчурин һәм Алеевлардан кала, Абушевлар, Агишевлар, Алимов, Бәхтиевләр, Хөсәеновлар, Гафаровлар, Галиевләр, Коләхмәтов, Мангушевлар, Сәет-Шәкуловлар, Тенишевләр, Хәмидуллин һәм башка шактый зур мал-мөлкәткә ия татар байлары яши. Бу эшкуарларның күбесе Лосевая

Сембернең беренче Җәмигъ мәчете

урамында яки сәүдә урыннарында үз йортларында яшәп, Сембердәге татар мәхәлләсе үсешенә сизелерлек йогынты ясаган.

Сембер губернасында татар эшмәкәрлегенең иң уңышлы тармагы сукно сәнәгате була. Иң беренче татар сукно фабрикасы 1849 елда Карсун өязендәге Зөябаш авылында Сөләйман Акчурин тарафыннан ачыла. Россиянең төрле шәһәрләрендә һәм чит илләрдә сатылган сукно, хәрби кием, одеал һәм башка әйберләр Акчуриннарга саллы гына мал-мөлкәт китерә. Алар бу акчаның шактый өлешен татар мәдәнияте үсешенә – мәчет һәм мәдрәсәләр, китапханәләр салуга, газета-журналлар, китаплар чыгаруга сарыф итәләр. 1870 нче елларда Сембернең шәрәфле гражданнары Акчуриннар губерна һәм шәһәр тормышында актив катнаша, Земство управасы, Дәүләт банкының Сембер бүлеге, Кредит ширкәте идарәсе эшләре белән шөгыльләнә башлый.

XX гасыр башында Акчуриннар, Алеев һәм Хөсәнов кебек атаклы татар сукночылары сафына Б.Ш.Юсупов, А.А.Агишев, Х.Ф.Терегулов, У.А.Килдиевләрнең фабрикалары өстәлә. 1907 елда «Сукно фабрикантлары җәмгыяте»нең әгъзалары арасында иң уңышлы татарлардан И.К.Акчурин һәм Т.К.Акчурин ширкәте вәкилләре, Ю.С.Акчурин, Х.Б.Сәет-Шәкулов, А.К.Агишев, Алеев фабрикасы администрациясе вәкилләре, Х.Ф.Терегуловлар да була. 1911 елда 46 иң эре фабрикантны берләштергән «Россия сукно фабрикантлары җәмгыяте»нә С.Ш.Бәхтиев тә килеп кушыла. Бу







фабрикалар барысы да авыл җирлекләрендә эшләп, шәһәр һәм авыл мәдәнияте үсеше өлкәсендә зур эшләр башкара. Губернада эшчеләр саны буенча иң зур сукно фабрикасы Акчуриннарныкы була. Анда 2500дән артык кеше хезмәт итә.

Сукно фабрикаларыннан тыш, И.А.Алимов, М.М.Тенишев һәм Х.Г.Коләхмәтовның сабын кайнату, Акчуриннарның һәм Тенишевләрнең урман кисү, чуен кою заводлары да барлыкка килә. Эре җирбиләүчеләр сафына И.Х.Алиев, Ш.Г.Муллиннар да өстәлә.

1909 елда татар сәүдәгәрләре Сембер Шәһәр Думасында да күренә башлый. Х.Х.Әсәнович, К.Ш.Абушаев, Ш.Г.Гафаров, И.К.Акчурин, З.С.Бәхтиев, А.К.Гафаровларның шәһәр үзидарәсендәге тырышлыгы нәтиҗәсендә милли проблемалар хәл ителә: 1912 елда мәктәп өчен урын тәгаенләнә, 1915 елда хәләл ит сатар өчен сәүдә рәтләре булдырыла, 1917 елда мөселман мәктәбе ачыла.

Я.Т.Акчурин Фабрика эшләре буенча губерна җыены, Мөбин һәм Мөхәммәдҗан Тенишевләр Сембер банклары идарәсе әгъзаларыннан санала. Шул ук фамилияле ир-атлар (Агишев, Акчуринннар, Бәхтиев, Сәет-Шәкулов) һөнәри җәмгыятьләрдә дә әгъза булып, губерна сәнәгате үсешенә үзләренең тәкъдим-фикерләрен кертүгә ирешә. Татар сәүдәгәрләре мөселман хәйрия җәмгыятьләре эшендә актив катнашып, аларның ярдәмендә күп кенә социаль мәсьәләләр дә хәл ителгән. Әйтик, 1897 елда Сембердә татарлардан 136 ир-атның һәм 10 хатын-кызның иганәчеләр акчасына көн күрүе мәгълүм.

Сембер татарлары арасында затлы нәсел вәкилләре – морзалар да булган. Шуларның берсе Тенишевләр, чукынып, дворянлык титулын һәм башка төрле өстенлекләрне саклап калалар. XX гасыр башында Сембер губернасының дворяннар кенәгәсенә татарлардан нибары өч фамилия – Алеевлар, Шәриповлар һәм Исхаковлар гына теркәлә. Поручик Кармалей Исхаковның дворянлык титулын тугры хезмәте һәм төрле сугышларда, шул исәптән 1812 елгы Ватан сугышында батырларча катнашканы өчен алганлыгы мәгълүм.

Сембердә Уфа морзалары Әмир Солтанаев, Габдулла Еникиев, Виленски морзасы Хәсән Әсәнович та яшәгәне мәгълүм. Морзалар, матди яктан хәлле булып,

Сембернең икенче Җәмигъ мәчете

үзләренең җәмгыятьтәге дәрәҗәләре, рус телен камил белүләре һәм губернаның үзәк оешмаларында вәкил булулары белән дә башка милләттәшләреннән өстен торган. Мәсәлән, А.С.Еникеев – губерна секретаре, аның улы И.А.Еникеев – Финанс министрлыгының казна палатасында регистратор, Х.Х.Әсәнович Шәһәр Думасы вәкиле һәм шәһәр идарәсе карамагындагы училищелар комиссиясе әгъзасы булып хезмәт иткән. Семберле Мөбин Еникеев һәм указлы мулла кызы Мәрьям Гафарова-Еникеевалар да дворяннар буларак теркәлгән.

***

XX гасыр башында шәһәрнең төньягында – Кирпеч сарайлары, мөселман зираты тирәсендә дә татарларның саны арта һәм икенче мәхәллә мәчетен оештыруга ихтыяҗ туа: 105 хуҗалыкта 267 ир-ат яши. Беренче мәхәлләдән аермалы буларак, биредә элекке шәһәр татарларының нәселе түгел, ә яңа гына авыллардан күчеп килгәннәр яши. Мәчет төзелгәнче, гает һәм җомга намазларын Мөхәммәтсабир Ибраһимовтан арендага алынган йортта укыйлар. Йорт хуҗасын указлы мулла итеп тә сайлап куялар. Сембер шәһәрендәге 1915 елда нигез салынган икенче мәхәллә мәчете, Беренче Бөтендөнья, аннан соңгы Гражданнар сугышы сәбәпле шактый озакка сузылып, 1922 елда гына төзелеп бетә. Мәхәллә халкының хәләл акчасына салынган гыйбадәтханә 1930 елда ябылып, бинасы дәүләт оешмалары өчен тартып алына. ■

# «СИБИРИЯ» ГАЗЕТАСЫНДА

## *Томск шәһәре татарлары тормышы*

1912 елның 18 февралендә Томскида чыга башлаган «Сибирия» газетасы Себер һәм Идел-Урал буйларында яшәүче татарларны рухи-мәдәни берләштерүче үзәккә әйләнә. Газета турында Исмәгыйль Рәмиев альбомыннан менә ниләр укырга мөмкин: «Пограммасы турында гәзит редакциясе: «Сибириядә беренче мәртәбә чыккан татарча сәяси, иҗтмагый, икътисади, әдәби һәм милли «Сибирия» гәзитәсе укучыларын дөньяның һәр тарафындагы вакыйгалар илә таныштырачагы кеби, Сибирия җирләренә тагын да күбрәк әһәмият бирәчәктер. Аеруча Сибириянең икътисади, гомуми хәлләреннән хәбәр бирәчәк, күчү эшләре илә таныштырачактыр. Уку-укыту эшләренә дә бик чыннан әһәмият биреп, дәрес китаплары, программалар тугрысында фикер йөртеп, тәнкыйтьләр басачактыр. Гәзитәдә «Хатын-кыз дөньясы» бер баб (рубрика) булып, бунда хатыннарның тәрәккыйсенә, аларның хакларын химая кылырга ярдәмләшә торган мәкаләләр язылачактыр. Бу җәһәттән «Сибирия» – Русия мөселманнарының бердәнбер гәзитедер», – ди. Бик гади генә гәзит булып дәвам итте. Урта кулда, дүрт битлек, атнасына 2-3 тапкыр чыгып торды. Кәгазе яхшы, хәрефләре яңа, техникасы ярыйсы ук матур. Эшләнүе Томскида «Себердә матбугат эше товарищество типо-литографиясе»ндә. Мөхәррире һәм нашире Вәгыйз Нәүрүзов булып, беркадәр вакытлар Фатыймаи-Фәридә Нәүрүзова карамагында чыкты» [1].

№ 96

Газета „СИБИРІЯ"

Первая газета въ Сибири

„СИБИРІЯ"

Цѣна 5 руб. въ годъ.

Томскъ, редакція „СИБИРІЯ"

Russie, Tomsk, redaction „Siberie"

سيبيرده برنچی غزيته

«سيبيريا»

«Сибирия» газетасының бер саны һәм басманың үзенә реклама

Газетаның үзендә басманың «Себердә беренче һәм бердәнбер татар гәзите» икәнлеге, аның чәршәмбе, җомга, якшәмбе көннәрендә чыкканлыгы әйтелә. «Сәяси, икътисади, әдәби вә милли гәзитә»дә «Хатын-кыз дөньясы», атналык сәясәт, «Сибирия»нең фельетоны, «Дахили (эчке) хәбәрләр», «Сибириядә», «Томски хәбәрләре» кебек рубрикалар бар.

Тәүге санда баш мөхәррир Мөхәммәдвәгыйз Нәүрүзовның «Сибирия мөселманнары

---

[1] Рәмиев И. Вакытлы татар матбугаты (Альбом). 1905-1925. – Казан, 1926. – Б.27-28.

өчен татар телендә бер гәзитәнең кирәклеге, «Сибирия» гәзитенә рөхсәт алу, гәзитә булуны теләүчеләр һәм булмауны теләүчеләр, «Сибирия» гәзитенең максат вә мәсләге, програмы, дәвамы» дигән саллы исем белән күләмле мәкаләсе басылып чыга. Аның беренче юлларында ук автор укучыларда милли горурлык уятырга тели: «Сибирия мәмләкәте – дөньяны тетрәткән каһарман бабаларымызның бишеге, – дип яза ул һәм газета чыгаруның актуальлеген искәртеп. Бу көндә Сибириядә бик күп мөселман булындыгы җәһәтлә, шул мөселманнарның дин вә тормышларына иң зарур булган нәрсәләрдән бәхәс итә торган татар телендә бер гәзитәнең булуы бик тиеш булса кирәк. «Сибирия» максаты татар милләтенә хидмәт итмәктер», – ди[2]. Шул ук мәкаләдә газетаның дәвамы өчен Томск, Себер һәм Россиянең Европа өлешендә яшәүче «мәгарифпәрвәр» байлардан 50шәр сум акча җыеп, «Мәдәният» исемле кечкенә ширкәт ясалганын да беләбез. Газетаның «материальный ягы» белән могтәбәр сәүдәгәрләрдән Мифтахетдин Бохараев идарә иткән.

Истәлекләрдә «Сибрия»нең нигездә Вәгыйз Нәүрүзовның хатыны Фатыймаи-Фәридә идарәсендә чыгуы турында әйтелә. Г.Хәбиров мөхәррир ханым турындагы хатирәсендә: «Бу 16 ай эчендә аның эшләгән эшләрен ир кеше дә эшли алмас. Ялгызы идарә итә, кызлар мәктәбендә укыта, газета эшен башкара, хезмәтчеләр өстеннән карый, матбугат йомышларын үти, почта һәм башка эшләрне үзе йөртә, газетага мәкаләләр яза, газеталар укый, килгән хат, мәкаләләрне укый вә башка һәртөрле эшләрне эшли иде. ... Хәтта соңгы баласы туган көнне иртән сәгать унда газетага мәкалә язып бирде», – дип искә ала[3].

Томск шәһәрендә 145 саны чыкканнан соң, Вәгыйз Нәүрүзов редакцияне Уфага күчерә һәм газета 1913 елның августыннан «Тормыш» исеме белән чыга башлый[4].

«Сибрия» газетасы Томск татарларының иҗтимагый-мәдәни тарихын өйрәнү өчен алыштыргысыз чыганак булып тора. Аның сәхифәләрендә шәһәрдәге татар байларының тормышы, хәйрия җәмгыяте, театр, мәктәп-мәдрәсәләр эшчәнлеге тәфсилле яктыртылган.

Игътибарыгызга әлеге газетада дөнья күргән язмаларны тәкъдим итәбез.

## Томски хәбәрләре

Томски педагогический советның мөгаллим вә мөгаллимәләргә картоннардан төрле нәрсәләр ясау эше илә танышыр өчен ясалган комиссиясенең 16 гыйнварда җыены булды. Җыенга егерме бишләп мөгаллим вә мөгаллимәләр килгән иделәр, мәзкүр кул эше белән танышыр өчен 18 мөгаллимә (*учительница*) язылды. Арада бер мөслимә дә бар[5].

*Сибирия. – 1913. – 20 гыйнвар.*

***

Томски сәүдәгәрләреннән мирза Аплин һәм Садыйк Ишуков әфәнделәр бер җирдә кунакта булганда, араларында ихтилаф чыгып, Аплин Садыйк әфәндегә кул илә һөҗүмдә булынган икән. Садыйк әфәнде эшне хөкемгә тартып, 9 гыйнварда 5 нче мировой судьяда эшләре каралды. Суд Аплинны, кул илә һөҗүм итүдә гаепләп, ун көн хәбес (*арест тотарга*) итәргә хөкем иткән, диеп хәбәр итәләр.

*Сибирия. – 1913. – 23 гыйнвар.*

---

[2] Нәүрүзов М. Сибирия мөселманнары өчен... // Сибирия. – 1912. – 18 фев.
[3] Хәбиров Г. Татар хатыннарының якты йолдызы сүнде // Тормыш. – 1914. – 19 фев.
[4] Фатыймаи-Фәридә 1914 елда Томскидан үпкә чире белән кайтып, 25 яшендә Бөгелмә өязенең Кәрәкәшле авылында вафат була. Аның тормыш юлы һәм «Сибирия» газетасындагы эшчәнлеге Альта Мәхмүтованың «Вакыт инде, без дә торыйк...» исемле китабында тәфсилләп бәян ителә. Шунлыктан, биредә кабатлап тормыйбыз.
[5] Бу мөслимә Фатыймаи-Фәридә булырга тиеш.

Томск шәһәре татарларының иҗтимагый-мәдәни тормышы кайнаган урын - XX гасыр башында төзелгән мәчет һәм мәдрәсә

## Мәхәллә җыены

Хәмзә хәзрәтнең[6] җомгада чакырып куюы буенча, 1 февраль, якшәмбе көн таш мәктәптә мәхәллә халкының җыены булды. Халык күп иде. Җыенга Хәмзә хәзрәт рәислек итте. Каралачак нәрсәләр: Романовлар бәйрәменә катышу һәм мәсҗедкә попечитель сайлау иде.

Мәҗлесне ачу илә Хәмзә хәзрәт үзенә Духовный Собрание тарафыннан 21, 22 нче февральләрдә бик тантаналы сурәттә догалар кылырга, бәйрәм итәргә кушып язу килгәнен сөйләде вә ни рәвештә бәйрәм итәргә киңәш сорады. Кайбер кешеләр бәйрәм көн мәсҗедтә җыелып дога кылганнан соң, мөселманнарның вәкилләре парад ясала торган җиргә барырга вә шунда мөселманнар үзләрен күрсәтергә тиеш, дисәләр дә, икенче фирка күп халык арасына кушылсак, күренми калырмыз, шуның өчен бөтенләй аерым бәйрәм итик, диделәр.

«Тәрәккыйюн ислам» (*хәйрия*) җәмгыятенең рәисе Нурулла әфәнденең тәүсыясе (*киңәше*) буенча, мәзкүр (*әлеге*) җәмгыятькә кушылып, мөселманнар аерым бәйрәм ясарга карар бирделәр. Бәйрәм шул рәвештә булачак: әүвәл мәсҗедтә җыелып падишаһ хәзрәтләренең һәм падишаһ гаиләсенең сәламәтлеге өчен, вафат булган Романовларның истирахәт рухы өчен дога кылыныр. Догадан соң, «Тәрәккыйюн ислам» җәмгыяте илә берлектә, таш мәктәптә бер торжественный заседание ясап, анда халыкны Романовлар тарихы илә таныштырылыр. Вә, мөмкин булса, верноподданнический телеграм җибәрелер. (Дога мәҗлесендә вә заседаниедә губернаторны да булындыру өчен, мәҗлесләрне русларның парадына туры китермәскә тырышу тиешле күрелде.)

Соңра Романовларның исемен калдыру өчен, берәр мөәссәсә (*оешма, җәмгыять*) ясарга кирәклек мәсьәләсе кузгалды. Халык беравыздан татарча-русча бер көтепханә (*китапханә*) һәм кыйраәтханә (*уку йорты*) ачып, аны Романовлар исеме илә исемләргә карар бирделәр.

[6] Томск губернасы ахуны Хәмзә Хәмитов, атаклы Кәрим байның абыйсы.

Томск шәһәренең Татар урамында «Сибирия» газетасы урнашкан бина

Карарны губернаторга ирештерергә Хәмзә хәзрәткә тапшырылды.

Азакта мәсҗедкә попечительләр сайлау мәсьәләсе кузгалып, бөтен халык беравыздан Томскиның тәрәккыйпәрвәр (*алдынгылыкны, яңалыкны сөюче*) сәүдәгәрләреннән Сәмирхан әфәнде Юнусовны сайладылар.

*Сибирия. – 1913. – 13 февраль.*

## Җәмгыять файдасына сеанс

Иртәгә 16 февральдә «Мир» электро-театрында «Тәрәккыйюн ислам» җәмгыяте файдасына сеанс биреләчәктер. Антракт вакытларында милли күңелле оркестрымыз тарафынан төрле милли көйләр уйналып торачактыр. Мөселманнар үз җәмгыятемез файдасына булган бу сеансны карарга күбрәк барырга тиешле.

*Сибирия. – 1913. – 15 февраль.*

## Рөхсәт итмәү

«Тәрәккыйюн ислам» җәмгыятенең үз бинасы булмаганга, күп вакытны гомуми җыеннар өчен квартирга мохтаҗ буладыр. Әлегә кадәр мәдрәсәдә җыелсалар да, бу соң вакытларда мәктәп-мәдрәсә начальствосы анда җыелудан манигъ итә (*тыя*) башладылар. Җәмгыятьнең рәисе, инспекторга мөрәҗәгать итеп, 21 февраль көнне җәмгыять, торжественный җыенып, мәсҗед янындагы мәктәптә ясарга сораса да, инспектор, рөхсәт итә алмыйм, дип язу төшергән.

*Сибирия. – 1913. – 15 февраль.*

***

Министрлар мәҗлесенең Томски университетындагы тыйббия (*медицина*) шөгъбәсенә (*бүлегенә*) сибирячка кызларны кабул итү тугрысындагы карары падишаһ хәзрәтләре тарафыннан тасдыйк ителгән (*расланган*). Ләкин монда христиан динендәгеләр генә кабул ителәчәкләрдер.

*Сибирия. – 1913. – 17 февраль.*

«Сибирия» газетасының мөхәррире, мөгаллимә Фатыймаи-Фәридә Нәүрүзова

***

Томскидагы кичке курсларның попечительләре, 10 мартта җыелып, членнарны яңадан сайлыйлар. Бу курсларда урта мәктәп дәрәҗәсендә дәрес биреләдер. Бу ел ул курсларда мөселманнардан да алты кеше дәрес тыңлый. Ләкин Томскиның үз егетләреннән бары бер генә кеше бар. Калганнары бар да читтән килеп торучылар.

*Сибирия. – 1913. – 10 март.*

### Томскида Сабан туе

Көн бик матур иде, һава, бераз кызу булып, битләрне карайтса да, яңгыр булып пычратмагач, халык бик шатланды. Кирәк үземезнең мөселман халкы, кирәк руслар былтыргыга караганда бик күп артык барганнар иде. Саф файда – 900 сум 25 тиендер[7].

Бу елгы Сабан туена губернатор урынына калган вице-губернатор Загражский җәнаплары, Гарби (*Көнбатыш*) Сибирь матбугатының мөдире Виноградов вә башка зур мәэмүрләр (түрәләр) бар иде. Загражский җәнапларына чәй, фрукта тәкъдим улынды. Чәй вакытында милли музыка уйналды. Вице-губернатор биш сәгать кадәр калды. Чәй вакытында мөселманнарның уку эшләрен сорашты. Бу бәйрәмнән бик мәмнүн (*канәгать*) калдыгын белдерде.

Програмда күрсәтелгәнчә, сәгать 12дә музыка уены башланды. Сәгать бердә велосипедта ярышлар башланды. Башка узышлар вә ярышларның һәркаюсы үз тәртибе илә дәвам иттеләр. Велосипед узышында беренче заездның беренче призы – Вражовка, 2 нчесе – Черногривовка, 2 нче заездның беренчесе – Тамашкевичка, 2 нчесе – Теплицкийга, 3 нче заездда беренче – Мамаевка, икенчесе Куликовка бирелде. Беренче заезд ипподромны – 3 кат, 2 нче – 2 кат, 3 нче бер кат әйләнде. Фәкать мөселманнардан ярышка катышучы егетләр булмады.

Атлардан: беренче ярышта – Аплин юртагы, 2 нчедә – Масков юртагы, 3 нчедә (*чабышта*) Кирәк авылының Шиһап Шәрәфетдинов дигән кешенең йөгереге узды. Җәяүле йөгерештә зурлардан Кирәк авылының Шиһап Шәрәфетдинов узды. (Аты да узган иде.)

Капчыкта – Шәһидуллин, балалар узышында Галимов беренче килделәр.

Көрәшләрдә: азиатский көрәштә – ломовой извозчик Шакир Мөхәммәтдинов – беренче, Кукушкин Андрей икенче приз алдылар. Русско-швейцарскийда – Кислицин – беренче, Габдрахман Еникиев («Аю») икенче приз алды. (Ләкин монда низаг чыкты: Кислицин бер кат егылган иде, низаглашып, көрәшкә кереште. Ахырда да «Аю»ны ачык ега алмады. Шулай була торып, тавышны озакка җибәрми хәл кылдырган өчен, Габдрахман әфәндегә рәхмәт әйтми узарлык түгел.)

[7] Шәһәрләрдә революциягә кадәрге Сабан туйлары түләүле булып, аннан кергән акча хәйрия җәмгыятенә бирелгән. – Ред.

Французкийда беренче – «кара маска», икенче – Муравский, 3 нче Самойлов булды. Авырлык күтәргәндә беренчесе – Денисов (бер кулы илә 4 пот, икесе илә 5 ярымны күтәреп, кулын тугры тотты), 2 нче Лихачев, 3 нче Ягушин булды.

Сабан туенда хезмәтне өстләренә алучылар яхшы үтәүләре сәбәпле, бу ел бик тәртипле чыкты. Якында бакча булмау сәбәпле, сандугач тавышлары ишетелмәсә дә, аларның хезмәтләрен абыстайларның яшь балалары үтәделәр. Көн буе туктаусыз сайраганнары булды.

Үткән елгы кебек Сабан туена катышмый калучылар бик аз булды, бармак илә санарга да җитми. Шаһи хаҗи илә Ибраһим Исхаков Сабан туен сораучыларга: «Без андый эшкә (гөнаһлы дигән сүздер) катышмыймыз», – дигәннәр. Хәтта Шаһи хаҗи, җәмгыятьнең рәисенә бу эш артыннан йөргән өчен, җәһәннәм төбенә китәчәген белдермештер. Хаҗи әфәнде угылларын да Сабан туена катыштырмаячагын сөйләп куйса да, зур угылы – мөхтәрәм Шәһидулла әфәнде семьясы илә барган иде. Ибраһим байның да угылы Габдулла әфәнде бик ныклап хезмәт итеп йөрде. Хөсәен әфәнде Измайлов та билетлар сатышып күп хезмәт итте.

Газетамызның баш мөхәррире главный контролер-ревизорлык хезмәтенә куелганга, җитмәсә, килгән бөек кунакларны каршы алу, аларны хөрмәт итү аның өстенә йөкләнгәнгә, Сабан туенда кирәкле мәгълүматны вакытында җыярга мөмкин улмады. Махсус мөхбиремез дә ишек төбенә билетёрлыкка куелу сәбәпле, һичнәрсә күрә алмады. Шуның өчен дә атлар, велосипед, җәяүлеләр ярышының минутлары күрсәтелмәде. Тиешле кешеләрдән мәгълүмат җыелып җитмәде. Бинаән галәйһи (*шул сәбәпле*), шулкадәр язу илә канәгатьләнәмез.

Алла кабул итсен.

*Сибирия. – 1913. – 26 май.*

## Томскида беренче мәртәбә театр

Томски мөселманнары ирләр, кызлар мәктәбенә, гыйльми-икътисади җәмгыятькә, газетага ия булдыклары хәлдә, ничә еллардан бирле үз телемездә әдәбият, музыка кичәләре ясарга, театр уйнарга рөхсәт алырга мөмкин улмады. Рөхсәт бирелмәве хөкүмәттән улмыйча, бәлки Томски мөселманнарының дин башлыгы булган карт мулланың һиммәте (*тырышлыгы*), аның яман уе илә булмый кала иде. Ниһаять, бу мәсьәлә дә чишелде. Газетамызның мөхәррире Мөхәммәтвагыйз әфәнде, губернатор урынында калган вице-губернатор Загражский җәнапларына, Томски мөселманнарының хәлләрен ачык аңлатып, театр уйнарга үзен мәсьүл (*җаваплы*) итеп, рөхсәтне алды. 8 июльдә Коммерчески собраниедә «Нур» труппасы тарафыннан Г.Камал әфәнденең әсәрләреннән «Бәхетсез егет» илә «Беренче театр» исемле әсәрләр уйналды. «Нур» труппасы «Сәйяр» труппасыннан аерылган ике кыз вә ике ир артистлардан гыйбарәт – барысы дүрт кешедер. Әдәби кичәләргә мохтаҗ булган Томскиның ачык фикерле сәүдәгәрләре, яшьләре мосафир артистларны хөрмәт илә каршы алдылар. Сәүдәгәрләр билет сатып, яшьләр исә рольләрне уйнарга өстләренә алдылар һәм мөкәммәл сурәттә бурычларны үтәделәр. Яшьләрдән катышкан егетләр: Л.Бохараев, Х.Янгуразов, Ж.Измайлов, Фәтхетдинов Шәйхи, Газиз әфәнделәр. Яшьләр үз рольләрен бик яхшы уйнадылар. Суфлер да яшь сәүдәгәрләрдән Ибраһим әфәнде Таҗетдиновтыр.

Театрда мөселманнар бик күп, руслар, марҗалар да бар иде. Театр бик муаффәкыятьле (*уңышлы*) чыкты. Театрда үзләрен яхшы тота белүләре илә Томски мөселманнары үзләренең чын мәгънәсе илә мәдәниятькә аяк бастыкларын беренче мәртәбә уйналган театрда беренче мәртәбә күрсәттеләр. Бары берничә шаян бала гына, беренче, икенче рәтләрдәге кеше урыннарына утырып, урын ияләрен урынсыз калдырдылар. Киләчәктә

бу кимчелекләр дә бетәр. Театр халыкны бик шатландырдыгы кеби, антракт арасында яшьләр тарафыннан милли музыкада милли көйләрнең уйналуы да артык шатландырды.

Хәзергә кадәр бозык уеннарда гына уйналган милли музыканың, иске замандагы кайгыларны аңлаткан озын көйләрнең скрипканың нәзек кылларыннан сызылып чыгуы халыкны мөтәэссир (*әсир*) итте. Мәдәнияткә аяк басылуын белдергән кыска шатлыклы көйләрнең залның диварына бәрелгән дулкын тавышлары халыкны җанландырды. Милли уен күрергә мохтаҗ булган Томски өчен бу көн – тарихи көн булып калачактыр. Бүгенге шатлыкның тәэсире һич онытылмаячактыр. Халык, милли артист вә яшьләргә, милли музыка уйнаучы әфәнделәргә рәхмәтләр укып, төнге сәгать бердә генә таралдылар. Тагы да ешрак милли уеннарның булуын теләдекләрен белдерделәр. Икенче уен яңа ачылачак мөселманча-русча акчасыз көтебханә-кыйраәтханә (*китапханә-уку йорты*) файдасына улачактыр.

Бер күңелсезлек булса ул да: «Нур» труппасының икегә бүленеп, бозылышып, Томскига килүләредер. Соңыннан килгән Мохтар әфәнде Мутин вә дүрт иптәшенең уенга катыша алмаулары һәм дә театр көнендә иске иптәшләре тарафыннан уйналган театрны күрергә кертелмәүләредер. Милли артист вә артисткаларның талашып йөрүләре, халыкка үрнәк күрсәтердәй урында таралып йөрүләре, корылган «милли труппа»ның югалуына сәбәп улачак начар хәрәкәтләре өчен, «Сибирия» газетасы хәзергә тәэссефне (*кызгануны*) белдереп, киләчәктә сәбәпләрне дә тикшерүне үзенә бурыч дип беләдер.

*Сибирия. – 1913. – 10 июль.*

## Мәшһүр мөстәшрикъ (востоковед) профессор Бартольд

Петербург дарелфөнүненең (*университетының*) шәрык телләре шөгъбәсендә (*бүлегендә*) профессор Бартольд җәнаплары үзенең теләве буенча гыйльми бер максат илә сәяхәт итмәк өчен, май урталарында Петербургтан чыкмыштыр. Башкортлар арасында, Эстәрлебашта булмыштыр. Аннан соң Оренбург, Уфа калаларында калып, мөселманнарның әдәбиятлары, бүгенге мәдәнияткә якынлашулары илә танышмыштыр. Мөхтәрәм профессор Бартольд 14 июньдә Томскига килде. «Сибирия» газетасы редакциясен зиярәт итте. Сәгать ярым кадәр утырыштык.

Мөселман дөньясының киләчәге хакында Бартольд җәнапларының фикерен сорадым. Шул җавапны бирде: «Мөселманнар бик тизлек илә Яуропа мәдәниятен кабул итәргә тиешледер. Мәдәният саясендә мөселманнар үз урыннарын саклый алырлар. Әгәр бу форсатны да качырсалар, мөселман дөньясының киләчәге куркынычлыдыр, чөнки дөньядагы һәр милләт үзенә, үзенең мәдәниятенә таянып кына яшидер. Мәдәният җәһәтеннән түбән урын тоткан милләт иң әүвәл икътисади җәһәттән әсир буладыр. Икътисади җәһәтнең яхшы булуы өчен, гыйльме һөнәр шарттыр. Мөселманнар гыйльме һөнәр җәһәтеннән бик түбән урын тотканга, икътисади җәһәтләре зәгыйфьтер».

Бартольд җәнаплары, Томскида 3 көн калганнан соң, Красноярски, Иркутски калаларына барып, берничә көн калачактыр. Томскида әллә никадәр гыйлем йортлары ула торып, музейның улмавына тәгаҗҗеб итте (*гаҗәпләнде*).

Мөхтәрәм Бартольд җәнапларының аягы җиңел булсын да, татарлардан җитешкән әһле гыйлем дә (*укымышлылар*) Сибириягә сәяхәт итсен.

*Сибирия. – 1913. – 16 июнь.*

*Текстларны басмага* ***Рәйсә Шәрәфиева***
*һәм* ***Ленар Гобәйдуллин*** *әзерләде.* ■

# Томскида татар театры тарихы

Надежда Савельева*

*XX йөз башында, Россия империясенең башка шәһәрләрендәге кебек үк, Томскида яшәүче татарлар да яңарыш кичерә. Томск өлкәсе Дәүләт архивының Губерна идарәсе фондында мөселманнарның «Тәрәккыюн ислам» җәмгыяте ачарга теләп язган гаризасы һәм әлеге җәмгыятьнең устав проекты саклана. Рәсми документны имзалаучылар арасында шәһәр башлыгы И.М.Некрасов, Ф.С.Сәйдәшев, М.М.Сәгыйтов, В.Нәүрүзов һәм К.М.Хәмитовлар бар. Җәмгыять Томск губернасы мөселманнары арасында мәгърифәт-белем таратуны: мәктәпләр төзү, укытучыларны укыту, мәктәпләрне китаплар, экспонатлар, таблицалар, картиналар һәм дәреслекләр белән тәэмин итүне максат итеп куя. Ул китапханәләр һәм уку йортлары, мөгаллим һәм мөгаллимәләр өчен курслар ачарга, музейлар булдырырга, күргәзмәләр оештырырга, әңгәмә-очрашулар үткәрергә, коллектив укулар оештырырга вәгъдә итә. Аның һәр әгъзасы 50 тиеннән 25 сумга кадәр һәм аннан да күбрәк акча кертергә тиеш була. Моннан тыш, җәмгыять ирекле иганәләргә, күчемсез милектән кергән табышның бер өлешенә, китаплар сатудан, түгәрәкләрдән, васыятьләрдән, концерт һәм күргәзмәләрдән дә кергән акчага исәп тоткан.*

«Сибирия» газетасындагы мәгълүматка караганда, Томскида татар телендә беренче профессиональ спектакль 1913 елның 8 июлендә (яңа стиль белән 22 июлендә) Коммерческое собрание бинасында куелган. Ул көнне «Нур» труппасы тарафыннан Г.Камал әсәрләреннән «Бәхетсез егет» һәм «Беренче театр» уйнала. Бу турыда журналыбызның 37-38 битләреннән карагыз. **– Редакция.**

Кызганыч, хакимият әлеге җәмгыятьне ачарга рөхсәт итми. Бу турыдагы карар

*__Надежда Григорьевна Савельева__ – Томскидагы Агач төзелеш сәнгате музее җитәкчесе, төбәкне өйрәнүче.

Эчке эшләр министрлыгы советы әгъзасы Извеков, вице-губернатор, дәүләт милке идарәчесе Князев, прокурор Дубяго һәм шәһәр башлыгы И.М.Некрасов тарафыннан имзалана.

Шуңа да карамастан, 1909-1917 елларда «Тәрәккыюн ислам» җәмгыяте томь татарлары арасында аң-белем, дөньяви мәдәниятне таратуда сизелерлек роль уйный. 1914 елгы мәгълүматларга караганда, Томскида биш мөселман башлангыч мәктәбе булган, шул исәптән 2 хатын-кыз мәктәбе, өлкәннәр өчен кичке ирләр курслары оештырылган, татар телендә «Сибирия» газетасы дөнья күргән. 1916 елда Большая Королевская урамында ачылган татар китапханәсе мәдәни тормышның үзәгенә әйләнеп, биредә театраль һәвәскәрләр түгәрәге дә барлыкка килә.

Гадәттә Томскидагы театр тарихы турында сөйләгәндә, XIX гасыр ахыры-XX гасыр башында эшләгән Королев театрын гына искә алалар. Әмма бу чорда татарларның да театр сәнгате билгеле бер дәрәҗәдә үсеш алган. Ташкентта яшәүче Софья Шакир кызы Бухараева татар театры турында менәниләр язган иде: «Томскиның һәвәскәр мөселман театрында минем әнием уйнады. Артистлар труппасы үзе 1912 елдан бирле яшәгән. Әлбәттә, минем әти-әниләр татар мәдәнияте белән генә чикләнмәде, аларның кызыксынулары шактый киң иде. Без бөтен гаилә белән Томскига килгән башка театрларның гастрольләрендә дә еш булдык».

Томскиның Өлкә татар мәдәнияте үзәге музеенда тышына: «Артисту Томскаго Любителаго Кружка Фахретдину Гаязетдиновичу Морскому (Ибрагимову). Томскій Мусульм. Любит. Кружокъ», – дип язылып, 27 иптәшнең имзасы, 1917 елның 29 июль датасы куелган иске генә калын альбом саклана. Әлеге язуга караганда, альбом «Томск мөселман һәвәскәрләре театры» артистларының фотосурәтләреннән төзелгән һәм әйдәп баручы артист, режиссер Фәхретдин Ибраһимовка (псевдонимы – Владимир Морской) туган көне уңаеннан бүләк итеп бирелгән. Альбомда ялгыз, төркем белән яки ике кеше бергә төшкән фоторәсемнәр дә бар. Мәсәлән, Фәхретдин Ибраһимов артистка Рәхмәтуллина белән «Урман кызы» спектаклен уйнаганда фотога төшкән. 1920 нче елларга нисбәтле тагын бер фотода Фәхретдиннең гимнастерка петлицаларында йолдыз белән ярымай ялтырый. Бу елларда ТАССР Коммунистлар партиясе Үзәк комитетының сәяси агарту бүлегендә эшләүчеләр нәкъ менә шундый билге тагып йөргән икән. Искәртүемчә, альбом 1917 елда төзелгән. Аны Томскида яшәүче Роза Усман кызы Халикова саклап калган. Кызганыч, фотоларның сыйфаты бик начар булу сәбәпле, аларны укучыларга тәкъдим итә алмыйбыз.

1920 елның язында оешкан татар театры, дөресрәге, «Мөселман музыка-театр труппасы» артистлары алдына коммунистик идеяләрне пропагандалау максаты куела. Алар тарафыннан Туктамыш авылындагы Сабан туе сәяси төсмерләр белән уздырыла: «Париж коммунасының соңгы көне» спектакле уйнала, аннан соң «зур уңыш белән» митинг оештырыла, Польша фронтында сугышкан кызылармиячеләрнең гаиләләре файдасына иганә җыела. 1921 елның 18 мартында труппа артистлары Париж коммунасы истәлегенә тагын бер спектакль куя. Өч көннән соң, Татар балалар клубына ярдәм итү өчен, янә бер спектакль уйнала, аннан кергән акча утын сатып алуга тотыла.

1921 елның апрель азагында Губерна комитетының татар-кыргыз бюросы утырышында татар труппасының бер өлешен, «җитәрлек дәрәҗәдә эшләми һәм үз-үзен тотышы канәгатьләндерми», дигән сылтау белән СибОНО (Себер халык мәгарифе бүлеге) карамагына җибәрергә карар кылалар. Калган артистлардан, эшчеләр яшәгән районнарда һәм татар авылларында спектакльләр кую өчен, Күчмә театр труппасы оештырыла. 1921 елның маенда төркем янәдән таркала: җәйге кыр эшләре чорында театр труппа буларак берләшеп эшли алмас, дип, татар артистларын драма түгәрәкләре

буенча бүләләр. Нәтиҗәдә, ай ахырына мөселман труппасы бер генә спектакльне дә сәхнәләштерә алмый, чөнки бу вакытта анда нибары унбер актер гына кала.

Гомумән, Яңа икътисади сәясәт (НЭП) Томск губернасының барлык мәдәни-агарту учреждениеләре эшчәнлегенә дә тискәре йогынты ясый. 1921 ел ахырына Томск һәм губернада булган барлык клублар да диярлек яшәүдән туктый.

1922 елның ноябрендә Томскида татар, украина һәм яһүд секцияләре булган интернациональ клуб эшли башлый. ТомгубОНО һәм РКП(б)ның Томск губерна комитеты җитәкчелегендә сәяси-агарту эшен алып бару мәдәни үзәкнең төп вазыйфасы була. Әмма аның эшчәнлеге бары тик татар һәм украин телләрендә спектакльләр куюга һәм яһүд секциясендә спорт дәресләрен алып баруга гына кайтып кала. Бу эшләрдә сәяси пропаганда җитәрлек булмау сәбәпле, клуб 1923 елның июлендә ябыла.

1923 елның икенче яртысында әдәбият, китапханә, музыка-хор, драма һәм хатын-кызлар белән эшләү буенча махсус секцияләре булган татар мәдәни-агарту җәмгыяте оештырыла. 1923 елның октябрь-ноябрь айларына җәмгыятькә 45 кеше – төрле хезмәткәрләр, эшчеләр һәм укучылар килә.

1925 елның февралендә «Красный строитель» эшче клубы каршында Томск губпрофсоветының татар секциясе ачыла. Татар халкы арасында мәдәни-агарту эшләре алып бару өчен булдырылган әлеге секциядә музыкаль-драматик түгәрәк тә оеша. Алар РКП(б) Губкомының татар бүлеге һәм ГубОНО Совнацменының (Милли азчылык советының) татар халкы өчен оештыра торган төрле чараларында актив катнаша. Мәсәлән, 1925 елның декабрендә үзешчәннәр губернада оештырылган татар матбугаты көннәрендә чыгыш ясый. 1926 елның октябренә секциянең 106 әгъзасы була. Аның карамагында уку залы, татар хатын-кызлары өчен почмак эшләгән. Биредә хатын-кызларны борчыган күп санлы проблемаларга кагылышлы җыелышлар һәм әңгәмәләр үткәрелгән. Томскидагы татар балалар бакчасы эшчәнлеге, балалар тәрбияләү, гигиена турында докладлар да укылып, экскурсияләр дә оештырылган. Шуны да искәртик, бу чорда татар секциясе шәһәрдә бердәнбер милли мәдәни-агарту үзәге булып саналган.

Алда язылганнар Томскидагы татар театры һәм мәдәни тормышыннан кайбер сәхифәләр генә. Әлеге бай тарих киләчәктә җитди тикшеренүне һәм фәнни анализны таләп итә. ■

# *Челтәрле дә бизәкле*

12-13 сентябрь көнне Томскида узган Төбәкне өйрәнүчеләр форумында Россия һәм чит ил шәһәрләрендәге татар бистәләрен төзекләндерү, саклау, өйрәнү һәм туристик объект буларак файдалану мәсьәләсе күтәрелде. Федераль дәрәҗәдәге «Томск шәһәренең Татар бистәсе» дәүләт тарих-архитектура музей-тыюлыгы, бистә нигезендә «Татар базары» проектын төзү буенча дәүләт оешмаларына мөрәҗәгать итү карары фәнни форумның резолюциясенә дә кертелде.

Томск шәһәренең Татар бистәсе һәм заманында мәдәни тормыш кайнаган Татар урамы хәзерге көндә ни хәлдә? Бистә нинди йортлары белән әһәмиятле һәм аларның сакланышы ничек? Журналыбыз хезмәткәре **Ленар Гобәйдуллин** форум вакытында фотоаппаратын алып, Татар бистәсе һәм аның урамнары буенча сәяхәт кылды.

***Фоторепортажның дәвамы тышлыкның 3 нче битендә.***

Кәрим бай Хәмитов йорты. М.Горький урамы, 35 нче йорт. XX гасыр башы

Сәүдәгәр Әхмәдулла Әхмәтов йорты. Татар урамы, 46 нчы йорт. 1902 ел

Сәүдәгәр Мансуров йорты. Татар урамы, 16 нчы йорт. XIX гасыр азагы

Садретдин Агафуров, механик Этторе Гвиццарди һәм принц Боргезе легендар автомобиль Itala белән. 1907 ел

# ЕКАТЕРИНБУРГТАГЫ *«татар кварталы»* һәм сәүдәгәр Агафуровлар

Лариса Коновалова[1]

*XIX гасырның икенче яртысы-XX гасыр башында Екатеринбургтагы татар бистәсе формалашуда әйдәп баручы рольне данлыклы сәүдәгәр Агафуровлар (Габделгафуровлар) башкара. Бөтен Россияне колачлаган сәүдә империясенең башында Казан губернасының Лаеш өязендәге Кече Елга авылы игенчесе Габделгафурның 1831 елда дөньяга килгән улы  Хисаметдин тора. Әүвәлгеләр сөйләвенә караганда, Габделгафурның имана җире бик аз, тормышы гаять авыр, биш кыз баланы тәрбияләргә кирәк була. Шулай итеп, 1855 елда 24 яшьлек Хисаметдин, әлбәттә, билгеле бер хакка, бай күршесе өчен хәрби хезмәткә китә һәм Екатеринбургка барып эләгә. Бирегә хатыны Бибигазизә һәм улы Камалетдинне чакыра, хәрби хезмәт вакытында дөньяви*

[1] **Коновалова Лариса Анатольевна** – Свердловск өлкәсенең О.Е.Клер исемендәге төбәкне өйрәнү музее филиалы – «Агафуровлар йорты» музей-клубы мөдире.
*Мәкалә **Бәдри Девишев** һәм **Рөстәм Бикбов** хезмәтләре нигезендә әзерләнде.*

Агафуровлар гаиләсе үз дачаларында крикет уйный. Уңда – Мәрьям Зәйнетдин кызы

*гыйлем эстәргә, рус телен дә өйрәнергә өлгерә. Хисаметдин 1868 елда унтер-офицер дәрәҗәсендә отставкага чыга һәм шәһәрнең базар мәйданындагы кечкенә лавканы вакытлыча арендага алып, вак-төяк – сабын, шырпы, папирос кәгазьләре белән сату итә башлый. Әкренләп, сәүдә үзәкләрен арттыра: эшләрен Эрбет, Чиләбе базарларында җәелдерә. Әлеге кәсептә аңа өлкән угыллары төп ярдәмче була. Берникадәр вакыттан соң, Хисаметдин Екатеринбург шәһәренең иң бай кешеләреннән берсе – икенче гильдия сәүдәгәр дәрәҗәсенә ирешә.*

Хисаметдин 1883 елда тормышы гөрләп барган мәлдә – 52 яшендә бакый дөньяга күчә. Төзи башлаган йортының да (хәзер бу йортта Татарстанның Даими вәкиллеге урнашкан. – *Ред.* ) беренче катын гына күтәрергә өлгерә. Аның эшен уллары Камалетдин (1853-1922) һәм Зәйнетдин (1861-1924) дәвам итә. Алар, берләшеп, «Бертуган Агафуровлар сәүдә йорты» оештырып җибәрә: Успенская (хәзерге Вайнер урамы, 16 йорт. – *Ред.*) урамында арендага алынган бинада универсаль кибет ачалар. Соңрак бу эшкә энеләре Кәшәфетдин (1872-1935) һәм Камалетдиннең улы Садретдин (1878-1943) да кушыла. Агафуровлар үз кибетләрендә алтын-көмеш әйберләр, сәгатьләр, парфюмерия, аяк киемнәре, канцелярия кирәк-яраклары һәм башка (тулы исемлекне фотолардан кара. – *Ред.*) тауарлар саткан. «Бертуган Агафуровлар сәүдә йорты»ның Пермь, Төмән, Эрбет һәм Томск шәһәрләрендә, соңрак Мәскәү һәм Варшава, Йокогама (Япония) һәм Харбинда (Кытай) конторлары, кибетләре ачыла. Агай-энеләр Германия, Швейцария, Франциягә барып, элемтәләр урнаштырып кайталар. 1913 елга сәүдә йортының тауар әйләнеше елга 6,5 миллион сумга җитә.

Агафуровларның сәүдә фирмасында эшләүче приказчиклар шәһәрдә затлы

Зәйнетдин Агафуровның хатыны Әсма Садрый кызы дачада

Камалетдин һәм Бәдигелниса Агафуровлар

Кәрим Девишев, Һарун Апанаев һәм Садретдин Агафуровлар дачада ял итә

киенгән, мөлаем йөзле, сату-алу эшенә оста, бай һәм кәттә егетләрдән санала. Сәүдәгәрләрнең икътисади, социаль активлыгы нәтиҗәсендә, Екатеринбургта «татар кварталы» формалаша башлый. Агафуровлар якын-тирәдәге йортларны сатып алып, аларны үзләренең туганнарына, сәүдә йортында эшләүче егетләргә арендага яки бүләк итеп бирә. Җиләк-җимеш белән сәүдә итүчеләрнең барысы да диярлек татар милләтеннән булып, алар шул кварталда урнаша. Вәлитовларның сәүдәсе Агафуровларның ярдәме белән үсеп, алар Пермь, Екатеринбург, Верхотурье, Кунгур, Түбән Тагил шәһәрләрендә җиләк-җимеш белән уңышлы гына сәүдә итә башлый. Шулай ук татар бистәсендә бай гаиләләрнең – Богатиев, Бәхтияров, Рәхмәтуллин, Сабитов, Мөхәммәтҗановларның да йортлары була. Шәһәрдәге ике намаз йорты Агафуровлар карамагындагы биналарда булып, мулла белән мәзиннең дә шунда яшәгәнлеге мәгълүм.



Екатеринбургның мәшһүр велосипедчысы Садретдин Агафуров

Бертуган Агафуровлар 20 ел эчендә мәктәп эшенә 100 мең сумнан артык акча тота. Пермь губернасы жандарм идарәсе башлыгының ярдәмчесе Красковскийның 1913 елгы 17 май хисабында: «Екатеринбург шәһәрендә ике ир (2 мөгаллим, 60-70 шәкерт) һәм кыз балалар (2 мөгаллимә, 60-70 укучы) өчен мөселман башлангыч мәктәпләре бар. Аларның икесе дә Зәйнетдин иганәсенә эшли», – дип язылган. Агафуровларның акчасына Түбән Новгород һәм Пермь (1903) шәһәрләрендәге мәчетләр дә салына.

Сәүдә йортының 25 еллык юбилее (1908 ел) хөрмәтенә, хәйриячелектә игелекле гамәлләре һәм иҗтимагый активлыгы өчен, Зәйнетдин Агафуровка Александр тасмасындагы алтын медаль, Екатеринбургның даими мактаулы гражданины исеме бирелә.

1908 елның 9 февралендә Екатеринбургта мөселман хәйрия җәмгыяте оеша. Баштарак Агафуровлар аның идарәсе составына керми, җәмгыятькә әгъзалык хакы җыелып та нәтиҗәле эшләр башкарылмый. Хәйрия җәмгыяте эшчәнлеге Агафуровлар кушылганнан соң, 1910-1911 елларда гына тамырдан үзгәрә. Зәйнетдин Хисаметдин улы Агафуров идарә рәисе итеп сайлана. Бу нәселдән тагын җиде кеше – Камалетдин Хисаметдин улы, Кәшафетдин Хисаметдин улы, Садретдин Камалетдин улы, Нуретдин Зәйнетдин улы, Әсма Садыйк кызы, Сәлия Солтан кызы, Мәрьям Солтан кызы; татар байлары – Фәтхетдин Шәфигулла улы Богатиев, Насыйбулла Хәбибулла улы Бәхтияров, бертуган Рәхмәтуллиннар, Галиевләр дә әлеге җәмгыятькә әгъза булып языла. Агафуровларның чит шәһәрләрдә яшәүче туганнары, Казанда яшәүче Һарун Апанаев та аларга кушыла. Шулай итеп, хәйрия җәмгыяте әгъзаларының саны 116 кешегә җитә.

Революциягә кадәрге Екатеринбургтагы татар рухи тормышын күзаллар өчен, шул чор вакытлы матбугаты һәм хәйрия җәмгыятенең хисабына мөрәҗәгать итик.

● Җәмгыять губерна администрациясеннән Екатеринбургта татар һәм рус телләрендә китаплар, газета-журналлар яздырып ала торган китапханә ачарга

Агафуровларның Төмәндәге сәүдә йорты

Петропавловскія Номера
Ф. М. МАКОВСКОЙ
Телефонъ 142 г. Пермь

Торговый Домъ
„Братья Агафуровы"
оптовый и розничный магазинъ въ г. Перми,
на ТОРГОВОЙ улицѣ, домъ ЭСКИНА
отдѣленіе на Сибирской улицѣ домъ Любимова.
Торговля игольнымъ, галантерейнымъ, порфюмернымъ и табачнымъ товаромъ.

При розничномъ магазинѣ на Торговой улицѣ, имѣются слѣдующія отдѣлы:

Модныя отдѣлки дамскихъ нарядовъ:

Приклады портняжскія.
Форменныя вещи всѣхъ вѣдомствъ.
Рукодѣльныя принадлежности.
Драпировочныя отдѣлки.
Бѣлье мужское дамское и столовое.
Одѣяла разныя.
Ковры, портьеры и шторы.
Парфюмерныя товары рускихъ и заграничныхъ фабрикъ.

Туалетныя и кабинетныя вещи.
Зеркала туалетныя.
Золотыя и серебряныя вещи.
Часы карманныя.
Мельхіоровыя издѣлія.
Дорожныя вещи.
Рыболовныя принадлежности.
Игрушки и игры.
Музыкальныя инструменты въ большомъ выборѣ.

КАНЦЕЛЯРСКІЯ ПРИНАДЛЕЖНОСТИ
складъ граммофоновъ, патефоновъ, пластинокъ, швейныя машины и металлическія вѣнки.
Шляпы дамскія и мужскія. Принимаются заказы.

рөхсәт сорый. Чөнки шәһәрдә меңнән артык мөселман яши, аларның өчтән бер өлеше, ярлы булу сәбәпле, үз телендәге китапларны һәм вакытлы матбугатны яздырып укый алмый. Китапханә Агафуровлар йортында урнашачак.

● 1913 ел, ноябрь. Мөселман мәктәпләрендә укучы ярлы ир һәм кыз балалар өчен кием-салым, аяк киемнәре сатып алырга – 200 сум, акушерлык курсында укучы Ибраһимова өчен – 25 сум һәм ай саен 5 сум тәгаенләнә. 500 сум китапханә оештыру өчен бирелә.

● 1914 ел, 16 декабрь. Идарә әгъзалары җыены вакытында хәйрия җәмгыяте мөселман китапханәсе өчен Пахомов йортын арендалауга елына 300 сум түли.

● 1915 елның 7 февралендә намаз йорты янындагы затлы бинада тантаналы рәвештә хатын-кызлар өчен башлангыч югары училище ачыла. Бинаның бәясе – 20 мең сум.

● 1915 елның 2 маенда хәйрия җәмгыятенең утырышы уза. Иң әүвәле ипподромда җәмгыять файдасына үтәчәк ат чабышы турында сөйләшәләр. Ат чабышының көне 14 майга тәгаенләнә. Аннары җәмгыятьнең сәркатибе М.Әмировның мөселман китапханәсе эшчәнлеге хакындагы доклады тыңлана. Докладтан аңлашылганча, яңа гына ачылган китапханә гаять уңышлы эшли, әмма мөселманнарның ихтыяҗын тиешле дәрәҗәдә канәгатьләндереп бетерә алмый. Сәбәбе – татар телендә язылган китапларның җитешмәве.

Камалетдин Агафуров гаиләсе эмиграциягә киткәннән соң, бу бинада татар-башкорт китапханәсе эшли. 1920 елдан Уралның милли мәктәпләренә укытучылар әзерли торган татар-башкорт курслары оештырыла, йортның икенче катында укытучылар һәм уку бүлмәләре була. Соңрак курслар Татар-башкорт педагогика техникумы итеп үзгәртелә. 1938 елдан – коммуналь квартира. Хәзерге вакытта биредә «Агафуровлар» музей-клубы урнашкан.

● 1915 елның 30 маенда җәмгыять файдасына оештырылган ат чабышларының хисабы басыла. Чиста керем 586 сум 87 тиен тәшкил итә.

● 1915 елның 21 августында Халык күңел ачулар паркында татар телендә хәйрия спектакле куела. Спектакль тамашачыларга ошаган булса кирәк: ике артистка өч затлы букет бүләк ителә. Билет сатканнан кергән акча 176 сум тәшкил итә.

● 1915 елда «Хәрбиләргә һәм аларның гаиләләренә ярдәм итү өчен вакытлы мөселман комитеты» оеша.

Зәйнетдин Агафуров йорты

Зәйнетдиннең хатыны Әсма Садыйк кызы (аның әтисе Садыйк Әбдрәшитов Троицкида атлар заводы белән дан тоткан) мәктәбендә укучы кызлар

Суфия Камалетдин кызы, Мәрьям Солтан кызы, Марзия Камалетдин кызы Агафуровлар

● 1915 елның 5 декабрендә мөселман китапханәсе өчен газета һәм журналлар яздыру мәсьәләсе карала. 1916 елга 6 татар, 5 рус газетасын, 10 татар һәм 5 рус журналын яздырып алырга карар кылалар.

Татар иҗтимагый тормышын кайгыртудан тыш, Агафуровлар спорт үсешенә дә зур өлеш кертә. Аларның актив эшчәнлеге нәтиҗәсендә, Екатеринбургта велосипедчылар һәм ат чабышын яратучылар җәмгыятьләре оеша. 1900 елда Камалетдин Агафуров акчасына заманча велодром төзелә.

Шулай итеп, сәүдәгәр Агафуровларның иҗтимагый һәм хәйрия эшчәнлеге нәтиҗәсендә Екатеринбургның «татар кварталы»нда яшәүчеләр саны арта. Шәһәрнең әйдәп баручы татар зыялылары, шул исәптән ахун Гыйрфан Рахманкулов та алдынгы карашлы, дөньяви белемле, чит телләр белән бергә рус теле һәм әдәбиятын да яхшы белгән игелекле затлардан була.

Илдә совет хакимияте урнашкач, Агафуровлар, Екатеринбургны ташлап, Себергә, Япониягә һәм Харбинга күченә. Камалетдин 1922 елны Иокогамада җир тетрәү вакытында, Зәйнетдин 1924 елда Харбинда йөрәк өянәгеннән, Кәшафетдин 1935 елда Харбинда юл фаҗигасендә һәлак була.

1920 нче еллар ахыры-1930 нчы еллар башында – илне индустрияләштерү сәясәте вакытында Екатеринбургка татарларның яңа дулкыны күчеп килә. 1919-1940 елларда шәһәрдәге татар җәмгыятенең милли-мәдәни тормышы зур үсеш ала. ■

# ЕКАТЕРИНБУРГТАГЫ *борынгы татар зираты*

Төбәкне өйрәнүчеләр форумында катнашучылар 15 сентябрьдә Екатеринбург үзәгендәге татар зиратында булды, мәрхүмнәр рухына багышлап дога кылды. Шунысы игътибарга лаек: 2007 елдан бирле бу каберстанны татар яшьләре тәртиптә тота, аның сакланышын кайгырта. Күптән түгел генә алар зиратны мәдәни мирас объектлары дәүләт реестрына, «Татар бистәсе» туристик маршрутына кертү буенча да хәрәкәт башлап җибәргән.

Зиратка кергәч, гарәби язулы, XX йөз башы кабер ташлары күзгә ташлана. Аларның күбесенә «Күллү нәфсин зәәикатүл-мәүт» («Һәрбер нәфес үлемне татучы»), «Иннә лилләһи вә иннә иләйһи раҗигун» («Барыбыз да Аллаһтан килдек һәм Аллаһка кайтачакбыз») кебек аятьләр язылган. Ташлардан мәрхүмнәрнең туган җирләре турындагы мәгълүматны да укый алабыз. Бу юллар исә Екатеринбургка татарларның кайдан күчеп килгәнлеген ачыклау өчен бер чыганак булып тора.

Арткы рәттә, кара төстәге гарәби язулы: «Әхтәмҗан Әбүбәкер углы Әбүбакиров» (1913 елда вафат); «Гөлбаһар Мирхәйдәр кызы, Әхтәмҗан җәмәгате Әбүбакирова» (1896 елда вафат); «Мөхәммәдзариф Мөхәммәдҗан углы Әбүбакиров (1886-1917)» каберләренә куелган ташлар

«...1883 нче сәнәдә 25 нче октябрьдә Хисаметдин Габделгафур мәрхүм булды. 52 яшендә...»

«...Казан губернасы Әблә карьясенең Екатеринбург мишчаны Сәгдетдин Фәйзулла углы...» 77 яшендә вафат

«...Малмыж өязе Арбор волосте Түбән Сосна авылының Мөхәммәттаһир Самат углы...» 1884 елда вафат

◄ Атаклы Тынкачевлар нәселенең дә бер вәкиле биредә җирләнгән

Свердловск (хәзерге Екатеринбург) шәһәреннән Бөек Ватан сугышына киткәннәрнең дә күбесе Татарстаннан булган

Киселгән агачны сынландырып, яшьли өзелгән гомерне символлаштырганнар: «...Гали Гыйрфан углы Кәримов 1910 сәнәдә Казанда дөньяга килеп, 1929 нчы ел 15 июлендә...» вафат булган

Төбәкне өйрәнүчеләр форумы делегатлары мәрхүмнәр рухына багышлап дога кыла

«Сембер губернасы Ардат өязе Никлюдов волосте Ламат авылының Хөснулла Әмиров җәмәгате Шәхлеҗәмал Юныс кызы (1874-1927)» каберенә куелган таш

«...Казан губернасы Зөя өязе Әҗәле волосте Танай авылының Гомәргали Сәгыйтулла, 55 ел гомер итеп, 1905 ел 12 нче июньдә вафат...»

***Ленар Гобәйдуллин*** *әзерләде.* ■

Безнең мирас №11 ноябрь 2019

# Көрәшчеләр

Рәдиф Сәгъди

Сулдан уңга: Нәфыйк, Рәшит, Фарыйх, Нәкыйп, Фәрит, Рәфыйк. 1975 ел

### Тәрбия

Мадьяровлар дигән нәсел фамилиясен ишетсәм, күз алдына татар халкының горурлыгы, Россия спорты тарихында уникаль күренеш булган алты бертуган батыр егет килеп баса. Менә аларның бер рәткә калкан кебек басып төшкән рәсемнәре: Фәрит, Фарыйх, Рәшит, Рәфыйк, Нәфыйк, Нәкыйп. Республика, Россия, Европа, дөнья келәмнәрендә бил алышкан, төрле зурлыклардагы ярышларда уңышларга ирешкән спортчыларыбызның феноменын аңларга тырышам. Аларның самбо көрәшендә яулап алган титулларының нигезен, җирлеген барлыйм. Ничек бер гаиләдән алты спорт остасы (мастеры), алты пәһлеван чыкты икән?! Сәбәбе, сере нәрсәдә?

Әти-әниләре газиз улларына нинди тәрбия биргәннәр дә, кайсы чишмә суларын эчертеп үстергәннәр икән, дигән уйлар белән мин Нәфыйк абый яшәгән якларга юл тотам. Аңа кадәр самбо көрәшенә кагылышлы китап һәм язмаларны укып чыктым. Андый династия тагын күп миллионлы тугандаш үзбәк халкында гына бар икән. Тик аларда биш кенә агай-эне!

...Барысы да ата-ана тәрбиясеннән килә. Балага сабый чагыннан нинди тәрбия бирәсең, соңыннан шул гамәлләр тормышында да чагылыш таба. Нәфыйк ага Мадьяровның сүзләре моңа ныклы дәлил: *«Безнең өчен әти хөрмәтле кеше иде. Әни*

*дә һәрдаим: «Әнә, әтиегездән үрнәк алыгыз, өйрәнеп үсегез, сезне ач-ялангач итмәс өчен көне-төне эшли, көч сала!» – дип, гел искәртеп торды. Әти безне үзе белән ияртеп йөрергә тырышты. Авыл хуҗалыгы алдынгыларын мактый, аларның эшләрен аңлата иде. Аның кешеләр белән аралаша белүен дә, һәркемгә игътибарлы булуын да кечкенәдән күреп, сеңдерә бардык. Шул ук вакытта барыбызны да колхоз-кыр эшләрендә катнаштыра иде. Безгә, колхоз рәисе малайлары, әнә, бот күтәреп яталар, дип төртеп күрсәтүчеләр табылмады. Авыр хезмәттән дә*

Әхмәди ага белән Рәхимә апа

*тайпылмадык, киресенчә, абый-апаларыбызга ияреп ярышып, җигелеп, барысын да үти тордык. Әнкәй дә, унике баласы булуына карамастан, көн дә эшкә йөгерде. Өлкәнрәкләрнең кечерәкләренә күз-колак булуына ышана иде ул. Әткәй белән әнкәйнең кеше булсыннар дип тырышуы аркасында без барыбыз да, җиң сызганып, төрле эшләргә чыга идек: көтүен дә көттек, бозауларын да карадык, печәнен чабып, саламын да өемнәргә өеп куя идек. Борчакны покоска салу да үзе бер өмәгә, ярышып эшләүгә әйләнә торды. Барып әйрән, чәй, һич булмаса, чишмә суы эчәбез дә, эшне тирләп-пешеп дәвам итәбез. Борчакның сабагы сыек булу сәбәпле, җиргә ята: аны комбайн ектыра алмый, шуңа күрә, чалгы тотып, бар авыл халкы диярлек кырга чыга иде ул игелекле, ләкин мохтаҗлы елларда. Безнең төп диспетчерыбыз әни булды. Эшләтте дә, укырга да өндәде. Үзе, ятимлектә үсеп, ике генә класс белем ала алган. Шул сәбәпле, барыбызны да, укып, югары белем алырга үгетләде. Соңыннан аның тормыш тәрбиясе киленнәренә дә үрнәк булды. Балаларын карарга да, ирләрне хөрмәт итәргә дә, якты караш, җылы чәй белән каршы алырга да дәрес бирде ул аларга. Әйтеп торам бит, ике класслы авыл кызы гына булса да, каян килгәндер инде аңа шундый остазлык?! Оныклары, әби-бабаларын бик яратып, хөрмәт итеп үстеләр. Инде хәзер үзебез әби-бабайларга әйләнгәч, шул традицияләрне дәвам итәбез, Аллага шөкер! Безнең балалар бабаларының хәрби киемнәрен – кительләрен, медальле-орденлы гимнастеркаларын киеп йөрергә яраталар, шул сәбәпле, бәхәсләшеп бетәләр иде. «Син инде солдат булдың, хәзер мин киям», – дип, алмаш-тилмәш чиратлашып киделәр.*

*Бүгенге көндә, Алланың биргәненә шөкер, улым Илнур дәү әтисенең эшен дәвам итә. Халкыбыз өчен затлы ит җитештерәбез, авыл хуҗалыгыннан аерылганыбыз юк. Оныкларыбыз Мәликә белән Айсил үсеп җиткәч кем булырлар – әлегә билгесез. Мәликәбез нәфис гимнастика белән шөгыльләнә, Берләшкән Гарәп Әмирлекләренә барып, беренче урынны алып кайтты инде. Айсил кызыбыз да апасыннан калышмый, фигуралы шуу белән шөгыльләнә, Алинә Заһитова – аның кумиры. Наиләбезнең исә ике малае үсә... Үзегез күрәсез, әткәй белән әнкәйнең нәсел дәвамчылары безнең гаиләдә генә дә дүртәү. Әле соңгы тукталыш булыр, дип уйламыйм... Кәрим белән Камилебез хоккей белән шөгыльләнәләр, Данис Зариповның уенын гел карыйлар».*

Безнең мирас №11 ноябрь 2019

## Самбо көрәше

Бу – кырыс, зур түземлелекләр сорый торган спорт төре. Бөтен ихтыяр көчеңне бер учка туплап, ашау-эчүләрдән тыелып, спорт залында шөгыльләнергә чабасың. Бик күпләр (килүчеләрнең 50-60 проценты), бу йөкләмә-нагрузкаларга түзә алмыйча, беренче елны ук китеп бара. Икенче елында да иң түземлеләре, максатчаннары гына эшен дәвам итә. Спортта, иң беренче чиратта, үз-үзләрен җиңә алганнар гына кала һәм соңыннан югары күтәрелә. Син авыр спорт биштәреңне асып тренировкага киткәндә, урамда иптәшләрең, дусларың шау-гөр килеп уйнап кала, йә булмаса, укытучылар, ата-аналар җитәкчелегендә циркка, зоопаркка, кино-театрларга юнәлә. Ә, син, ул көнне үзеңне авызлыклап, йә тренировкада буласың, йә ярышта бил алышасың. Кире кайтканда, мороженое, пирожный, өчпочмак, пәрәмәч ишле ризыклардан авыз итеп торучыларны күреп, көнләшеп куясың. Сиңа ярамый, авырлыгыңны сакларга кирәк! Әле шул категория-авырлыкка төшәр өчен, көнаралаш мунчага барып, эссе ләүкәдә чабынасың, гимнастика ясыйсың, шуңа өстәп, тизрәк тир куар өчен аягыңны кайнар суга тыгып, башыңа калын сөлге урап, эссе ләүкәдә түзепләр утырасың. Иртән исә әче таңнан торып, инде киметер матдәсе калмаган, суырылып килгән гәүдәңне сөйрәп, унар чакрым араны йөгереп кайтасың. Шулай итеп: «Тагын ике йөз генә, йөз генә грамм ыргытасы иде!» – дип, чакрым артыннан чакрым үтәсең. Әлбәттә, үсә, ныгый барган организмны һава белән генә яшәтеп булмый. Җан асрар өчен әз-мәз шоколад кисәге, йөз-йөз илле грамм майсыз ит, бер-ике стакан каты чәйдән генә торган тамак ялгау – синеке, шуннан артыгы ярамый. Әле бит кичкырын кеше эштән кайтканда, сиңа алҗыткыч ике сәгатьлек тренировкага барырга кирәк. Анда исә эшләр урман кискәннән, шахтада күмер чапканнан да читенрәк. Көндәшең сине төрлечә йолкый, тарта, сөйри, каера. Тренер күрмәгәндә борыныңа, йомшак җиреңә менеп төшәргә дә күп сорап тормый. Ә син түзәсең, чөнки тиздән ярыш, ярыштагы алыш. Анда инде клубташың түгел, сине өзгәләп-ботарлап ташларга да әзер усал көндәшең көтә. Тренировкаларда алган осталык-чыдамлыкларың менә кайчан кирәк була!

Сине болгап ыргытырга дип чыккан чираттагы көндәшең йә сине иярли, йә син аны! Менә максатчан тренировкалар ни өчен кирәк! Соңыннан, ярылган иреннәреңне сөртә-сөртә, сыдырылган тәнеңне сыйпаштырып, өеңә таба атлыйсың. Кайтып урын өстенә авасың. Шулай үзеңне авызлыклый, җиңә торгач, һөнәри усаллык туа. Ләкин ул явызлыкка әйләнергә тиеш түгел. Явызларга рингта да, келәмдә дә урын юк! Алар спортта, тормышта да югары нәтиҗәләргә ирешә алмыйлар. Ә менә спорт усаллыгы сиңа көндәшеңне җиңәр өчен кирәк. Айлар, еллар буе «спартан» тормышы белән яшәү сине батыр ясый, синнән, чыдый торгач, гладиатор туа. Ләкин акыл һәрчакта да үзең белән булырга тиеш! Әгәр ул булмаса, югары уңышка ирешүең икеле. Һөнәри осталык, акыл, спорт усаллыгы, чыдамлык – зур җиңүләрнең төп нигезе! Ә дөрес юлдан барыр өчен, сиңа яхшы остаз, акыллы тренер кирәк...

*«Әлбәттә, безнең барыбызның да олы спорт юлына чыгуыбызның башында Фәрит абыебыз тора, – дип фикерен дәвам итә Нәфыйк ага. – Шәһәргә килгәч этиебезне алыштырган, начар гадәтләргә кереп китүләрдән дә саклап калган кешебез ул! Тормыш юлында безгә маяк булып, юл күрсәтеп барды. Спортта яулаган уңышларыбыз да аның тырышлыгы аркасында. Ил, дөнья күләмендәге ярышларга чыгарлык спортчылар итеп тәрбияләде ул. Икенче туганыбыз Фарыйх абый – зур фаҗигаләр күргән кеше. Кечкенәдән хыялый, юмарт күңелле абыебыз, маҗаралар эзләп, яшьлек хыялларын тормышка ашырыр өчен, Ленинградка хәрби училищега укырга чыгып китә. Соңыннан диңгез офицеры булып хезмәт иткән җиреннән Куба кризисына эләкте ул. Су асты*

СССР чемпионаты. 1982 ел, Барнаул. Рәфыйк – беренче, Нәфыйк – өченче, баш тренерга да – алтын медаль

*көймәсендә авария килеп чыккач, көчле нурланышка дучар булып, авылга үләргә дип кайтты Фарыйх абый. Әнкәй аңа кәҗә сөте, төрле үлән төнәтмә-чәйләре эчереп, аякка бастырды. Чери башлаган аякларының яралары төзәлде.*

*Шуннан соң абый яңадан самбо белән җитди шөгыльләнеп, спорт остасы дигән мактаулы исемгә лаек булды. Әлеге дә баягы, өлкән абыйларыбыз Фәрит белән Рәшитнең дә өлешләре зур ирешкән уңышларыбызда. Алар, Казанга килеп төпләнеп яши башлагач, безне көрәштереп кенә үстермәделәр, гаилә корганда да, йорт салганда да зур терәк булдылар. Үзебезнең ихаталар калыкканчы, кунакка да, мунчасына да, балаларны ияртеп, аларга йөрдек, рәхмәт аларга! Рәшит абый әле хезмәткә дә өйрәтүче кешебез иде. Ул бит үзенең һөнәри тормышын тракторчы булып колхозда эшләүдән башлады. Фарыйх абый да, шабашка булсынмы, колхоз эшенә чыгыйкмы – оештырып, әйдәп йөрде».*

## Кумәклек феномены

Әлеге гамәлләрдән чыгып фикер йөртсәк, Мадьяровларның кечеләре, өлкәнрәкләреннән үрнәк алып, агаларына охшарга, алар алдында сынатмаска тырышып, хезмәт куеп үсәләр. Шул ук вакытта бер-берсе алдында җаваплылык тою да әлеге феноменга керә торгандыр. Кумәклек феномены ул – борынгыдан килгән халәт: авырлыкларны бергәләп кенә җиңеп була. Безнең очракта да әйләнәңдә абый-энеләреңнең терәген тою кайчагында җиңеп чыга алмаслык мәсьәләләрне чишкәндә дә ярдәм итә. Бердәмлек зур көчкә ия! Мадьяровларның спорт династиясенә бердәмлек, куйган максатыңа ирешү сыйфаты әти-әниләре тарафыннан сабый чакларыннан ук сеңдерелгән. Миңа калса, кирәк чакта усал да, җитди дә, таләпчән дә була алу – күбрәк Рәхимә апаның

Сулдан уңга: Нәфыйк, Рәфыйк, Нәкыйп, Фәрит, Рәшит



Фарыйх. 1975 ел

тәрбияседер ул. Ирең эштә чакта, бер көтү балага күз-колак булып, кулда тотып бетереп кара әле! Колхоз рәисе булып иртә таңнан кичкә кадәр хезмәт куйган Әхмәди абзыйның вакыты да җитеп бетмәгәндер. Ләкин зирәк ананың: «Әтиегез ни әйтер, әтиегез кайтканчы эшләп бетерегез, әтиегез тамак ялгамаган әле, тавышланмагыз, әтиегез ял итә!» – дигән тәрбияви сүзләре үз ролен үти. Әтиләренең дә: «Менә әниегез ни әйтер! Анагызны тыңлагыз!» – дигән ихтирамлы мөнәсәбәте аша да тәрбияләнә балалар. Өй тулы шук малай-шалай, кыз-кыркынның егәрен тырышып хезмәт куюга, гаилә ихтыяҗларын кайгыртуга юнәлтә алган алар. Әхмәди аганың балалары ялкау, хәерче гаиләләрдәге кебек түшәмгә төкереп, эчләре пошудан котырышып ятмыйлар. Өлкәнрәкләре колхоз эшенә чыксалар, кечерәкләре өй тирәсендә булышалар. Әхмәди ага да кайткан-киткән чагында: «Менә моны, әнә тегене эшләп куегыз әле!» – дип наряд биреп китә. Нәтиҗәдә, агаларыннан күреп үскән Рәфыйк, Нәфыйк, Нәкыйп тә эшләп чыныга. Әтиләре заманында колхозның беренче тракторчысы була. Соңыннан өлкәннәрдән икесе – Наил белән Рәшит тә әлеге эшкә тартыла: алар, трактор йөртүгә укып, таныклык алып кайталар.

Дөрес, бала-чага шаярмый-шукланмый, бәхәсләшми дә тора алмый. Андый чакта таләпчән Рәхимә апаның кырыс күз карашы, «Әтиегез белсәме!» дигән сүзләре дә җитә. Балаларын кечкенәдән әтиләренә ихтирам белән карарга өйрәтә ана кеше. Шуңа

күрә, табын янына утырган үсмерләр үзләре үк: «Әти ашадымы соң әле, аңа каламы соң?» – дип сорый торган булалар. Ундүрт җанның яшәешен кайгырткан Әхмәди аганы Рәхимә апа балалары алдында гел олылый, аталарының алар тормышында иң мөһим кеше икәнлеген төшендерә. Югыйсә, Рәхимә апаның ике класстан гайре белеме дә булмаган. Ләкин балаларны, өлкәннәргә хөрмәт белән карарга һәм эшкә өйрәтеп, ныклы тәрбия биреп кенә чын кеше итеп үстереп булганлыгын күңеле белән тойган ул. Үзенекеләргә катырак та эләккәләгән, әлбәттә, тик үги улы Наил шукланса гына кул күтәрмәгән, чөнки үзенең рәнҗетелгән сабый чагын – ятимлектә үскәнлеген һәрчак истә тоткан ул. Таләпчән, кирәгендә усал да була белгән әниләре оланнарны, кыз-кыркынны да эшкә җигә белгән, тырышлыкка, максатчанлыкка өйрәткән.

Бүгенге көндә бер баласын да тиешенчә тәрбияли алмаганнарга менә дигән үрнәк! Сәке өсте генә түгел, өй тулы бала-чага, тик барысы да эш белән мәшгуль: көтүен дә көтәләр, суын да ташып куялар, чүбен дә утыйлар, терлек астын да чистарталар, кирәк икән, колхоз эшенә дә чыгалар. Балалар үскән саен, чыгымнары да күбәя. Әхмәди абзыйның үзе кебек тырыш малайлары, көннәрдән беркөнне күрше-тирәне шаккатырып, көненә бишәр йөз кирпеч суга башлыйлар. Кечерәкләре дә читтә калмый: балчык ташый, аны изә. Бер тәүлек җебетелгән кызыл балчыкны бии-бии йомшарталар. Шулай шаярыша-көлешә торгач, танымаслык булып буялалар. Хәлләре бетсә дә, әзер балчык тутырылган авыр чиләкләрне сөйрәп булса да китерәләр. Фәрит белән Рәшит абыйлары үзләренә дигән кием-салымны, ул чорларда бик кирәкле транспорт булган велосипедларны да кирпеч саткан акчага юнәтә.

Сәгать иртәнге дүрттән торып, балалары уянганчы нәрсәдер эшләп куйган, шул арада гадәттәгечә ат җигеп каядыр барып кайтырга да өлгергән Әхмәди ага гел үрнәк була гаиләсенә. Балаларына да: «Һөнәрле, белемле булыгыз! Ир кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз!» – дип, гел искәртеп тора. Аларның бергәләшеп гармунда уйнарга өйрәнүләренә дә сөенә. Әлбәттә, соңрак малайларның төп әйдәманнары өлкән абыйлары – Фәритләре була. Барысын да эшкә җигә белә, милли көрәш серләренә дә төшендерә-өйрәтә ул. Тырышлыгы бушка китми: милли көрәштән самбога күчкән ага-энеләре белән бергә, Нәфыйк Әхмәди улы да спортка ныклап тартыла. Нәтиҗәдә, ул җиде тапкыр Татарстан чемпионы, 1977 елда Республикабыз кубогына да ия була, шул ук елны Россия чемпионына әйләнә. 1980 елны Болгариядә үткәрелгән халыкара бәйгедә дә җиңеп чыга. 1982 елда СССР кубогын ота ул. Өстәвенә, дзюдо буенча да 1978, 1980 нче елларда беренчелекне бирми Нәфыйк. Гомумән, титулларының барысын да санасаң, бик күпкә җыелыр иде. Яшьтән тәвәккәл малай төгәллекне ярата, кешелеклелеге белән дә аерылып тора. Үзе ул әлеге кайнап торган яшьлек чорларын болай искә ала: *«Тренерым Фәрит абый икеләнүләргә урын калдырмый торган иде. «Сүз бирдеңме, алындыңмы – үтә, егылдыңмы – тор, максатыңа һәрчак иреш!» – дип һәрдаим искәртеп торды. Иң уңайсызы – зур бәйгеләрдә үз агаларыңа каршы мәйдан тоту иде. Авырлыкларыбыз бер булу сәбәпле, Рәфыйк абый белән бил алышырга да еш туры килде. 1982 елда Барнаулда СССР беренчелегенең ярым финалында очраштык без. Чемпионлыкны абый алса, мин өченче урынга калдым. СССР кубогы ярышларында исә финалда Рәфыйк абыйны отып, инде мин чемпион булдым. Төрле турнирларда гел бергә туры килә идек. Аның киңәшләрен тыңлап, тәҗрибәсен өйрәнеп көрәшә идем. Тормышта да күршедә генә яшәдек, стена кагып кына кунакка йөрешә идек. Оланнар да бергә укыдылар, хәтта аның Лилиясе белән минем улым Илнур бер парта артында утырдылар. Абыйның Айдары белән безнең Наиләбез, бер чор балалары буларак, гел аралашып үстеләр».*

Яшьләй абыйларына ияреп Сабан туйларында көрәшеп үскән, олы келәмгә чыгып

зур титуллар яулаган Нәфыйк абый соңыннан үзе дә тренерлык эшенә күчә – яшьләрне самбо көрәше серләренә өйрәтә. Кукмара чибәре Зөлфия белән яратышып йөриләр, агай-энеләрен, апа-сеңелләрен, әти-әниләрен җыеп, гөрләтеп туй үткәрәләр. Әлбәттә, тренерларга түләнә торган 120 сумга гаиләне җитеш итеп тотуы, тормыш алып баруы җиңелләрдән булмый. Акчалырак эшкә күчәр иде, яраткан спорты, шәкертләре кала. Бөтен кыюлыгын җыеп Спорт министрлыгына барып: «Хезмәт хакымны бераз күтәрә алмассызмы икән?» – дигән үтенеч җиткергәч, дорфа сүзләр ишетеп, телсез-өнсез кала. Күп тапкырлар Татарстан, Россия, СССР, дөнья күләмендәге бәйгеләрдә бил алышкан чемпион, халыкара спорт остасы йөрәге әрнеп чыгып китә.

Өлкәнрәк буын яхшы хәтерли: СССР дигән гигант дәүләтнең таркалуы халыкны бик авыр хәлдә калдырды. Илнең алдынгы кешеләре үзгә кәсепләргә күчтеләр. Укытучылар, галимнәр, спортчылар һәм башка һөнәр ияләре, чит илләрдән кием-салым, мебель кебек әйберләр ташып, сатучылык белән шөгыльләнә башлады. Дәүләт тарафыннан игътибарсыз калдырылган бюджетниклар, гаиләләрен яшәтер өчен, шулай үзгә юллар эзләде.

Көче ташып торган атаклы спортчы, Әхмәди абыйның тырыш оланы югалып калмый. Яраткан спортын ташлап диярлек, Вертолет заводының төзелеш бригадасына эшкә урнаша ул. Мускуллары уйнап торган ир-егетләр, бригада подрядына күчеп, аена 400-500 сумлап акча эшли башлыйлар. Күпмедер вакыттан соң, кооператив оештыралар. Бу чорлар турында: «Алты егет булганнар!» дигән китабында күренекле журналист һәм җәмәгать эшлеклесе Илдус Илдарханов болай дип язып үтә: «Нәфыйк Әхмәди улын Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы каршындагы корпорациягә чакыралар. Шунда эшли башлагач, Нәфыйкта әтисеннән күчкән сыйфатлары ныграк ачыла башлый. Әхмәди ага – җир сөргән, аны эшкәрткән, хуҗалык җитәкчесе булып та эшләгән шәхес. Балаларында тырышлык сыйфаты гына тәрбияләп калмыйча, аларны кешеләр белән эшләгәндә игътибарлы булырга да өйрәткән икән. Нәфыйкта бу сыйфатлар Питрәчтәге кошчылык фабрикасына директор урынбасары булып күчкәч тагын да ныграк ачыла. Исәпли-саный белүен, төгәллекне яратуын, икенче төрле әйтсәк, икътисадта көчле булуын күрсәтә ул. Ике елдан директор, озакламый «Татарстанның атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре» дигән мактаулы исемгә лаек була».

Нәфыйк Әхмәди улы агай-энеләре белән спортта үткән чорларын гомеренең иң бәхетле еллары дип саный. Төрле илләрдә булу, аралашу аның дөньяга карашын киңәйтә. Ярышларда алган абруен сакларга тырышып, авыл хуҗалыгы өлкәсендә дә җиң сызганып, бар көчен салып хезмәт куя ул. Совет заманында биләмәләре Яшел Үзән районының Олы Ключи авылына урнашкан, соңыннан бөлгенлеккә төшеп ташланган кошчылык фермасын аякка бастырды ул. Хәзерге фабрика Европа югарылыгында төзелеп, авыл халкын эшле, Татарстан халкын исә күркә итле итте. Бүгенге көндә затлы бу итне Казан кибетләрендә аласыз икән, аның нәкъ менә әлеге фирманыкы булуы ихтимал. Биредә тауарның сыйфатына зур игътибар бирелә, аның кулланучылар өстәленә затлы килеш барып җитүе максат итеп куела. Ярыш мәйданнарында алган җәрәһәт-имгәнүләргә карамастан, сокланырлык гамәлләр кыла Әхмәдинең данлыклы уллары. Рәфыйк Мадьяров та авыл хуҗалыгыннан ерак китмәде: нәселле кәҗәләр үрчетә, Татарстан халкына шифалы сөт җитештерә. Аның улы Айдар – бүгенге көндә зур идарә җитәкчесе.

Барлык агай-эне, хатын-кыз, туган-тумача дини бәйрәмнәрдә Әхмәди мәчетенә – Арча районының Байкал авылына кайталар. Әти-әниләре, якты дөньядан вакытсыз киткән энеләре Нәкыйп рухына дога юллыйлар. Кече туганнары истәлегенә елга

Нәфыйк абый үзенең гаиләсе – хатыны Зөлфирә ханым, улы Илнур һәм кызы Наилә белән. 1984 ел

бер оештырылган турнирга көч сынашырга Россиядән генә түгел, төрле илләрдән дә көрәшчеләр җыела. Бәйге башланыр алдыннан бертуганнар чыгып басып, энекәшләренең стенадагы рәсеменә сагышланып карап торалар. Аларның күз алдына уйнап-шаярып үскән, көрәшеп йөргән кече энеләре килеп баса. «Онытмавыгыз өчен рәхмәт сезгә!» – дия кебек ул, абыйларына карап. Нәфыйк абый да энесен бик еш искә ала: *«Нәкыйп безнең арада иң талантлы, иң оста көрәшче булып үсте, чөнки аның үрнәк алырлык агалары бар иде! Ул, бездән үрнәк алып, безне дә уздырырга тырышты, хәтта безнең белән көрәшкәндә дә ташлама ясамый алыша иде. Аның исеме белән уздырылган халыкара турнир гына күңелләргә бераз тынычлык бирә. Ул чын батыр иде!»*

Нәфыйк абый да, башка агалары да күренекле энеләре, халыкара спорт остасы булган Нәкыйпнең гаиләсенә төрле яклап ярдәм күрсәтеп, һәрчак булышып яшиләр. Элек самбо спортын җитәкләгән Мадьяровлар династиясенең бүгенге көндә көрәштән читкә тайпылуы гына йөрәкне әрнетә. Нишлисең, барыбызның да гаиләләре, балалары, оныклары, аларны тәэмин итәсе бар! Тренерларның түбән хезмәт хакы сәбәпче моңа. Нәфыйк абый, сүзен йомгаклап: *«Безнең династиянең башында Фәрит абый торды. Бүген дә ул әтиебез урынына калган әйдәманыбыз. Төркиягә китеп яшәсә дә, гел кайтып йөри. Быелның августында аңа җитмеш биш яшь тулды. Егетләр кебек әле ул, Аллага шөкер. Барыбыз исеменнән дә аңа кабат нык сәламәтлек, озын гомер телибез! Гаилә бәхете сиңа, абый!»*

Без дә спорт үсешенә гаять зур өлеш керткән күренекле тренер, дөнья чемпионы, халыкара спорт остасы Фәрит ага Мадьяровны котлап, аңа сәламәтлек, иминлек, тигезлек белән хәерле озын гомер телибез! ■

Безнең мирас №11 ноябрь 2019

# ФӘРИТ МАДЬЯРОВ

## *шигырьләре*

### ЕЛЛАР ЧАБА...

Еллар уза... Яшь гомерне алып,
Чабалардыр алар ник алай?!
Вакыт арбасыннан төшеп калып,
Еласаң да булмый бит, малай!

Еллар чаба һаман... Күз алдыннан
Үткән гомер уза тезелеп...
Ялгышларым, хаталарым өчен,
Үзәкләрем куя өзелеп...

Ә шулай да, начар кеше, диеп,
Әйтә алмас идем үземә.
«Халкым өчен яши алдым!» – диеп,
Туры карыйм кеше күзенә...

### ҮПКӘЛӘМӘ, ӘНКӘЙ...

Энҗе бөртегедәй күз яшеңне
Яшермә син, Әнкәй, яшермә...
«Балаларым озак килми», – диеп,
Күңелеңне, Әнкәй, төшермә!

Орышырга: «Сез – гамьсезләр!» – диеп,
Хаклы, Әнкәй, бары син хаклы...
Сине үпкәләткән мизгел өчен
Сыкрый, Әнкәй, күңел шулчаклы.

Хәзер без дә олыгайдык кебек,
Утын-суын кичтек, җиз торбасын...
Синнән үрнәк алып, җиңә белдек,
Юлда нинди киртә тормасын. ■

Фәрит абый үзенең кадерле әти-әнисе Әхмәди ага белән Рәхимә апа янәшәсендә

ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫНА – 100 ЕЛ

# ӨСТӘЛЕМДӘГЕ КИТАП – ТАРИХ ЯДКАРЕ

Халидә Габидуллина*

*Эш өстәлемдә һәрвакыт китап тора. Кирәк вакытта яки эч пошканда мин аны актарып, укып утырырга яратам. Ни өчен дисезме? Чөнки анда авылым тарихы, аның кызыклы, игътибарга лаек кешеләре турында язылган. Ул китап – Мөхәммәт Мәһдиевнең «Торналар төшкән җирдә» әсәре. Әсәр беренче тапкыр 1983 елда басылып чыга, М.Мәһдиевнең өч (1995-1996) һәм биш (2009) томлыкларына да кертелә. Хәтта, аерым китап булып, 1997 елда башкорт телендә дә дөнья күрә. Китапта тарихның төрле чоры сурәтләнгән: 1921 елгы ачлык фаҗигасе, колхозлашу, Бөек Ватан сугышы, аннан соңгы күтәрелеш, халкыбызның социализм, коммунизм төзибез, дип, фидакарь хезмәт итүе...*




«...Безнең авылдан бер генә герой да, бер генә космонавт та, бер генә академик та чыкмаган. Гап-гади, иң гадәти бер авыл», – дип башлый автор кереш сүзен. Чыннан да, Арча районындагы Гөберчәк – гади татар авылы. Анда җиргә кендеге белән береккән, туган нигезен бик яраткан кешеләр генә яши. Язучы авылдаш геройларын чын күңелдән ярата, аларны хөрмәт итә, соклануын белдерә, башкаларга үрнәк итеп тә куя белә. Китаптан укылганнар тәэсирендә тормышка карашың үзгәрә, геройларның язмышы аша тәҗрибә туплыйсың, киләчәк буын өчен өлге булырлык авылдашларыбызга сокланасың. Мөхәммәт абый әсәренең баш өлешендә үк туган авылындагы күренешләрне чит илдә күргәннәре белән чагыштырып яза. Аның фикеренчә, Европа илләрендә булган һәрнәрсә безнең авылда инде күптән бар. Язучы авыл тарихын гади кешеләр тормышы, язмышы белән бәйли. «Тарих ул – кешелек җәмгыятенең ачы тәҗрибәсе», – ди автор. Чыннан да, Гөберчәк авылында биредә тәҗрибә туплап, ачы язмыш кичереп, халкына рәхмәтле дә, мәрхәмәтле дә булган кешеләр яши.

Әсәрдәге күрсәтелгән һәр герой үз исеме белән бирелә, без аларны таныйбыз, яратабыз һәм авылыбызда шундый шәхесләр дә булган бит, дип горурланабыз. Мәсәлән, авылда алты тегүче яшәгән. Алар вакыт-вакыт чит җирләргә чыгып китеп, үз эшләре белән шөгыльләнгәннәр. Мөхәммәт абый тегүчеләрнең кайларда эшләгәнлекләре белән дә кызыксына. Менә шул вакытта ул үзенә зур ачыш ясаган күк була да инде: авылдашлары татар милләтенең йөзек кашы булган шәхесләр белән аралашып, аларга киемнәр теккән икән бит! Гатиятулла абзый Шәрәфиев Габдулла Кариев, Габдулла

* **Халидә Габидуллина** – Арча районының Гөберчәк авылындагы Мөхәммәт Мәһдиев музееның җитәкчесе.




Тукайлар белән тыгыз элемтәдә булып, аларга төрле киемнәр тегеп бирүе турында сөйли. Әсәрдә урман карчыгы – Мәрфугатти турында да мәгълүмат шактый. Ул җитез, үткен, эшкә батыр хатын булган. Үстергән өч улын Бөек Ватан сугышында югалтып та, төшенкелеккә бирелмичә, тормыш йөген тарткан, хәтта тол калган киленнәренә дә яшәү өчен көчдәрт биреп торган. Ничек инде шундый хатын-кыз белән горурланмыйсың да аны башкаларга үрнәк итеп куймыйсың! Автор әтисе Сөнгатулланың ачы язмышын да читләтеп узмый, чөнки аның үткән тормышы, авылның гына түгел, шул чор тарихының бер өлеше булып тора.

Су – җирдәге һәр тере җан иясенең яшәү чыганагы. Автор чишмә караучы Сафиулла абзый турында «Алай да чишмә бар әле» бүлегендә бәян итә. Язучы тешеңне сындырырлык салкын сулы Сафый чишмәсе аркылы кешелек дөньясына болай дип эндәшә сыман: кешеләр, һәрвакыт очрашып, бер-берегезнең хәл-әхвәлен белешегез, дус-тату булып яшәгез, табигать байлыгын югалтмыйча, карап-барлап торыгыз! Мөхәммәт ага һөнәрчеләребезне дә читтә калдырмый. Авыл хатын-кызларын шәл бәйләргә өйрәтүче Масра авылы киленнәре турында язып, аларны мактап, әсәрендә аерым урын бирә.

Масра басуы юлы, торналар төшә торган кырлар, төлке оялары, оста пыялачы Шәйхи, үткен-елгыр кыз Зөлфия, тегермәнче Пауал, җан дусты Габдерәкыйп, дөнья гизгән күршесе Насыйбулла карт, Симетнең биш килене, мунча ягарга яратучы Камәр түти, урманчылар, кичке уеннар, кендек әбиләре, Ибәт нараты турында язмаса, Мөхәммәт абыйның бу әсәре китек булыр иде сыман.

«Торналар төшкән җирдә» аша бүгенге яшь буын туган авыл тарихы, аның эчкерсез, эшлекле, әдәпле кешеләре белән таныша. Әсәр геройлары инде вафат, ләкин аларның балалары һәм оныклары, дуслары, туганнары, күрше-күлән исән. Шуңа күрә, тагы да күбрәк белү максатыннан, шушы китаптан аерылышмыйча, авылдашларым белән очрашам, аларның истәлек-хатирәләрен барлыйм. Әлеге истәлекләрне, мәкалә итеп язып, газета-журналлар аша халыкка җиткерергә тырышам. Матбугатта чыккан хатирәләрнең бер өлеше тупланып, «Мөхәммәтле Гөберчәк» исемле китабым басылып чыкты. Мөхәммәт абый үзе белгән буын белән очрашса, мин аларның онык-оныкчыклары белән аралашам, киләчәккә бу мәгълүматлар тарих булып калыр, дип ышанам. М.Мәһдиевнең «Торналар төшкән җирдә» китабы миңа эшләү һәм яшәү өчен көч бирә сыман. Авылдашларым нинди авыр заманнарда да югалып калмаган, язмыш сынаулары алдында баш имәгән, сынмаган-сыгылмаган, төрле киртәләрне бердәм булып үтә алган.

Әсәрдә телгә алынган торналар, ел саен безне шатландырып, туган якларына кайтсыннар, мул уңыш бирүче басу-кырларыбызда машиналар гөрелтесе сүрелмәсен, авыр елларда кешеләрне ачлыктан саклап калган урманнарыбыз шауласын, чишмәләребез челтерәп аксын, миһербанлы-шәфкатьле, итагатьле, белемле яшьләребез үссен. Авыл яшәсен, яшәрсен! ■

# ИСЛАМ ДӨНЬЯСЫ

Габдерәшит Ибраһимов

Иске Токио. Япония. 1868-1912

### ЯПОННАРДА ТАРИХ БАШЫ

Шул рәвешле, японнарда тарихи даталарны билгеләүдә халыкның үзенә генә хас бер тәртибе бар һәм алар әлеге тәртипне үзгәртергә уйламыйлар да. Хәтта бу тәртипне саклау өчен оештырылган махсус җәмгыятьләре дә бар. Ул – Тарихны саклау җәмгыяте – Япониядә иң зур җәмгыять булып санала. Аның әгъзалары нигездә мәмләкәтнең алдынгы кешеләреннән гыйбарәт булса да, араларында җир эшкәртү, хайван үрчетү белән шөгыльләнүче авыл кешеләре дә бар. Җәмгыятьнең төп эше – Япониядә булган вакыйгалар белән бергә, Аврупаның әһәмиятле вакыйгаларын да теркәп бару.

Җәмгыятьнең идарә үзәге Токио шәһәренең Бибих дигән җирендәге Мәгариф министрлыгы бинасында урнашкан. Аларга бу бинада аерым урын бүлеп бирелгән, идарә рәисе Хиаши әфәнде

Дәвамы. Башы журналның 1 нче (2017) санында.

һәр көн эш урынында була. Тарихны теркәүчеләр дә биредә һәр көнге вакыйгаларны көнендә үк тәртип белән язып баралар. Мин бу җәмгыять әгъзалары булган бик күп кеше белән таныштым, ике мәртәбә җыелышларында катнаштым. Бер мәртәбә минем хөрмәтемә мәҗлес тә кордылар, анда чыгыш та ясадым.

### ТАРИХЧЫЛАР ҖӘМГЫЯТЕНЕҢ ГОМУМИ ҖЫЕЛЫШЫ

Беркөнне бу җәмгыятьнең гомуми җыелышында катнаштым. Бу юлы Вено бакчасындагы бер кунакханәдә җыелышканнар иде. Җәмгыять әгъзалары миннән чыгыш ясавымны сорадылар. Иң алдынгы кешеләрнең күбесе килгән, хәтта хөкүмәт министры Хиҗката-Сан да биредә иде.

Башта фикер алышулар булды, соңыннан мине бертавыштан җәмгыятьнең шәрәфле әгъзасы итеп сайладылар. Кыска гына тәнәфестән соң, чыгыш ясавымны үтенделәр. Мин, торып басып, чыгышымны рус телендә ясадым (Такайама тәрҗемә итте, «Йамата» газетасы хәбәрчесе Омихара теркәп барды):

«Әфәнделәр! Иң башта шуны әйтеп үтим: мин – Русиядә яшәүче татар кешесемен. Безнең татарлар, үз хакимиятләрен югалтканнан соң, 350 ел буе руслар кулында әсир хәлендә яшиләр.

Әсирлек – кешеләргә нәүбәт белән килә торган бер хасталык ул. Кешенең хаста булуы, авыруы гаеп ителә торган хәл түгел. Ләкин хасталыкны дәваламау – гаеп! Соңгы елларда шәрык халыкларының күбесе бу чир белән авырый башлады. Әлбәттә, моның үз сәбәпләре бар, шулай булса да, биредә алар хакында сөйләүнең кирәген күрмим. Хасталыкның сәбәпләрен өйрәнү дәвалау өчен иң беренче шарт булып торса да, авыр яраланган берәүнең котылуына чара эзләмичә, аның җанын кыйган кешене тоту өчен артыннан куа китү кебек була күрмәсен, дим. (Алкышлар.)

Әмма безнең шәрык милләтендә гаҗәеп ныклык бар: һичбервакыт, һичбер афәт каршысында өметсезлеккә төшмәсләр. Бу ныклыклары ярдәмендә алар иң куркыныч «хасталык»ларны да җиңә килгәннәр. Инде ул үткән гомерләрендә өметсезлеккә төшмәгәннәр икән, моннан соң да өметсез булмаячаклары бик ачык аңлашыла. Тик шул ук вакытта, хасталык озакка сузылган һәм бик авыр булганга, вакыт үткәрмичә, дәвалау чараларын да, әлбәттә, эзләргә кирәк.

Бүгенге көндә, әлхәмделиллаһ, Нихон [язмыш кояшы – Япония] үзен танытты. Шул рәвешле якын киләчәктә бөтен Көнчыгышны яктыртачагына ышанып калабыз. Көнбатышның вазыйфасы – бату! (Алкышлар.)

Нихон-Япония юлның башында барса, бөтен көнчыгыш милләтләре алга чыгачак! Японнарның Цусима җиңүеннән башлап, Көнчыгышның киләчәге билгеләнде.

Мин биредә японнарның алга чыкканлыгын үз күзләрем белән күреп аңладым. Япон милләтендәге табигый сәләт миңа гаять зур ышаныч бирде. Зур кыюлык белән шуны әйтә алам: японнарның Миди тарихлары саф алтын белән язылып теркәлергә лаеклы. (Алкышлар.)

Япон милләтенә булган дуслык һәм ярату хисләремне белдерәм. Хакыйкатьнең минем яклы булуына өмет итәм. Япон милләте бөтен Көнчыгыш милләтләренең юлбашчысы булачак. Көнчыгышның табигый юнәлеше – чыгу, күтәрелү! Моңа берәү дә каршы тора алмаячак. Аврупалылар моңа «табигать кануны», диләр, тик безнең мөселманнар «илаһи канун», диләр. Мөкатдәс китабыбыз Коръәнебездә дә: «Аллаһының кодрәте киң һәм үзгәрмәс», – диелгән.

«Әйе, нәкъ шулай!» – дип, чыгышымны тәмамладым. Аннан соң җәмгыять әгъзасы Мийако җәнаплары, урыныннан торып, миңа карата дуслык һәм

*Цусима бугазында 1905 елның май аенда Русия белән Япония арасында булган бәрелеш һәм шунда японнарның җиңүе турында сүз бара (тәрж. иск.).

канәгатьлек хисләрен белдереп чыгыш ясады. Җыелыш тәмам булды. Икенче көнне минем чыгышым газеталарның күбесендә басылган, газета язучылары тарафыннан да алкышларга күмелгән булып чыкты. Ләкин минем моннан хәбәрем юк иде, чөнки япон газеталарын укый алмыйм. Шулай итеп, япон халкы белән арабызда беренче тапкыр җылы мөнәсәбәт урнашты. Японнарда миңа карата олы ихтирам барлыкка килде.

Мин исә бертуктамый Японияне гизәм, көннәр буе, иртәдән кичкә кадәр, карап-күзәтеп йөрим. Япониянең башкаласы булган Токионың әйләнә-тирәсендә урнашкан авыллар, җәйге өйләре булган бакчалар аша үтәм, күбесенчә җәяү йөрим. Авылларда йөрүнең минем өчен файдасы күбрәк иде, чөнки юлда очраган кешеләрдән, теләсәм дә, теләмәсәм дә, юлны яисә башка берәр нәрсә турында сорарга туры килә һәм японча сөйләшергә мәҗбүр була идем. Менә шундый мәҗбүрилек телне өйрәнү юлы булып тора да инде. Тәрҗемәче һәрвакыт янында булмый. Кайчакларда куна калырга кирәк була, кунар урын эзли, сораша, сөйләшә идем. Гомумән, сәяхәткә чыгуымның максаты да бу иде.

## ЯПОНИЯДӘ АВЫЛ КЕШЕЛӘРЕ

Японнарның авылларын гизү миңа үзенә аерым бер рәхәтлек бирә иде. Авыл кешесе белән шәһәр кешесе арасында бик артык аерма да күренми. Гадәт һәм әхлак дисеңме, киенү рәвеше дисеңме – боларның берсендә дә күзгә ташланырлык аерма юк. Япониянең авылларында да искиткеч тәрбияле, әдәпле, килгән кунакка ачык йөзле кешеләр яши. Авылларның күбесендә инглизчә яхшы белгән кешеләр шактый. Кайбер авылларда газета басылып чыга. Бары тик, авыл кешеләре гадирәк, яшәү рәвешләре табигатькә тагын да якынрак һәм алар Көнчыгышка хас тормыш белән яшиләр. Өйләрендә, гадәттә, чыпта келәм, кечерәк кенә тимер мич була, шулардан тыш, йорт җиһазы диярлек башка берни дә күрмәссез.

Авылларда йөргәндә бернәрсә игътибарымны җәлеп итә иде: кышкы көн булганга һавалар суык тора, берәр өйгә кунак килүгә, иң башта тимер мич китереп куялар, шунда ук күмерен дә тутыралар, әлеге янмаган күмерне кунак алдынарак этәләр, бары тик шуннан соң гына сәлам бирәләр. Һәр авылда, һәр өйдә бу кагыйдә рәвешен алган. Шунысы гаҗәп: кисәү башы калган булып, шуннан чыккан төтен исен һич кенә дә тоймадым. Кайчакларда шулкадәр арып кайта, ятып йоклый идем: Аллаһ сакласын, әгәр шул вакытларда кисәү калган булса, җеназам да шул илдә калган булыр иде. Бик күп тапкырлар арып йоклап киткәнем булды, йорт хуҗасы тимер мичне минем борыным төбенә үк диярлек китереп куйган була, күземне ачуга, иң элек шул мич күземә ташлана иде.

Авыл кешеләрендә мин күргән ул искиткеч мөлаемлыкка кызыгып карарлык иде. Ул авылларны бер-берсе белән тоташтыра торган юлларның төзеклегенә, әле шуның өстенә искиткеч чисталыгына сокланып, кайчакларда минем япон авылы кешесе буласым килә иде. Ләкин ашау турында сөйләшсәк, Аллаһ ярдәм бирсен, балыктан башка берни юк. Ашаулары – балык та суда пешкән дөге. Ит, икмәк кебек нәрсәләрне эзләп торасы да юк. Бик мул булган бернәрсә бар – ул да булса, йомырка. Арзан да булганга, мин, күбесенчә, йомырка ашап тамагымны туйдыра идем.

## АТАКЛЫ КЕШЕЛӘР БЕЛӘН КҮРЕШҮЛӘР

Японнарның иң атаклы профессорлары һәм галимнәре белән таныштым. Дәүләтләр хокукы белгече Арига җәнаплары белән күрештем. Бу мөхтәрәм галим белән бик күп тапкырлар сөйләшеп утырдык. Атаклы профессор, Рим дәүләте хокукы буенча белгеч Томидко җәнаплары белән дә таныштык.

Кытай теле белгече Хаттори әфәнде белән дә очрашып сөйләштек. Болардан башка тагын бик күп шәхес белән күрешеп сөйләшү насыйп булды. Япон халкы турында гаять киң мәгълүмат алуга ирештем. Болар һәммәсе дә Аллаһы Тәгаләнең ярдәме белән акчасызтәңкәсез бөтерелгән гаҗәеп бер бөтерелү иде. Парламент әгъзасы һәм Монголия белгече Сасаки җәнаплары белән дә күрештем. Сасаки – япон милләтендә иң мәшһүр ораторларның берсе. Бервакытлар Төркестан Кытаен һәм Монголияне адым-адым гизгән, Монголия җәмәгатьчелегенең игътибарын үзенә җәлеп иткән, Монголиядән Япониягә бик күп студент китерткән. Хәтта шундый хәл дә була: Сасаки монгол алпавыты Тургут Ван улы Балта Тураны Япониягә алып килеп, Япон университетында укытып тәмамлатканнан соң, аны Кытай сараена Хасса армиясе рәисе итеп билгеләтә.

Сасаки – Көнчыгыш берлеге фикерен алга сөрүче шәхес. «Японнарның яшәеше – Көнчыгышның берлек булып берләшүендә. Японнар күпме генә алга китсәләр дә, Көнчыгыш берлеге фикеренә хезмәт итмәсәләр, киләчәкләрен тәэмин итә алмаячаклар», – дигән фикерендә нык тора.

Сасаки – японнарның ышануы буенча, тумыштан өстен кеше. Япон халкының күпчелеге кыска буйлы. Сасаки исә – гаять эре гәүдәле, озын буйлы кеше. Бу мөхтәрәм шәхес белән дә танышып дуслаштым. Бергә шактый вакыт үткәрдек, сөйләштек, фикерләштек. Ниләр турында сөйләшкәнебезне алда җае белән язып китәрмен.

## ЯПОН МӘКТӘПЛӘРЕ

Япониядә сәяхәт иткәндә иң олы максатым һәм өметем – япон милләте турында җитди һәм дөрес мәгълүмат тупларга тырышу иде. Японнарда мәктәпләрнең һәм укучыларының күплеге, белем алуга көчле омтылыш турында белә идем инде, әмма кулымда рәсми мәгълүмат юк иде. Тарихчылар җәмгыяте идарәсенә барганнан соң, түбәндәге мәгълүматларны алуга ирештем:

41 нче Мидидә (ягъни бу милади 1908 ел саннары һәм иң яңа статистик мәгълүмат дигән сүз) Япониядә мәктәпләр өч төркемгә бүленә: 1. Хөкүмәт ачкан мәктәпләр. 2. Халык (земство) мәктәпләре. 3. Аерым бер кеше тарафыннан ачылган мәктәпләр.

Хәзерге вакытта мәктәпләр шул өч исем белән аталып йөртeләләр икән: хөкүмәт мәктәпләре, халык мәктәпләре, шәхси мәктәпләр.

## БАШЛАНГЫЧ МӘКТӘПЛӘР

Башлангыч мәктәпләрнең саны түбәндәгечә: хөкүмәт мәктәбе – 3, халык мәктәбе – 26897, шәхси мәктәп – 225; барысы – 27125.

Башлангыч мәктәп укытучыларының саны: хөкүмәт мәктәбендә – 32, халык мәктәбендә – 121574, шәхси мәктәпләрдә – 912.

Башлангыч мәктәп укучыларының саны: хөкүмәт мәктәбендә – 1471, халык мәктәбендә – 5671466, шәхси мәктәпләрдә – 40761; барысы – 5713698.

Башлангыч мәктәпләрнең барысында да ир һәм кыз балалар бергә укыйлар.

## УРТА МӘКТӘПЛӘР

Ир балалар укый торган урта мәктәпләрнең саны: хөкүмәт мәктәбе – 2, халык мәктәбе – 229, шәхси мәктәп – 56; барысы – 287.

Ир балалар укый торган урта мәктәпләрдәге укытучылар саны: хөкүмәт мәктәбендә – 36, халык мәктәбендә – 4384, шәхси мәктәпләрдә – 1042; барысы – 5462.

Урта мәктәпләрдә укучы ир балалар саны: хөкүмәт мәктәбендә – 560, халык мәктәбендә – 90420, шәхси мәктәпләрдә – 20456. Урта белем алучы укучыларның саны – 41111436, Миди ир балалар урта

мәктәбен бетергәннәрнең саны – 15291.

Кыз балалар укый торган урта мәктәпләрнең саны: хөкүмәт мәктәбе –1, халык мәктәбе – 107, шәхси мәктәп – 25; барысы – 137.

Кыз балалар укый торган урта мәктәпләрдәге укытучылар саны: хөкүмәт мәктәбендә – 24, халык мәктәбендә – 1625, шәхси мәктәпләрдә – 362. Барысы – 2011.

Урта мәктәпләрдә укучы кыз балалар саны: хөкүмәт мәктәбендә – 356, халык мәктәбендә – 30420, шәхси мәктәпләрдә – 6497. Барысы – 37273. Кыз балалар урта мәктәбен бетергәннәрнең саны – 9179.

**ТӨРЛЕ МӘКТӘПЛӘР**

Төрле сәнәгать мәктәпләре: хөкүмәт мәктәбе – 2, халык мәктәбе – 62.

Укытучыларның саны: хөкүмәт мәктәбе – 12, халык мәктәбе – 1176.

Укучыларның саны: хөкүмәт мәктәбе – 975, халык мәктәбе – 19359.

Кыз балалар өчен ачылган бер укытучылар мәктәбе бар. Укытучылары – 45, укучылары – 365.

**СУКЫРЛАР МӘКТӘБЕ**

Сукырлар өчен ачылган мәктәпләрнең саны: хөкүмәт мәктәбе – 1, халык мәктәбе – 2, хәйрия мәктәпләре – 35.

Ир һәм хатын-кыз укытучыларның саны: хөкүмәт мәктәбе – 18, халык мәктәбе – 40, хәйрия мәктәпләре – 150.

Укучылары: хөкүмәт мәктәбе – 320, халык мәктәбе – 395, хәйрия мәктәпләре – 949.

Менә Япониядә мәгарифнең берьеллык рәсми статистик мәгълүматлары шулардан гыйбарәт.

Бу мәгълүматлар – мәктәп яшендәге балалар һәм яшьләр буенча. Болардан башка әле тагын олы яшьтәгеләр, эшчеләр, хезмәткәрләр өчен дә аерым-аерым бик күп мәктәп бар. Алар бу исәпкә кертелмәгәннәр.

Хәрби мәктәпләр, Диңгезчеләр мәктәпләре дә, шәхси университетлар да бу статистикада юк.

**ДӘҮЛӘТ УНИВЕРСИТЕТЛАРЫ**

Укытучылары – 503, студентлары – 7370, тәмамлаганнарның саны – 1426.

***

Бөтен Япония халкының (кореялыларны исәпләмичә) саны 51000000 булып исәпләнә, шуларның 6000000нан артыгы белем алу белән шөгыльләнә.

Инде шул рәвешле күзаллыйк: башта японнарның башка өлкәләрдәге алга китешен бу мәгълүматлар белән чагыштырып карыйк, аннары аларның фәнгә һәм мәгърифәткә булган омтылышларының, тырышлыкларының башка милләтләр белән чагыштырганда күпкә югары икәнен аңлау кыен түгел.

Японнарда белем-тәрбия бирү эшләре үз телләрендә алып барыла. Фәнни китаплар тулысынча үз телләрендә языла. Японнар мәктәпләренә чит илләрдә һәм чит телләрдә язылган китапларның тәрҗемәләрен турыдан-туры кабул итмиләр, мәктәпләр өчен үз телләрендә дәрес китаплары язалар икән.

Мәктәпләрдә укытылган китапларга чит тел сүзләрен мөмкин кадәр кертмәскә тырышалар. Хәтта яңа гына иҗат ителгән технологик җиһазларга да японча атамалар бирәләр. Мәсәлән, «почта» сүзе бөтен дөньяда «почта» була торып, японнар аңа да «йубин» дигән атама биргәннәр. Фотографиягә «шашин» диләр, «телеграф», «телефон» мәгънәләрендә дә үз сүзләрен кулланалар.

*Төрекчәдән*
***Асия Рәхимова** тәрҗемәсе* ■

Безнең мирас №11 ноябрь 2019

# КҮЛ – КҮЗ ЯШЕ

Сәгыйть Сүнчәләй

***(Хикәя)***

*Әдәбият тарихчылары хезмәтләрендә XX гасыр башы татар шигърияте үсешенә сизелерлек зур өлеш керткән Сәгыйть Сүнчәләйнең иҗат мәйданына аяк басу вакыты итеп 1910 нчы еллар күрсәтелә. Ә инде Әстерханда яшәгәндә үк «Борһане тәрәккый» газетасында хәбәрләр бастыруы, 1908 елда исә Д.Мамин-Сибирякның «Кара ханым», Л.Толстойның «Ильяс» һәм «Кафказ әсире» әсәрләрен тәрҗемә итүе аның иҗат биографиясенең башы итеп каралмый (мәсәлән, «Татар әдәбияты тарихы»ның 4 нче томында. 2016). Моның белән килешергә буладыр да. Алар яшь тәрҗемәченең иң беренче каләм тибрәтүләрен чагылдыра. Шагыйрьнең шактый тулы басмасы – «Әсәрләр һәм хатлар»ы (Казан, 2005) да 1909 елгы «Әҗәлгә хитаб» шигыре белән ачылуы да гаҗәп түгел. Әмма без Тукайның «җиде ел мөддәтендә себерү вә пакьләү күрмәгән «такмак бүлмәсе»н себерергә тотынып язылган «Уянгач беренче эшем» мәкаләсендәге «Килер заман, һәр язучының үзен, сүзен вә шәхси тормышын энәсеннән җебенә кадәр тикшереп чыгарлар әле» дигән васыяти сүзләрен истә тотканда, иҗатының әүвәлге сәхифәләренә дә игътибар итәргә кирәк, дип уйлыйм. Мәсәлән, югарыда телгә алынган тәрҗемәләре белән бер елда ук аның ачык имзасы («С.Сүнчәләй») белән «Күл – күз яше» исемле китабы басылган. 12 битле генә бу татарча текстның исеменә «башкорт хикәясе» дигән искәрмә дә китерелә. Мифологик яңгырашлы текстның эчтәлегендә сюжетның кайдан алынганлыгы, авторның аны реаль бер кешедән ишетү-ишетмәве турысында бернинди мәгълүмат китерелми. Китап басылган елда С.Сүнчәләйнең Пермь ягындагы Сараш авылы земство мәктәбендә укыта башлавын хәтергә алып, әсәрдә бәян ителгән мифның әлеге авылның (яисә бу як авылларының) халкы башкорт тикшеренүчеләре тарафыннан бүген дә башкорт итеп тә каралуына таянганда, авторның әлеге «башкорт хикәясе» дигән искәрмәсе куелу да нигезсез түгеллеге аңлашыла, мондый миф та чыннан да халыкта яшәгән булырга тиеш. Шунысы да мәгълүм: С.Сүнчәләйнең 1908 елда тәрҗемә итеп бастырган «Кара ханым» (Д.Мамин-Сибиряк) һәм «Ильяс, яки бәхет балдамы?» (Л.Толстой) тәрҗемә әсәрләре башкортлар тормышыннан алып язылганнар.*

*Шуны да әйтергә кирәк: дөнья халыклары фольклорында күлләр еш кына адәм баласының (балаларының) күз яшеннән хасил булуы кебек мифик ышанулар катнашында да карала (кайчакларда яшьләр арасындагы гыйшкый кичерешләр нәтиҗәсендә дә). Бу нәрсә – күлләрнең күз яшеннән барлыкка килүе башкорт фольклорында да чагылыш тапкандыр.*

*Минемчә, С.Сүнчәләй (кемнәндер ишетеп, язып алып) тәкъдим иткән «хикәя» үзе соңрак заманга караган чынбарлык реалийларын чагылдыра (аракы эчү, тәмәке тарту, холыксыз малай, мулла образы...).*

***Зөфәр Рәмиев,*** *профессор*

Сәгыйть Сүнчәләй Сараш авылында, 1908-1915 еллар

Мин бервакыт башкортларның гаять зур бер күленең кырыендан аның хәрәкәтен, дулкыннарының чылтырап, калтырап торганнарын карап, хозурланып тора идем. Тирә-як тын, кешесезлек. Мәзкүр күл сахраның нәкъ уртасына җәелгән иде. Аның күзгә шикелле ялтырап тора торган өстендә ул тирәдә яшәүче кошлар даимән очып йөриләр иде. Кайсы чума, кайсы йөзә, кайсыберсе очып китә иде. Ул күлдә нинди генә кош юк дисеңме? Төрлесе бар.

Әнә, бер кырыйда гагар дигән кошлар көлешеп, каткылдашып, су эченә чумып уйныйлар. Андан арырак әллә ничә төрле үрдәкләр йөзә, күлнең уртасында киек казларның гигылдаулары ишетелә.

– Әйдә әле, үрдәкләр бөтенләй су кырыена килде, – дип, янымда иптәш булып йөри торган Шаһ-әкрәм исемле башкорт баласы бездән ерак түгел генә җирдә суда йөзеп йөрүче берничә үрдәккә күрсәтеп хитаб кылгач, без бөгелеп-бөгелеп кенә аларның тугрысына читтәнрәк китдек. Ул калды. Мин, акрын гына су кырыена – үрдәкләр тугрысына җиткәч, мылтыкымны алып төзәдем. Атарга гына дигәндә, әллә нәрсәгә бәрелдем дә, кулдан мылтыкым төшеп китүе берлән тынык тавыш берлән атылып

киткәч, тавыш күл буенча яңгырап китте. Ахырда әллә кайда еракта – сахрада тавыш тынды. Үрдәкләр дә, канатларын күтәреп очып, күлнең аргы кырыена китделәр.

Шаһ-әкрәм: «Ник инде тиерә алмадың?» – дип, очып киткән үрдәкләр артыннан күзләрен терәп карап калып, мине тиргәде.

– Бик ашыгылды. Әллә нәрсәгә бәрелеп аудым. Мылтык кулдан төшеп атылды. Бер дә курыкма. Бара төшиек әле. Бер хили (бик күп. – ***З.Р.***) тотарбыз әле, – дип, Шаһ-әкрәмне ничек булса да җуатырга тырышып, йомшак сөйләдем.

Акрын гына китде. Юлда барганда бер хили үрдәк очраганга, Шаһ-әкрәмнең бәхетенә, аларның берничәсен атдым. Ул вакытта минем күземә шәркый табигать ялангач шикелле ачык күренде. Мин, Шаһ-әкрәмнең җәрәхәтләнгән кошлар артыннан суга төшеп, аларны тоткач, һавага тотып торганын хозурланып карап тора идем. Ул тоткан саен шатлана, рәхәтләнә иде.

Бу күлнең актык кырыена кадәр барганчы көн кичкә таба авышкан иде. Кояш әллә кая гына яшеренгәч, һава яңарды, сафланды. «Безгә китәргә вакыт түгелме инде?» – дип, Шаһ-әкрәмнән соравыма ул да: «Нигә китәргә кирәк? Әйдә, күлне әйләнеп чыгыйк. Анда үрдәк хисапсыз күп!» – диде. Мин дә, ул чакырган тарафка карап, юлның бик ераклыгын белдем.

– Юк, Шаһ-әкрәм, соңыннан кайчан булса да әйләнербез, – дип киреләнсәм дә, ул, һаман үз сүзендә торып:

– Әйдә барыйк, минем әспискам (шырпы. – ***З.Р.***) бар. Ут ягарбыз, – дип, кесәсендән бер савыт шырпы күрсәтте.

Мин дә чарасыз разый булдым. Күлнең тирәсен әйләнергә икәү килдек. Бара-бара камышлыкны да уздык. Бара торгач, су янында бер биегрәк йиргә мендек. Анда күлнең әйләнәсе бөтенләй күренә, хәтта сахраның ерак тарафлары да күренә иде. Күл өсте томан берлән каплана башлады. Һава сафлыгыннан салкынга әверелде.

Күл өстендә вак кына дулкыннар хасил булды.

Юлның яртысындан күбрәге барылгач, аякларымның арганлыгын сиздем, чөнки юл комлык иде. Ул да җитмәсә, билгә дә авыр мылтык асылынган.

Бераз тынарга кирәк, дип, үз-үземә уйлаган гына идем, су кырыендарак әллә нинди бер кара күләгә күренде. Шаһ-әкрәм дә, күргәч, миңа таба кысыла башлады.

– Исәнме, таныш! – дип, әлеге кара күләгәдән тавыш ишеткәч, без, бер Әхмәтҗан исемле карт балыкчы икәнен сизә торып:

– Әхмәтҗан агай! Синме? – дип соравымызга ул да:

– Әхмәтҗан булмыйча кем булсын, шырпы бармы? – диде.

Кич булды.

Шаһ-әкрәм, аның шул сүзләрен ишетүе берлән, әллә кая йөгереп китде. Бераздан итәгенә чыбык-чабык, коры камыш төяп китерде. Ут кабызды. Без ул вакытта Әхмәтҗан карт берлән читтәрәк утырып тора идек. Бер минут үткәч, Шаһ-әкрәмнең уты, кабынып, безнең тирә-ягымыздагы кара караңгылыкны югалтып, бераз йирне яктыртты.

Мин ут кабынгач кына Әхмәтҗан картның төсен яхшылап карадым. Аның башында иске, тузып беткән түбәтәй берлән сакал-мыегы ап-ак, читләре бераз кырыкган иде. Күзләре тонган, даимән яшь берлән тулган булып, күлмәгенең изүе ачык булганга, аның җирән төстә төкле күкрәге күренә иде. Чалбары бик кыска булып, буй-буй төстә иде. Үзеннән бер-ике сажин читтәрәк аның җәтмәсе тагылган иде. Шул йирдүк тотылган балыкларны сала торган чиләге дә ауланып ята иде.

Әүвәл үрдәкләремнең барлыгын күргәч, берсен алып, аңарга кызганыч күзе берлән карап:

– Ашарсыңмы? – дип соравына мин дә:

– Иртәгә ашармын, – дидем.

Сөкүт (тын тору) дәвам итде. Ә Шаһ-әкрәм үзенең уты берлән мәшгуль иде. Мин күлгә карадым. Күлнең өстендә ап-ак томан һаман арта барганга, караңгылык кими, югала бара иде.

Бездән ерак түгел йирдә челән кошына охшаган кошның куркынычлы тавышы ишетелде.

– Шайтан кычкыра, – дип, Шаһ-әкрәм күзләрен ачып әйткәч, мин дә, аның курыкканлыгын белеп:

– Син шайтаннан куркамсың? – дип соравыма:

– Андан куркырга ярыймы соң? Безнең халык аннан курыкмый, – дип әйтеп, Әхмәтҗан картка карады. Ул исә, хозурланып, уттан күзләрен алмый иде.

– Сездә шайтаннар күпме? – дип соравыма ул да:

– Белмим, монда аз, әмма урманда туп-тулы, ай-йай, анда бер хили бардыр. Ә сезнең халык алардан куркамы? – диюенә:

– Синең шикелле кечкенә балалар куркалар, – дидем. Бу сүзләрне мин әйткәч, ул минем күзләремә карап миндә шайтаннан курыкмау галәмәтен күреп, тынычланды.

Ерактан, әллә кайдан һавада очып килә торган торналарның каркылдаулары ишетелде. Бераздан бөтен көтүе берлән безнең тугрыдан очып киттеләр. Күл дулкынлана башлады.

– Нихәл, Әхмәтҗан агай, әле җәтмә салырга ярыймы? – дип, уйга чумып тора торган әлеге балыкчы карт Әхмәтҗандан сорадым. Ул да:

– Нинди ул салу, дулкын бата. Төн урталарындарак салырмын. Әмма «Шәех яше» бүген бераз шаулар бугай, – дип, акрын гына калтыраган дулкынларның шаулаганын тыңлап әйтте.

– Нинди «Шәех яше»? Бу – су ич, – дип, аның сүзен күзәтмәкче булсам да, ул да һаман:

– Су дулкыны түгел шул. Син әле бу күлнең нәрсәдән килгәнен белмисең, – диюенә мин дә:

– Юк, – дидем.

– Юкка гына елмаясың, еларга кирәк инде, – дип, Әхмәтҗан карт минем яныма якынлашып утырды да: – Без дә әүвәл замандарак еламый идек. Миңа әти сөйләде, әтигә мулла сөйләгән, аңар бер гакыллы, тәдбирле «ак мулла» дигән бер мулла сөйләгән. Ул инде күптән вафат. Андый картлар безнең авылда бер дә юк, – диде дә, күлдән сөйләргә рөхсәт сораган шикелле булып, күл өстенә бераз карагач, тагын үзенең тарихын сөйләргә кереште. – Әүвәл заманнарда монда күл бер дә булмаган. Тик бу урында бер кечкенә генә чишмә булган. Һәммәсе комлык, сахра булган. Менә инде ул чишмә буш кына бер су булмаенча, ул изге су булган төрле яктан авырулар килеп, шуны сөртенгәч, төзәлеп киткәннәр. Бае да, фәкыйре дә – һәммәсе килгән. Аллаһ аларга ярдәм иткән. Кулы сынса да, аягы сынса да монда килеп шул су берлән сөртенеп, төзәлеп китә торган булган. Ә хәзер кулыңны сындырып кара әле. Үләсең, тизрәк дуктырга йөгерергә кирәк. Ул заманны халык таза булган, сәламәт булган, рәхәт яшәгән, – дип әйткәч, Әхмәтҗан картның тамагы кысылып, бер зур сулыш алып җибәрде. Тагы сүзенә керешеп: – Ул заманда безнең авыл бик зур булмаса да халык бик бай булган. Үлән күп булган, җир күп булган. Кышын халык өйләрендә яткан, ә җәен кырда йөргән. Урман зур булган. Ә хәзер бер дә юк, казна үзенә алды. – Әхмәтҗан картның тавышыннан аның әүвәлдәге урманны кызганганлыгы аңлашылды. – Ул заманда безнең авылда бер изге карт, ягъни әүлия булган. Аны һәр

йирдә халык белгән, ул төнен дә, көнен дә бертуктамыйча Аллага гыйбадәт берлән мәшгуль булган. Ул бер кечкенә генә өйдә бер баласы – угылы берлән торган. Карт малай начар холыклы, явыз булганга, атасының сүзләрен тыңламаганга, аны авыл халкы да, атасы да сүккән, хурлаган, әрләгән. Бөтенләй шайтан булган. Үзеңә мәгълүм: шайтан азгын кешенең дусты булганга, аңарга төрле гөнаһлы эшләр эшләргә кушкан. Аракы эчәргә кушкан. Тәмәке тартырга кушкан. Коръән укымаска кушып алдаган. Ә малай шайтанның бу сүзләренә ияргән. Атасы малайның азып йөрүеннән Аллага шикаять итеп егълый булган. Көн дә, кояш баткач, шул су янына килеп, Аллага гыйбадәт кыйлып егълый булган. Аның зарын Алла ишеткән, урман ишеткән. Ул бик каты егълаган.

Әхмәтҗан карт, сүзендән туктап, картнаң егълаган тавышы ишетелми микән, дип, колагын салып торса да, тирә-як тып-тын, тик су дулкыннарының чыпырдаган тавышы гына колагына ишетелә иде. Ул, тагы сүзенә керешеп:

– Шуннан соң Аллаһы Тәгалә бу изге мулланың яшен халыкка таптатмас бер эш эшләгән. Изге эш эшләгән. Кайсын ки халык булдыра алмый, – дигәч, мин:

– Нәрсә эшләгән, әллә бер бер могҗизамы? – дип сораган идем.

Ул, тагы сүзенә керешеп:

– Билгеле шулай. Әлеге карт мулла Шәех кичләрдә яшь түгә-түгә, ул яшь бер зур күлгә әйләнгән. Күл зурайган саен, урманны, игенне, үләнне баскан. Ул вакытта авылның бер мулласы әлеге Шәехнең углына:

– Атаңның күз яшеннән хасил булган күлгә барып аны аягың берлән таптама, үләрсең, атаң каргар, – дисә дә, малай шаян, азгын булганга, аның сүзен тыңламаган: «Бик артык куркырга әллә мин гакылсызмы?» – дигән дә, су буена киткән. Авыл халкы иртә: «Ул малайны атасының күз яшендә коенган өчен ничек үтерер икән?» – дип, су янына киткән. Тик Шәех үзе генә бармаган.

– Йә, малайны нишләткәнме, әллә өенә кайтканмы? – дип сорагач, ул, тагы сүзенә керешеп:

– Кайда ул кайту!.. Шулай коенырга киткәч, атасының күз яшендә коенган. Әйтергә дә гөнаһ! Аллаһы Тәгалә аның бу эшенә ачуланган. Шул кичне бик каты күк күкрәгән, яшен яшьнәгән. Кич артык караңгы булган. Җил каты булган. Малай атасының яшендә коенганда дулкын үзен алып, төрле якка бәргән, суккан. Уртага алган, аннан кырыйда үзен йөрткән. Ахырда, кырыйдарак бер зур ташка суккан. Син бит безнең зур ташларны күргәнсең? Шуннан соң малай үлгән. Халык иртә берлән аны атасына күтәреп китергән. Атасы аны үлек күреп, бик каты егълаган, – диде.

Әхмәтҗан картның тамагы бөтенләй кысылды. Тирә-як гаять караңгы иде. Ап-ак томан безне күл берлән бергә каплап алды. Әллә кайдан башкорт атларының тавышы ишетелә иде. Җил яхшук өрә иде. Шаһ-әкрәмнең уты күптән сүнгән, тик бер-ике генә утлы күмере ялтырдап тора иде. Күл шаулый. Күлнең шаулавы башка бер тавышларны бетереп, әллә нинди, назлы гына, йомшак кына һәм сузылып китә торган бер тавышларның ишетелүе минем башыма яңа гына сөйләп бетергән башкорт балыкчының хикәясендәге егълау тавышының әсәре сеңгән шикелле булып тора иде.

*Текстны журналга* ***Зөфәр Рәмиев*** *әзерләде.* ■

ЗАКИР РӘМИЕВНЕҢ (ДӘРДЕМӘНДНЕҢ) ТУУЫНА 160 ЕЛ

# ДӘРДЕМӘНДНЕҢ
# *барланмаган иҗат үрнәкләре*

Лирон Хәмидуллин

*Закир (Мөхәммәдзакир) Мөхәммәдсадыйк улы Рәмиев 1859 елның 23 ноябрендә Агыйдел елгасы буендагы Җиргән авылында туган. Ризаэддин Фәхреддин төзеп бастырган шәҗәрәдә аның бабасы Габделкәрим, бабасының атасы Исмәгыйль һәм аның энесе Сәлим мулла хәзерге Әлмәт районының Тайсуган авылыннан чыкканнар, дип күрсәтелә. 1774 елда туган Габделкәрим, Тайсуган мәдрәсәсен тәмамлагач, шул тирәдәге бер авылда мулла вазыйфасын башкарган, диелә. Морза Исмәгыйльнең һәм аннан элгәреләренең кем булганлыклары билгесез, дип яза Ризаэддин хәзрәт. Агыйдел буенда 1780 нче елларда төзелә башлаган Эстәрлетамакка иң элек Сәлим мулла килеп урнаша. Бераздан ул шунда агасын да чакырып ала. Һәм Исмәгыйль (?-1801) Эстәрледән кырык чакрымга үрдәрәк урнашкан Җиргән авылында сәүдә эшенә керешә.*

Дәрдемәнднең соңгы тапкыр чит илдә булуына бәйле күмәк фотосурәт:
Утырганнар (уңнан): Закир Рәмиев-Дәрдемәнд; абыйсы Шакирның кызы Камилә Максудова, Закирның кызы Зәйнәп Вәлиева (язучы Ярулла Вәли хатыны), Шакир Рәмиевнең улы Әхмәт-Мидхәт Рәмиев; басып торалар: Камиләнең ире Садри Максуди, Закирның улы Гариф Рәмиев (Шакирның улы белән икесенең хәзерге Бельгиядәге Льеж шәһәре югары уку йортында укыган еллары), Закирның улы Искәндәр Рәмиев – фотога төшкән 1914 елда Германиядә югары уку йортын тәмамлаган вакыты). 1914, Льеж шәһәре
Бу сәяхәт вакытында алар Парижда, Римда һәм Истанбулда булалар, диелә. Римда төшкән фотолары бар (Закир, Зәйнәп, Камилә, Садри – дүртәү Ватикан мәйданында)

*Бәлки ул Тайсуганда вакытта ук шул эшне башкаргандыр. Авылларда төпләнеп яшәгән морзаларның күпчелеге элек-электән йә мулла яки сәүдәгәр булган бит инде. Гомер чигенә җитәрәк, ул монда Габделкәримне дә чакырып китерә һәм «сәүдәгәрлек эшен улына тапшыра». Әлеге шәҗәрәдә Габделкәрим улы Садыйкның Җиргәндә туганлыгы әйтелә. (Ул 1828 елда туа һәм 1892 дә вафат була.)*

Булачак шагыйрьгә өченче яшь булганда Садыйк гаиләсе Урал-тауның көнчыгыш өлешендә урнашкан Юлык авылына күченеп килә (җир асты байлыкларыннан бакыр белән алтынга бай булган Орск өязе биләмәсенә). Элек вак-төяк сәүдә белән көн күргән Садыйк та бераздан монда берәүнең зур табыш китерми торган алтын чыгару приискасын сатып ала. (Алтын бөртекләре җирнең өске катламнарында гына булганлыктан, аларны казып чыгару урыннарын шахта дип түгел, прииска рәвешендә атау кулланыла.) Шуннан соң Садыйк үз гомерендә егермеләп прииска тотуга ирешкән. (Табыш китерми башлаганнары, «искергән-ташланган»нары да шул исәпкә керә.)

Садыйк хаҗиның хатыны Хәнифә Дашкова да – атаклы морзалар нәселеннән. Алар 1850 елда өйләнешкәннәр. Әлеге гаиләдә, шәҗәрә дәвамчылары буларак, ике ул – Шакир (1857-1912) белән Закир (1859-1921) Рәмиевләр үскән. Бу балалар үскән вакытта Юлык авылында башлангыч мәктәп кенә эшли. Хәнифә, бик укымышлы кеше буларак, малайларын өстәмә рәвештә үзе укыткан, үзе үк аларга русча башлангыч белем дә биргән, дип язалар истәлекләрдә. Борынгы төрки әдәбият үрнәкләре белән дә иң элек аналары таныштыра. Риза хәзрәт Фәхреддин, Уфада Шакир Рәмиев белән тәүге очрашуын искә төшергәндә: «Ул мине Нәваи, Сәгъдиләр шигырьләрен яттан белүе белән гаҗәпләндерде», – дип яза.

Үсә төшкәч, инде бу балалар укуларын Юлыктан йөз кырык чакрымдагы шәһәр мәдрәсәсендә – Орск каласында дәвам иттерәләр.

Шушы калада 1880 елда укуын тәмамлагач, Закир Төркиягә китә. Монда ул махсус уку йортына кереп укымый, төрек телен һәм әдәбиятын үзләштерүгә күбрәк әһәмият бирә.

Закир Рәминең кулына каләм алып иҗат итә башлавы Төркиядә яшәү елларына туры килә. Шул ук елларда ул «Дәрдемәнд тәхәллүсен ала», дип фаразлый галимнәр. «Истанбулда төрек телен үзләштерә, төрек әдипләре белән таныша. Ирекле рәвештә университет галимнәре дәресләренә йөри», – дип искә алалар соңрак аның даирәсенә кергән шәхесләр.

Орскига, Шакир агасына ул Төркиядә нәшер ителгән газета-журналларны, китапларны даими рәвештә җибәреп торган. Абыйсының аңа язган берничә хаты сакланган. «Цензорлар газеталардагы кайбер сүзләрне сызып ташлаган», – дигән җөмләләр дә очрый. «Китапларны рөхсәт ителгән күләмдә җибәреп тор. Безнең халыкка шундый китаплар бик кирәк», – дигән тәкъдимнәр дә бар ул хатларда.

Дәрдемәнднең Төркиядә яшәгән 1880-1881 елларда шигырь иҗат итә башлаганлыгы да, кечерәк күләмле чәчмә әсәрләрне тәрҗемә итәргә керешкәнлеге дә мәгълүм. Һәм аның бу хезмәтләре үз илендә чирек гасырдан соң гына басылып чыга.

Әдәбият фәнендә: «Дәрдемәнднең тәүге шигырьләре 1902-1903 елларда Кырымда чыгучы «Тәрҗеман» газетасында күренә башлыйлар», – дип әйтелә. Ризаэддин Фәхреддиннең 1903 елда нәшер ителгән «Әсма, яки Гамәл вә җәза» әсәрендә, авторы күрсәтелмичә, аның «Үткән көннәр» шигыре басылып чыга. Ул елларда Уфада яшәгән «Әсма...» әсәре авторына әлеге шигырьнең кайчан һәм ничек килеп кергәнлеге ачыкланмаган. «Үткән көннәр»дә, бәлки, «Тәрҗеман»да яисә Кавказда нәшер ителүче

Дәрдемәнднең соңгы еллардагы фотосы. Уртада – кияве Гариф Камалов, уңда – шагыйрьнең өлкән кызы Өммегөлсем. Оренбург

башка бер газетада, яки Кырым татары Ильяс Браганскийның С.-Петербургтагы типографиясендә туплап чыгарылган берәр җыентыкка кергән булгандыр. Закирның «Каргалының Сибгатулла хаҗига мәктүб» шигырен ел ярым чамасы, Төркиядә яшәп кайтканнан соң, 1884 елда Юлык авылында тәмамлаганлыгы мәгълүм. Соңрак ул шигырь «Шура» журналының 1908 елгы 1 нче санында, Дәрдемәнд вафатыннан соң чыккан «Дәрдемәнд әсәрләре» белән «Исә җилләр» китапларында нәшер ителә.

1950 нче елларда Дәрдемәнд иҗатын барлауга зур өлеш керткән, аның варислары белән аралашкан галим Мөхәммәт ага Гайнуллин: «Дәрдемәнднең Истанбулдан кайткач... төрекчәдән татарчага берничә җиңел хикәя тәрҗемә иткәнлеге, шигырьләр яза башлавы турында ... мәгълүматлар бар», – дип белдерә. Исмәгыйль Рәмиев тә: «Аның тәрҗемә хикәясе «Шура»да басылган иде», – дип яза. Дөреслектә «Шура» журналында Дәрдемәнд тәрҗемә иткән өч проза әсәре басылган икән. Миркасыйм Госманов белән Раиф Мәрданов туплап чыгарган «Шура» журналының библиографик күрсәткече» китабында (2014) алар һәм Дәрдемәнднең бу мәҗмуга битләрендә урын алган барлык шигырьләренең исемнәре теркәлгән. Ә әлеге өч тәрҗемә чәчмә әсәрнең берсе шактый зур күләмле булып, ул «Шура»ның 1909 елгы өч санында басылып чыккан. Соңгы тәрҗемә әсәрдән кала, барлык хикәя һәм нәсерләр, шул исәптән автор тарафыннан балалар өчен махсус язылганнары да Дәрдемәнднең үз гомерендә нәшер иткән бердәнбер китабында – «Балалар өчен вак хикәяләр»е (1910, «Вакыт» басмаханәсе, Оренбург) битләрендә урын алган.

«Вакыт» газетасы мөхәррире Фатих Кәриминең (1870-1937) хәбәр итүенчә, Дәрдемәнд Төркиядә чакта европача яшәү рәвешен чагылдырган бер француз романын да тәрҗемә иткән. Төрекчә нөсхәдән күчереп, әлбәттә. Әмма иленә кайткач һәм әлеге тәрҗемәне кабат күздән кичереп чыккач, аны «безнең мохиткә бу әсәр бармый», дип ертып ташлый.

Ә инде 1906 елдан соң шагыйрьнең иҗат үрнәкләре әүвәл «Казан мөхбире», аннары «Вакыт» газеталарында, «Шура» журналында әледән-әле күренә башлый. «Дәрдемәнд» тәхәллүсе белән кемнең иҗат иткәнлеге ачык билгеле булмаган көннәрдән үк аның шигырьләре укучы күңелен җәлеп итә, телгә керә. Мисал итеп, шул чорның әдәбият галиме Габдерахман Сәгъдинең «Шура»да (1911) басылган «Шагыйрьләр һәм шигырьләр» хезмәтен искә төшерик. Шагыйрьнең үзенчәлекле иҗатына уңай бәя биргәннән соң ул: «Дәрдемәнднең кем булуы безгә мәгълүм түгел», – дип тә өстәп куйган. Яңарак кына Төркиядән кайтып, чит-ят җирләрдә укытып йөргән Г.Сәгъди түгел, Оренбург, Казан, Уфаларда яшәүче иҗат кешеләренең дә күпчелеге байтак вакыт Дәрдемәнд тәхәллүсе белән язучының кем булуын белмәгәннәр. Ә шагыйрьнең хикмәтле сүз-әйтемгә, сәнгати төгәл сурәтләүгә бай шигырьләре белән

кызыксыну көннән-көн арта барган. Мәгәр, шигырь җыентыкларын кат-кат чыгару мөмкинлекләренә ия кеше булса да, Дәрдемәнд аларны үзе исән вакытта бер китапка туплап чыгармаган.

Дәрдемәнд иҗатында тормышка милләт язмышы аша караш – төп сыйфатларның берсе. Аның күпчелек шигырьләре берничә строфадан гына тора. Ләкин шул уналты-егерме юллык әсәрдә ил, ватан, милләт язмышын күз алдына китереп бастыру хас. Милләте турында уйлануларын ачык итеп әйтмәгән хәлдә дә, аның әсәрләрен укыганның соңында, күңелдә шул хис яңара. Ирексездән милләтеңнең үткәне һәм киләчәге турында уйлана башлыйсың. Аларда кеше язмышы да, борынгы тарих рухы да, киләчәк өмет нурлары да күз алдыннан җемелдәп үтәләр.

«Дәрдемәнд татар әдәбияты дөньясына сигезенче елның башында куәтле тавышлар илә шауламакта булган диңгезнең дулкыннарын ярып барган могҗиз «Кораб» өстендә заһир (пәйда) булды... «Менә татар сәнгате әдәбиясе күгендә яңа бер йолдыз заһир булды», – димешләрдер. Чөнки аңарда, чынлап та, яңа рух сизелә – ниндидер әдәби мәдәнилек, чын каләм сәнгате, матур өслүб, җыйнак вә кыска тәкъбирләр... Гүя ул, ниндидер бер сихерле куәт белән, әйтергә теләгән мәгънәсен йөрәгеңә турыдан-туры яра да сала... Алыйк, «Кораб»ны, «Без»не, «Өмидләр», «Бүзләрем мана алмадым», «Бәллү»не... «Бәллү», югарыда сөйләп килгән һәммә кәмалләрне (камиллекне) үзендә җыйдыгы кебек, өслүбенең матурлыгы, гаҗәеп аһәңе илә дә бөтен матбугатымызда беренче урынны аладыр», – дип язган иде Галимҗан Ибраһимов 1913 елда чыккан «Татар шагыйрьләре» очеркында.

Кайчан, кайларда өйрәнгән, ничек ирешкән шагыйрь андый осталыкка?

Казан ханлыгы чоры морзаларына бәйле шәҗәрәсе булуына карамастан, ул гап-гади бер татар авылында туган, гадәти татар мәктәп-мәдрәсәләрендә белем алган. Гади халык арасында яшәп, аның моң-зарын имчәк сөте белән үк күңеленә сеңдергән. Буй җиткән, яшәгән төбәге дә бик тә үзенчәлекле – татар, башкорт, казакъ ише кардәш халыкларның укмашып көн күргән, тел-лөгать алмашкан урыны – Урал-тауның көньяк-көнчыгыш төбәге. Шагыйрь иҗатында алар да чагылыш табачак: башкортларның моңлы озын җыр-кубаерлары, казакъ акыннарының кыллы кубыз, думбыра чиртә-чиртә тапкыр сүз әйтеш бәйгеләренең йогынтысы Дәрдемәнд шигырьләрендә бик ачык сиземләнә.

Дәрдемәнд иҗатына карата үз бәяләмәсен язганда, Г.Ибраһимов фикерләрен икенче бер әдип һәм галим Габделбари Баттал да куәтли. 1925 елда Төркиядә басылган «Казан төрекләре» китабында ул: «Дәрдемәнд – мәгънә ягыннан фикерче бер шагыйрь... Шигырь төзелешендә тиешенчә хәбәрдар... аһәңгә, рифмага һәм вәзенгә бик игътибарлы. Һәм, бу яктан караганда, Казан төрки шагыйрьләре арасында иң өстен шагыйрьләрнең берседер. Иске төрки әдәбияты белән дә җитди шөгыльләнгән, Нәваи, Лотфи, Бабур кебек чагатай шагыйрьләренең җыентыкларын игътибар белән укыган булуы да ачык билгеле. Шуңа күрә Дәрдемәнд шагыйрьләр арасында иң белемлесе саналырга хаклы», – дип яза.

1959 елдан башлап, Дәрдемәнднең шигырь җыентыклары даими рәвештә диярлек чыккалап тора. Ә аның тарафыннан язылган яисә тәрҗемә ителгән чәчмә әсәрләргә, никтер, әһәмият ителми. Әдәбият сөючеләрне алар белән дә таныштыру кирәктер, дип беләм. Мәсәлән, аның каләме һәм күңеле аша уздырылган, 1909 елдан соң бер мәртәбә дә искә алынмаган «Абакамның көтепханәсе» чәчмә әсәре белән кабат танышу беребезгә дә зыян итмәстер, дип уйлыйм. ■

# АБАКАМНЫҢ[1] КӨТЕПХАНӘСЕ [2]

**Госманлы төрекчәсеннән күчерелде, мөәллифе *(язучысы)* – Тепфер.**
**Мөтәрҗиме *(тәрҗемәчесе)* – Дәрдемәнд.**
**(Асылы немецчә язылмыштыр.)**

Аталарның магазиннарында торып үскән бәгъзе адәмнәр инсаннар хакында өстән генә, күбесенчә магазин ишеге төбендә торып, килгән-кичкәннәрне сәер итмәк *(читтән карап тору)* вә урамнарда йөреп, ялгыз күрше-тирәләрнең әхлак вә гадәтләрен өйрәнмәктән гыйбарәт мәгълүмат кәсеп итмешләрдер. Бу адәмнәр арасында министрлык яки адвокатлык сыйныфына кергәннәр дә булынмыш исә дә, магазиннарыннан ияртеп барган фикер вә тәрбияләреннән һичбер вакыт тәмам котылып җитә алмамышлардыр.

Ул вакытлар башка адәмнәр өй кыекларыннан башка һичнәрсә күренмәгән бүлмәләр эчендә хәбәрсез көн кичермәктә иделәр. Болар базар вә сәүдә эшләрен кирәге кадәр белеп җитә алмасалар да, бу кимчелек урынына, даимә күрше-тирәләренең хәл-әхвәлләрен тикшерүдән буш калмый, ичмасам, бу юлда булсын, инсаннар хакында бераз мәгълүмат хасил иткәннәрдер.

Инде, әй, министрлар вә адвокатлар сыйныфыннан булган затлар! Сездән сорыймын: бүлмәсе эчендә ялгыз торып гомер иткән бер адәм белән магазин ишегенә сөянеп, килгән-киткәннәрне сәер итмәк белән мәшгуль булган адәмнең дәрәҗәи мәгълүматлары бермедер?

Никадәр дә мөшкел бер эш! Син бер тарафтан бер дустыңның вә йә бер китапның өйрәтүе буенча балаңның фикерен, күңелен тугры юлга күндерү иҗтиһады белән интеккәнсең дә, икенче тарафтан ничә төрле нәрсәләр, тавышлар, күршеләр, белмим, янә ниндәен вакыйгалар, синең зарарыңа яхуд файдаңа сүз беркетеп, ишеңә катышалар ки, тәэсирләреннән котылырга бертөрле чара таба алмыйсың.

**Шагыйрьләр гүзәл, рухани кызларга гыйшык, мәхәббәт итәләр, әмма гади хатыннардан башкасына очрый да алмыйлар.**

***

Минем торган мәхәлләм (Сан-Пьетро) чиркәүнең артындагы епископ хәбесханәсе якыннарында, аулак бер төбәктә иде. Бүлмәмнең тәрәзәләре астында үскән акация агачларының өстеннән чиркәүне, чаң манарасының түбәнге кисәген, хәбесханәнең бер тәрәзәсен вә күлнең бер микъдарын күрә алмакта идем. Әгәр ялгыз шуларны хөсне истигъмаль итә *(күркәм итеп файдалана)* белгән булса идем, миңа башка балаларга караганда, күп ярдәм итмеш булачак иде. Моны һичбер вакыт инкарь итмим. Мин ул мәктәптән, ягъни ул күренештән бераз файдалана белгән булса идем, һәрхәлдә магазин ишегенә сөялеп үскән, яхуд бүлмәсе эчендә хыяллар белән мәшгуль булган бер адәмнән үземне, әлбәттә, мәгълүматлырак хисап итәр вә шундаен бер мәктәптән җитешмеш бер егет булганым өчен, горурланыр да идем. Әгәр табигыятемнең дә бераз ярдәме булган булса иде, мин ул бүлмәнең эченнән һичшиксез бер шагыйрь булып чыгар идем.

***

Ләкин ник ялган сөйлим! Бу көем, ягъни хәзерге хәлемдә калуым янә дә

[1] Абака – ата белән бертуган ир кардәш. (Авт. иск).
[2] Әсәрдән өзек.

хәерлерәктер. Чөнки бер шагыйрьнең бәхетле булуында шөбһәм бар. Юкса, син шагыйрьләр арасында исем вә шөһрәтен баса алган берәрсен таныйсыңмы? Танысаң, сөйлә! Яки шигырьләре даими хөрмәт вә игътибарда йөргән олуг шагыйрьләрдән берәрсенме беләсең, ул хыялдан чыккан сәмави *(күккә бәйле)* тасвирларны хакыйкать күзе илә күрә алган булсын? Әй, өсте дам *(тозак),* мәхрүмлекләр вә нәүмизлекләр белән тулы булган галәм! Без синең заһир *(ачык)* хәлеңне генә күрәбез. Юкса, эчеңдә кем белә, янә ниндәен бәлаләр, мосыйбәтләр *(кайгы-хәсрәтләр)* бар!

Шагыйрьләр үзләре өчен асылсыз, табигый булмаган бер бәхет вә сәгадәт тасвир итәләр. Күзләрен югарыларга, күк йөзләренә күтәрәләр, әмма үзләре җир өстенә баглы. Гүзәл, рухани кызларга гыйшык, мәхәббәт итәләр, әмма гади хатыннардан башкасына очрый да алмыйлар.

***

Әй, кальбләр *(йөрәкләр)*! Сез ки нечкә вә нәзек хәлләрне, гыйбрәтле вә хикмәтле мәгънәләрне сизәсез, инсан өчен җиһанда шәрәфле бер исем калдыруның никадәр зәхмәтле, никадәр дә кыенлыклар белән очрашканын сөйләгез!

Алар шагыйрь булганнары өчен бу зәхмәтләрне чигәләр, яхуд, бу зәхмәтләрне чиккәннәре өчен шагыйрь булалар. Укыган шигырьләре арасында, безнең хәйрәт *(аптыраган)* күзләребезне чагылдырган хыял нурлары, җилле-давыллы һаваларда болытлар арасыннан чыккан утлы ялтырамалар кебек, фикерләренең болганып-айкалып бер-берсенә бәрелешүләреннән хасил буладыр. Зәхмәтләре үзләренә шатлыклар тудыра. Шатлыклары зәхмәтләрен оныттыра. Менә бу даими әрнү, сызланулардан аларның иң югары әсәрләре барлыкка киләдер. Димәк, ул моңлы, матур тавышлар көчле, куәтле бер җил-давылның әсәре рәвешендә пәйда булалар.

***

Шагыйрь хакындагы фикерем тугрыдыр. Бер мәртәбә шагыйрь исемен күтәрергә тырышканнарның хәлләренә дикъкать итегез: алар көчләре җиткән кадәр мәшәкатьләргә керәләр, зәхмәтләргә йөкләнәләр. Бәгъзе адәмнәрнең күркәм әхлакны, тәрбияне матур сүзләр белән әйткәне кебек, шагыйрьләр дә гали *(югары)* хис вә фикерләрен кайгылы, дәһшәтле сүзләр белән тасвир итәләр. Шигырьләрендә азапланулар күрсәтәләр, зарлана-уфтаналар. Яшьләре егермеләрне үтәр-үтмәс күңелләре сүнмәгә йөз тота. Ниһаять, шигырьләре эчендә вафат итәләр. Менә боларның бары да шагыйрьлекне шул юлда башлыйлар.

Әй, дустым! Кайгылы, бәхетсез, өмидсез булу алай син уйлаганча ансат кына түгел. Хәсрәт газаплары чикмәк, күңел җилкендереп, күз нурларын югалтмак, бер көзге яфрак кебек саргаеп сулмак, минем белүемчә, чыдарга мөмкин булган дәртләрдән түгелдер. Әй, минем газизем! Өзлексез зарланмакта, атлаган саен уфтанмакта, халык күзендә үлгән, дәфен ителгән күренмәктә, әйтче, Ходай өчен, ни олуглык, ни шәрәф таптың?

***

Мин шуны аңлатмак буламын ки, иң күңел шатландырган, иң кызыклы шигырьләрнең дә эчләрендә бер моң, яшерен бер сагыш бар. Безне җәннәт кебек бер гөл бакчасына керткән, безгә бер матурны сәмави *(җирдә булмаган)* сызыклар белән тасвир иткән вакыт, үзен шунча иң югары дәрәҗәгә күтәргән нәрсә, карасаң, янә шул дөнья җәфасы. Бичара! Хаста булган өчен – сыйхәтне, сәламәтлекне, бозлар өстендә йөргәне өчен – матур җәйләрне, әйләнәсе каткак чүлләрне күргән өчен дә суык суларны сагынып тасвир итә.

*Шура. – 1909. – №4. – Б.103-106* ■

# ХӨСӘЕН МИРЗА

***Борынгы татар тормышыннан трагедия***

Фәтхи Бурнаш

***Иргали, Хәдичә***

**Иргали.** Кайда синең кызларың, егетләрең? Камчы татымыйча, сез һичнәрсә эшләргә теләмисез...

**Хәдичә.** Хәзер генә таралдылар. Мин көч-хәл белән аларны тоттым. Хәзер менә урманга алып барам.

**Иргали.** Барыгыз. Барырга теләмәгәннәрне миңа әйт. Мин аларның морҗаларыннан төтен чыгартмам, тамчы тамдыртмам. Әгәр шул көннәрне Бибисарамның саулыгы кайтмаса, күңеле күтәрелмәсә, мин сезнең үзмәләрегезне бәйләргә бер бөртек чәчләрегезне калдырмамын.

**Хәдичә.** Һәммәсе өеннән, ачлыктан зарлана, бер сүз тыңлатып булмый.

**Иргали.** Барыгыз, әгәр урманда Бибисараны яхшы сакламасагыз, һәрберегезгә агач төбе саен гүрегезне казытырмын. *(Сара керә.)*

***Сара, Иргали, Хәдичә***

**Сара.** Әйдә, Хәдичә!

**Иргали** *(Хәдичәгә)*. Бар, мин Сараны үзем озатырмын. *(Хәдичә китә.)* Бибисара, мин сиңа ничә тапкыр әйттем.

**Сара.** Мин артык сине тыңларга да теләмим.

**Иргали.** Син – авыру. Сиңа үзеңне бернәрсә белән дә борчырга ярамый... Бигрәк тә...

**Сара.** Дивана белән булырга ярамый, диярга телисең, мин беләм. Ул миңа сезнең һәммәгездән дә якынрак.

**Иргали.** Юк, мин беләм... синең йөрәгеңә Диванадан да якынрак кеше бар... Алай булса да...

**Сара.** Син, Иргали ага, Диванага тел тидерүдән саклан. Мин аны атамнан да шелтәләткәнем юк.

---

Дәвамы. Башы журналның 8 нче (2019) санында.

**Иргали.** Ләкин син үзеңне тагы да якынрак күрә торган бер кеше дә барлыгын аңларга тиеш идең.

**Сара.** Мин аны башыма да китерергә теләмим.

**Иргали.** Хода минем шаһитым булсын!

**Сара.** Әгәр чынлап шулай булса да, мин үземне моңа ышанмаска көчләр идем.

**Иргали.** Мин аңлыйм... Син әле һаман да диваналар хыялын башыңнан чыгарып ташларга теләмисең.

**Сара.** Әйе, аны һичбер кеше минем күңелемнән чыгарып ташлата алмас.

**Иргали.** Әнә шулай да булсын. Ләкин син аны икърар итүдән сакланыр идең...

**Сара.** Мин аны сөйсәмдәме?

**Иргали.** Бибисара! Синең аякларыңа егылырга мәҗбүр булган көннәремә нәләт төшсен! Ләкин әле мин һаман да өметләремне яндырырга база алганым юк.

**Сара.** Иргали ага! Бу сүзләрең миңа соңгы тапкыр ишетелсен.

**Иргали.** Син шуны хәтерлә, Бибисара: тау белән тау бер-берсенә якын килерләр, ләкин аның белән син...

**Сара.** Җитәр, Иргали ага!

**Иргали.** Юк! Син Мусаны тагын бер кат күрә алмассың!

**Сара.** Җитәр, димен!

**Иргали.** Күрсәң дә, син аңа артык йөрәгеңнән өлеш бирә алмассың!

**Сара.** Телләреңне синең шайтан алсын! *(Китә.)* Диваначыгым, тизрәк...

**Иргали.** Мин сиңа калганын соңыннан сөйләрмен.

***Иргали ялгыз***

**Иргали.** Әх, син, акылсыз кыз бала! Йолдызларга кулың җитсә җитәр, ләкин инде Мусага җитә алмас.

А! Ничек кенә сөйләсәң дә Мусаның исән үткәргән сәгатьләре минем өчен һәлакәттән башка нәрсә китермиләр. Ул хәзер минем кулымда бодай камыры шикелле сыгылырга тиеш. Ә аннан соң Сараның язмышы минем кулымда булачак.

*(Хөсәен мирза, Мәрьям бикә, капитан-исправник чыгалар.)*

**Хөсәен, Мәрьям һәм башкалар**

**Иргали.** Хәерле иртә, хуҗам!

**Хөсәен** *(капитанга)*. Рәхим итегез!

**Капитан.** Рәхмәт!

**Хөсәен** *(утырып)*. Ни бар, ни юк, Иргали?

**Иргали.** Сезнең миңа йөкләгән вазыйфаларыгыз һәммәсе дә үз җирендә, хуҗам. Илнең тынычлыгын кайтару өчен, мин мөмкин булган бөтен чараларны күрдем.

**Хөсәен.** Рәхмәт! Мин сине киләчәктә дә үземнең ышанычлы терәгем итеп күрергә телим.

**Иргали.** Капитан әфәнде сезгә сөйләгәндер. Без фетнәчеләрнең кайда булулары турында ышанычлы хәбәрләр алган идек. Тәдбирләр вакытлы һәм урынлы булганда, мин ул эшләрнең уңышлы чыгуына ышанам.

**Хөсәен.** Капитан әфәнде безгә кулыннан килгән бөтен ярдәмнәрне биреп торачак.

**Капитан** *(торып)*. Эһем! Сез ул турыда тыныч булыгыз! Мин анда тагы 180 казак җибәрелүе турында приказ алдым. Алар бүген килеп җитәчәк.

**Иргали.** Шулай булса, урмандагы һичбер агач төбе күләгәдә калмас. Тик Сез миңа ышаныгыз да, әмер һәм ярдәм генә бирегез.

**Мәрьям.** Син, акыллым, кадерле кунакны бернәрсә белән дә сыйларга теләмисеңмени?

**Хөсәен.** Рәхмәт, кошчыгым! Син һәрвакыт миңа шундый кимчелекләремне хәтерләтә торасың. Әй, ябалак! *(Малай керә.)* Берәр стакан кофе китерсеннәр. *(Малай китә.)*

**Мәрьям.** Син, Иргали, Бибисараның хәленә күз төшермәдеңме? Ул бүген безгә күренергә дә теләмәде.

**Иргали.** Хафа булмагыз, Мәрьям бикә! Аның өчен һәр сәгать мин хезмәт өстендә.

**Мәрьям.** Рәхмәт!

**Хөсәен.** Ул әле ял итәме?

**Иргали.** Мин кызларга аны җиләккә алып барырга куштым. Бу аның кәефе өчен беренче дәва булачак.

**Хөсәен.** Безнең бөтен тормышыбыз аның өчен үтә. Әгәр син миңа куйган хезмәтеңне Бибисарага да куйсаң, синең исемең васыятемнең беренче юлында урын алыр.

**Иргали.** Ходай озын гомер биреп, минем туфрагымны сез салсагыз иде.

**Хөсәен.** Минем бердәнбер балам да шул, нәләт төшкән Гөлбәһар хатынның кулыннан һәлак булган улым Искәндәрнең төсе дә шул...

**Мәрьям.** Ах, ничек йөрәгемне кисте ул Искәндәр! Хәзер исемен ишетсәм дә зиһеннәрем тарала...

**Иргали.** Гөлбәһар токымыннан берәрсен табып бу хәсрәтләрнең үчен кайтара алсам, мин зур бәхеткә ирешер идем, хуҗам.

**Хөсәен.** Мин егерме ел элек югалган баламның тагы да мине шатландыруын уйларга теләмим, алай да мин аның палачларыннан шундый үч алыр идем...

**Мәрьям.** Акыллым! Үзеңне бочыма! Тынычлан! *(Кофе кертәләр.)*

**Хөсәен.** Рәхим итегез!

**Капитан.** Рәхмәт!

**Малай** *(кереп)*. Крестьяннар хуҗа хәзрәтләрен күрергә телиләр. *(Китә.)*

**Хөсәен.** Иргали! Бар, кемгә нәрсә җитмәгән? Кем ул минем кадерле вакытымны бүләргә тели? *(Иргали китә.)*

**Мәрьям.** Ах, ул Искәндәр шулкадәр сөйкемле иде... аның мисле бер генә җанда – Бибисарада гына калган.

**Капитан.** Әйе! Сезнең ул хәсрәтегезне бик күп телләрдән ишетергә туры килде.

**Хөсәен.** Шулай хәсрәтле туды безнең кояшыбыз. Искәндәр белән Сара игез туганнар иде. Алар өч яшенә җиткәч, сөт аналары Гөлбәһар хатын белән аның ире бакчачы Хәсән юк булды. Шул сәгатьтән Искәндәр дә югалды.

**Капитан.** Ах, нинди фаҗига.

**Хөсәен.** Шатлыгым да, хәсрәтем дә бер генә – Бибисара гына калды. Ах... Ә ул... юлбасарлар башлыгы, кеше үтерүче, фетнәче Муса белән минем намусымны таптады...

**Капитан.** Хәйран калырга мөмкин! Мин белмим, ничек Сез башта ук ул Мусаның, каз муенын борган кебек, горласын борып ташламадыгыз.

**Хөсәен.** Без башта шикләнмәдек. Аны бит миңа Красильников бирде, хәтта бүләк итеп биргәндәй калдырды.

**Капитан.** Нинди позор!

**Хөсәен.** Соңыннан белдем, ул аны миңа үч белән биргән икән. Хәзер бит помещикларның да күбесе үзләре ата юлбасарлар. Ә хәзер менә, ах!..

**Мәрьям.** Син тынычлан, акыллым. Бәлки әле барысы да рәтләнер.

**Капитан.** Әлбәттә... Без бөтен дөньяның астын-өскә әйләндерербез... Аларны табага салып куырырбыз.

**Хөсәен.** Әй, ябалак! *(Малай керә.)* Кошчыгым! Мине үз бүлмәмә илтсеннәр! Капитан, Сез карагыз!.. *(Китәләр.)*

**Капитан.** Сез тыныч булыгыз!

***Капитан ялгыз***

**Капитан.** Черт его знает! Мошенник өстенә мошенник утыртканнар, жулик өстендә жулик үстергәннәр дә, хәзер разбирись инде менә үзләрен. Алай да бу Муса дигәннәре кухня тараканы булды бит әле минем башка... *(Башын кашый.)* Алай да китәргә кирәк. Кем белә, бәлки берәр җирдән чиертер әле... *(Чыгып барганда Иргали очрый.)*

***Иргали, капитан***

**Иргали.** Сез каядыр ашыгасыз бугай?

**Капитан.** Мин бүген пополнение көтәм. Шуларны каршы алырга кирәк.

**Иргали.** Бу мәшәкатьләрдән Сез дә бик арыгансыз инде.

**Капитан.** Беттән курыксаң, постоялый дворга кермә, диләр, безнең эш шул бит инде.

**Иргали.** Дөрес! Башланган икән, ахырына кадәр җитәргә кирәк. Җиңүгә кадәр!

**Капитан.** Правильно! Бир кулны! Без әле күрсәтербез! *(Китә.)*

***Иргали ялгыз***

**Иргали.** Бу эшләрне бүген ашыктырмасаң, иртәгә соң булуы мөмкин. *(Малай керә.)*

**Малай.** Сезне сорыйлар.

**Иргали.** Кем бар?

**Малай.** Әйтмәде, чит кеше булырга ошый.

**Иргали.** Әйт, керсен! *(Малай чыга.)* Мөгаен, ул килгәндер.

*(Ибраһим керә.)*

***Ибраһим, Иргали***

**Иргали.** Ә, Ибраһим, син?

**Ибраһим.** Әйе, мин әйтелгән вакытка җитәргә тырыштым.

**Иргали.** Сине берәү дә танымадымы?

**Ибраһим.** Кем танысын! Минем киткәнемә егерме ел тулып китте. Син үзең дә беренче күрүдә танымадың түгелме?

**Иргали.** Ярый. Бу синең өчен яхшырак. Анаң берничә көнсез кайтып җитә алмас, дисеңме?

**Ибраһим.** Әйе. Ул юлда бик арыды.

**Иргали.** Мирзаның хәзер артык борчулы һәм ачулы вакыты. Безгә бу эшләрне анаң кайтканчы сер итәргә кирәк булыр.

**Ибраһим.** Син шулай уйлыйсыңмы?

**Иргали.** Уйлыйм гына түгел, мин шуңа ышанам.

**Ибраһим.** Минемчә, безгә ашыгу файдадан башка бернәрсә дә китермәс иде.

**Иргали.** Чөнки мирзаның, Гөлбәһар токымыннан беренче очраган кешегә иң авыр җәза бирергә, дигән нык анты бар.

**Ибраһим.** Син чынлап сөйлисеңме?

**Иргали.** Хәтта ул, очраса, Гөлбәһар ыруыннан булган күкрәк балаларын бугазлаудан да тартынмас иде.

**Ираһим.** Искәндәрнең исәнлеге турында хәбәр булгач, бәлки ул бөтенләй башка төрле фикергә килер иде.

**Иргали.** Һич! Хәтта мин әле Гөлбәһар карчык үзе кайткач та, аның гомерен саклап калыр өчен миңа күп көч куярга туры килер диеп ышанам.

**Ибраһим.** Бу бит гаделлек булмас иде.

**Иргали.** Хәзергә әле гаделлек белән хакимлек бергә җыйналганнары юк. Искәндәрнең исән булуы бу эштә мирзага батырлык кына өстәр иде.

**Ибраһим.** Бу бит бик куркыныч.

**Иргали.** Әйе, хәзергә синең аягың минем өчен җиңел хезмәт китермәде.

**Ибраһим.** Алайса, миңа монда күп калырга да ярамас?

**Иргали.** Шуның өстенә, сине беркем дә күрмәс, кайтканыңны берәү дә белмәс. Югыйсә, эшең начар булыр.

**Ибраһим.** Алайса, мин китәм.

**Иргали.** Бар, ләкин Шиһап өеннән бер адым атлыйсы булма! Ә мин монда карармын.

**Ибраһим.** Зинһар өчен! Мин сиңа гына таянам. *(Артка Солтан кереп яшеренә.)*

**Иргали.** Син тыныч бул! Мин үземнең бәхетсез крестьян туганнарым өчен бөтен хезмәткә хәзер!

**Ибраһим.** Ярдәмеңнән ташлый күрмә, Иргали!

**Иргали.** Ярый, бар. Анаң кайткач, безне күрештерерсең.

**Ибраһим.** Киттем! *(Китә.)*

**Иргали.** Кара, кеше күзенә күренмә!

***Иргали ялгыз***

**Иргали.** Гөлбәһар кайтып җитәргә тиеш. Бу минем эшләрне тагы да авырайта төшә. Минем кулымда бер-ике көн вакыт кала. Шул көннәр эчендә ничек тә бу шомлы эзләрне юарга кирәк. *(Әйләнә, сискәнә.)* Әй, кем бар анда? *(Солтан чыга.)*

***Солтан, Иргали***

**Солтан.** Э... бу Сезнең бәхетсез колыгыз.

**Иргали.** Солтан... Син ничек монда керә алдың? Син ничек капкачыларны үтә алдың?

**Солтан.** Сез миңа ачуланмагыз. Миңа шулай ашыгыч кирәк булды.

**Иргали.** Син шымчылык иттең? Син безнең сүзләребезне тыңлап тордың, ә?

**Солтан.** Мин бернәрсә дә ишетмәдем.

**Иргали.** Ялганлыйсың. Син барысын да ишеттең, барысын да тыңлап тордың, шулаймы? (*Солтанның якасыннан ала.)*

**Солтан.** А! Сез нигә миңа бәйләнәсез? Мин Сезгә зур йомыш белән килдем.

**Иргали.** Беләм, фетнәчеләр яныннан.

**Солтан.** Сез мине шатланып каршыларга тиеш.

**Иргали.** Син хәзер миңа фетнәчеләрнең кайсы җирдә торганнарын әйтергә тиеш.

**Солтан.** Әлбәттә.

**Иргали.** Шулай ук Муса, Бикморзаларның хәзерге көнне кайда булуларын әйтергә тиеш.

**Солтан.** Шиксез шулай.

**Иргали.** Һәммәсен дә бәйнә-бәйнә сөйләрсең.

**Солтан.** Һәммәсен дә түкми-чәчми сөйләрмен.

**Иргали.** Утыр! Телең ялганлар булса, күзләрең шаһит булып торыр.

**Солтан.** Ләкин элек мин боларны хуҗа хәзрәтләренең үзләренә генә сөйләргә тиешмен.

**Иргали.** Ах, син әле миңа ышанырга теләмисең?

**Солтан.** Алла сакласын! Киресенчә, Сезнең миңа булган ышанычыгыз тулы түгел...

**Иргали.** Син барыбер миннән узып мирзаны күрә алмассың.

**Солтан.** Шулкадәр җир килеп Сезне күрә алганны, монда кергәч, хуҗа хәзрәтләрен ничек күрә алмам икән?

**Иргали.** Юк, син миннән узып һичбер эш күрә алмассың!

**Солтан.** Ибраһим белән булган бөтен серегез миннән яшерен булмасадамы?

**Иргали** (*ташланып)*. Ах! Син минем башымнан үткәнче мин синең үләксәңнән үтәрмен...

**Солтан.** А! Мин кычкырырмын! Бөтен дөньяны җыярмын!

**Иргали.** Мин синең бугазыңны тартып сузармын! *(Солтанны ега.)* ■

Безнең мирас №11 ноябрь 2019

# Сириннең публицистик поэмасы



*Әдәбиятка Сирин буларак кереп калган шагыйрь (тулы исеме Батыршин Сәйрин Хәниф улы, 1896-1969) – 1930 нчы елларда репрессияләнгән шәхесләрнең берсе. Татар шигъриятендә үзенә генә хас стиль белән иҗат иткән трибун шагыйрьне, 1930 нчы елларда совет җәмгыятендә җәелгән гаделсезлек, астыртынлык, икейөзлелек күренешләрен тәнкыйтьләгән өчен кулга алалар һәм биш елга сөргенгә озаталар. 1935-1940 елларда ул искиткеч каты режимлы Сиблагта җәфа чигә. Срогын тутырып кайткач (аның исән калуы үзе бер могҗиза!), 1941 елда үз теләге белән Ватан сугышына китә: Смоленск юнәлешендәге сугышларда катнаша, ике тапкыр контузияләнә. Армиядән кайткач, туган авылында колхозда эшли, иҗатын дәвам итә. 1969 елда Баулы эшчеләр бистәсендә вафат була һәм шунда җирләнә. Татарстан АССР Югары суды Президиумының 1957 елгы 13 июнь карары нигезендә реабилитацияләнә.*

Сириннең совет җәмгыятендәге гаделсезлекләрне тәнкыйтьләвенең үз сәбәпләре була. Аны Казандагы Көнчыгыш педагогия институтында укыган чагында, 1927 елда ук, бернинди сәбәпсез кулга алалар, бер ай НКВД төрмәсендә ябып тоталар. Аннан соң да Черек күл тарафыннан куркытулар, сорау алулар булып тора. Бөтен күңеле белән «Якты совет җәмгыяте төзибез», дип рухланып яшәгән шагыйрь кинәт аптырап кала: «Нинди гаебем бар соң минем?» – дип уйлана. Һәм шуңа төшенә: тышкы яктан кызыл лозунглар белән төреп-бизәп алынган совет системасының эчендә мәкер, алдашу, байлык бүлешү ята икән! Шагыйрьнең ирек сөюче, хөр, бунтарь җаны моның белән килешә алмый, Сирин җәмгыятьтәге гаделсезлеккә каршы көрәш ача: Совет җәмгыятенең чын йөзен фаш итә торган әсәрләр иҗат итә башлый.

Нәкъ менә шушы чорда – 1933 елда ул үзенең «Халыкара сугышка каршы Конгресста Сириннең сөйләгән беренче речe» дигән поэмасын иҗат итә. Бу әсәрне ул бунтарь җанының әнә шул давылланган көннәрендә – 1933 елның 16-19 ноябрьләрендә язган. Поэма моңа кадәр беркайда да басылмаган, аның тексты ОГПУ архивында гына сакланып калган. Бу – әсәрнең тулы тексты түгел, аерым бүлекләр генә булса кирәк. Шагыйрьнең поэманы тәмамлап куярга да, кат-кат эшкәртеп торырга да мөмкинлеге булмаган, ахрысы.

1930 нчы елларда Сирин халык арасында иң популяр шагыйрьләрнең берсенә әйләнә. Студент чагында ук ул Һади Такташ белән дуслаша. Алар икесе дә бунтарь җанлы, бер-берсе белән якын дус булганнар, ярыша-ярыша иҗат иткәннәр. Казанның иң зур залларында уздырыла торган әдәби кичәләрдә икесе дә яңгыратып шигырь укыганнар, яшьләрнең иң яраткан шагыйрьләренә әверелгәннәр. Мәсәлән, Ямаш

Игәнәй Сириннең тууына 100 ел тулу уңае белән язган «Эз сызып атылган йолдыз» мәкаләсендә («Аргамак» журналы, 1996 ел, №12) Сирин турында: «Заманында сәхнәләрдә Һади Такташ белән ялкынлы шигырьләрен укып йөргән шагыйрь бит ул. Татар шигъриятендә яңалык ачучы, – дип яза һәм Сириннең үз сүзләрен китерә: Сәхнәнең бер ягыннан – Такташ, икенче ягыннан мин килеп чыга идем. Укып җибәрәбез шигырьне, зал нишләргә белми, сихерләнә, илаһи шаукымга тоташ уралып, тылсымлы-серле халәтнең иң югары ноктасында бөтерелә». Рафаэль Мостафин да Сиринне «Такташның көндәше» дип атаган иде.

Мондый дуслык аларның иҗатларында да чагылыш таба. Такташ белән Сирин әсәрләре арасында байтак кына охшашлык-аваздашлык та бар. Бер үк темага яки бер үк мотивка алар икесе ике төрле әсәрләр иҗат иткәннәр. Менә аларның кайберләре: Октябрьнең унъеллыгына Такташ «Үпкәлим», ә Сирин «Урам уртасында» шигырен багышлый; кызыл кавалеристларга атап Такташ «Атлы сугышчыга», ә Сирин «Атлы шлемнар» әсәрен яза. Мондый аваздашлык хәтта Такташ вафатыннан соң да дәвам итә. Кызларның кыска күлмәк киеп йөрүләренә Такташ «Җырым сиңа булсын» (1927), ә Сирин «Бала итәкле озын күлмәкләр» (1933) шигырен, кар бөртекләреннән этәрелеп китеп, Такташ «Ак чәчәкләр» (1929), ә Сирин «Кышкы чәчәкләр» (1933), халыкара күләмдә тыныч тормыш турында Такташ «Лорд Чемберленга СССР крестьяны Һади Такташтан җавап нотасы» шигырен (1927), ә Сирин шушы «Халыкара сугышка каршы Конгрессста Сириннең сөйләгән беренче речь» (1933) поэмасын иҗат итә.

Поэманың идея-эстетик кыйммәтен ачыклар өчен, беренче чиратта әлеге әсәр иҗат ителгән вакыттагы иҗтимагый вазгыятькә һәм авторның шул чактагы рухи халәтенә игътибар итәргә кирәк. Поэманың төп мотивларының берсе – дәүләт белән шул дәүләттә яшәгән гади бер кешенең үзара мөнәсәбәте. Бу мәсьәләне шагыйрь илләр-дәүләтләр арасында тынычлыкны сакларга кирәклек турындагы фикерләргә бәйләп бәян итә. Авторның совет җәмгыятендәге гаделсезлек, аерым бер кешенең хокуксызлыгы турында уйланулары кәгазьгә күчә.

Әсәрдә сугышның (әсәрдә Беренче Бөтендөнья сугышы күздә тотыла) гади кешеләрне имгәтүе, яшәргә сәләтсез итеп калдыруы сурәтләнә. Аның бер абыйсы сугышта аягын югалтып, ә Җәмил абыйсы кулын өздереп кайта. Шагыйрь урынлы сорау куя: нигә сугышалар, нигә кешеләрне гомер буе җәфалануларга дучар итәләр?

Тагын бер мотивка игътибар итик: поэмада ачлык-ялангачлык проблемасы да күтәрелә. 1921 нче еллардагы ачлык Сириннең үзегенә үткән була. Бала чагында ук ачлыктан аның бер абыйсы һәм бер энесе бакыйлыкка күчә, соңрак әнисе дә җан тәслим кыла. Истәлекләрендә Сирин болай дип яза: «Алабуталар чабып никадәр тырышсам да, әнине үлемнән коткарып булмады. Ачлык белән чирләп анам үлде минем!.. Миңа дөньяның кызыгы калмады. Инде нишләргә?.. Үзем дә үпкә шеше һәм тиф белән чирләдем дә, кыш буе чирләгәннән соң, бераз аякка баскач: «Бәлки, Казанда үлми калырмын», – дип, Казанга киттем. Анда да ачлык, икмәкнең килосы бер миллион сум икән. Мине Кабан күле буендагы зур йортка урнаштырдылар...»

Сирин әлеге поэмасында да «гади халыкның ач-ялангач булуының сәбәбе – дәүләтләрнең үз кешеләре турында кайгыртмавында», дигән фикер әйтә.

Әсәрнең ахырында Сирин җәмгыятьтәге ясалмалылык, икейөзлелек кебек күренешләргә каршы чыга, табигый хис белән яшәүчеләрне яклый.

Игътибар итик: поэмада күтәрелгән кайбер фикерләр бүгенге тормышыбызга да аваздаш.

***Әнвәр Шәрипов,***

*филология фәннәре докторы, профессор* ■

## ХАЛЫКАРА СУГЫШКА КАРШЫ КОНГРЕССТА СИРИННЕҢ СӨЙЛӘГӘН БЕРЕНЧЕ РЕЧЕ

***(Поэмадан өзекләр)***[1]

..................................

### Сирин

**Беренче бүлек**

Мин сезне күп тыңлап йөрдем,
Күп мәртәбә уйлап карадым.
Күп мәртәбә мин үземне
Речь сөйләүдә хаклы санадым. <...>
Сез миңа сүз бирмисезме?
Бирмисез, ни булса да.
Мин сездән сүз сорап тормыйм,
Гафу итегез мине, господа!
Кигән кием начар, сөйләр телем
Тупас булса да, мин оялмыйм.
Бүген мине шушы трибунада
Сүз сөйләүдән беркем тыялмый.
Сез сөйлисез дә сөйлисез,
Кемгә кирәк сезнең сүзегез?!
Әгәр сезне кеше дип әйтелсә,
Кешелеккә бераз якын икегез.
Менә бере – Франция,
Германия – аның иптәше.
Суларында пароходлар йөзә,
Ул сулар бит – илнең күз яше.
Ә Сәйринең һаман ач-ялангач,
Яланаяк йөри урамда.
Бер бүрек тә алып кия алмаган,
Катып-туңып йөри буранда.
Әнә, анда бик күп каберләр бар,
Кем аларны болай үтергән? <...>
Алар үлгәннәр дә... үлмәгәннәр,
Каберләрдән торып чыгарлар;
Чыгарлар да, сезнең үзегезне
Шунда китереп бер көн тыгарлар.
Кайгың да бар синең, шатлыгың да,
Уйларың да бар бит, таш кала!
Бик күп уйлар синдә чылбырланган,
Бик күп хисләр синдә таптала. <...>

**Икенче бүлек**

Коралсызлану – сез кулсызлану дигән сүз,
Әгәр төп мәгънәдә аңласак.
Коралсызлану – без кулсызлану дигән сүз,
Әгәр яңа мәгънәдә куллансак.
Коралсызлану – коралланy дигән сүз,
Хикмәтләрен аңлап җиткерсәк.
Коралланy – аяксызлану дигән сүз,
Кем аяксыз булуын төшенсәк.
Ничек аңлыйк инде без бу сүзне,
Кемгә кайсы файда – шунысын
Белик инде бу конференциядә,
Сез аңлыйсыз моның соңгысын.
Ярый, әйдә, коралланыгыз, –
Бар байлыклар шуңа түгелсә;
Безнең эшләп, безнең тапканнарыбыз
Тагын безгә каршы куелса...
Тагын бик күп машиналар эшләнсен,
Тагын бик күп газлар ясалсын, –
Җир өстендә бик күп каннар аксын,
Шуның белән дәүләт мактансын...
Кемгә бирерсез ул коралларны?
Кемгә кирәк сезнең сугышыгыз?
Эшчеләрнең анда ни катнашы бар?
Бик кирәксә, үзегез сугышыгыз!
Кемнәр бүген сугышка сусаган,
Шул кешеләр корал алсыннар!
Шул кешеләр канлы фронтларда
Бер-берсенә каршы барсыннар!
Һичбер эшченең һичбер вакытта,
Күп алса да җәзасын,
Үзенең яшәү правосын
Дәүләткә һич биргәне юк;
Һичбер эшченең һичбер вакытта
Сезгә дус йөргәне юк!
Һичбер дәүләтнең һичбер вакытта,
Сугыш кирәк дип китерергә,
Һичбер дәүләтнең һичбер вакытта
Бер эшчене үтерергә,
Һичбер эшченең һичбер вакытта
Сиңа биргән хакы юк.
Һичбер эшченең һичбер вакытта
Сиңа бирәсе анты юк!

**Өченче бүлек**

Шунда берәү залдан кул күтәреп,
Аягүрә торып басты да,

[1] Кыскартып бирелә. – ***Редакция.***

Тирә-якка карап, күзлеген ак
Яулык белән сөртеп алды да:
– Шагыйрьгә, – ди, – ник сүз бирдегез?
Шагыйрьләрнең сүзе бу түгел.
Туктатыгыз, хәзер туктатыгыз,
Аның сүзе безгә кул түгел.
Каян килгән, паспортын карагыз,
Дөнья бозып монда йөрмәсен!
Юкса, без конференцияне
Ташлап чыгабыз, бездән көтмәсен!
– Ә, шулаймы? Сүз бирмисезмени?
Сезнең өчен авыр булса да,
Йөз миллионнар миңа рөхсәт бирә,
Гафу итегез мине, господа!
Мин сездән сүз сорап тормыйм, –
Миллионнарны утка якмагыз!..
Бу нәрсә бу?..
Конференцияме?..
Зинһар, тизрәк тынлык саклагыз!

### Дүртенче бүлек

Киң табигать яшәү хакы биргән, –
Шуңар килә безнең яшисе,
Шуңар килә безнең дә киясе,
Шуңар килә безнең ашыйсы.
Кошлар кебек яшисе килә дә,
Хиссез дәүләт сине һәр көнне,
Яшәү шартларыннан файдаланып,
Кол итәргә мөмкин һәркемне.
Бер-бер кеше «гаепле» табылса,
Күренеп тора аның чарасы, –
Аның яшәвенә зарар итү, –
Шул инде аның хәзер җәзасы.
Әгәр дә мин җаным теләгәнчә
Дәүләтләргә каршы сүзләшсәм,
Дәүләтләрнең төрле ялганнарын
Халыкларга ачып күрсәтсәм, –
Сез бит шунда, сакчы этләр кебек,
Тирә-яктан өрә бшлыйсыз.
Үзегез дә ул үлемнән куркып,
Үлем белән мине таптыйсыз.
Ярый, алайса, бик кызык бер
Уй өелде әле минем башыма:
Әгәр дә бер үлгән кеше
Кайтып басса дәүләт каршына;
Кайда җыелыш, кайда эшчеләр бар,
Төртеп-ертып шунда кердисә,
Хөкүмәтнең төрле ялганнарын
Бер-бер артлы сөйләп йөрдисә;
Һәрбер хаклык өчен, аяк терәп,
Үз каршында егылып талашса,
«Безне үтереп көн күрәләр бит», – дип,
Халыкларга сөйләп аңлатса, –
Их, бичара дәүләт, нишләр идең?
Нишләр идең син бу кешегә?
Тик ул гына дөреслекне сөйләр,
Башын имәс ул һичберкемгә.
Шулай инде, мин дә шулай эшлим,
Шуңар миңа синең юк җәзаң.
Шуңар гына мин бу дөреслекне
Монда килеп сөйли алам.

### Бишенче бүлек

<...> Кеше өчен дәүләтләр яшиме?
Дәүләт өчен мәллә кешеләр?
Кеше өчен дәүләтләр яшәсә,
Нигә болай безнең бу эшләр?
Алып китеп таза абыемны,
Кайтардыгыз өйгә аяксыз.
Ничек тормыш итәр инде ул?
Йөри алмый бит ул таяксыз.
Алты-җиде баласы бар иде,
Барысы эчтән авыр сулады;
Барысы бергә кочаклашып,
Күз-яшь белән үксеп елады.
Яшь балалар килеп карыйлар да,
Тоталар да аның таягын,
Бөтен дәүләтләргә кычкыралар:
«Бирегез, – дип, – әти аягын!»
Кеше өчен дәүләтләр яшиме?
Дәүләт өчен мәллә кешеләр?
Кеше өчен дәүләтләр яшәсә,
Нигә болай безнең бу эшләр?!
Бервакытны Җәмил абый[2] кайтты,
Караганда болай берни юк.
Бервакытны күрсәм, исем китте, –
Җиң эчендә аның кулы юк.
Безгә белдермәскә теләгәндер,
Безнең күздән яшьләр тамдылар...
Шул вакытта минем йөрәгемдә
Мәңге бетмәс утлар яндылар.
Аның кулы һаман төзәлмәде,
Күлмәкләре канга буялды.
Гомер буе, мескен, җәфаланды,
Шулай үтердегез, югалды...
Дәүләт өчен кешеләр яшиме?
Кеше өчен мәллә дәүләтләр?

[2] Җәмил – Сириннең бертуган абыйсы. – ***Ә.Ш.***

Кеше өчен дәүләтләр яшәсә,
Нигә бетми кайгы, хәсрәтләр?!

**Алтынчы бүлек**

Барлык дәүләтләр!
Тыңлагыз, тыңла!..
Серләр яшерен калмасын!
Дәүләтләрнең закон-афераларын
Түбән халык яхшы аңласын!..
Әгәр дә мин,
Шундый бер яңалык табып,
Комлыкларны шикәр ясасам,
Һәм зур күлне майга әйләндереп,
Җиңел туенуга юл ачсам, –
Бөтен халык шуннан файдаланып,
Ашый бирсә, алар бетмәсә,
Кулындагы шикәр-майларыңа
Беркемнең дә исе китмәсә,
Нишләр идең, дәүләт?!
Нишләр идең?
Мине, бәлки, тотып суярсың!..
Ә тегендә беркем бармасын, дип,
Адым саен сакчы куярсың.
Ник саклыйсыз инде ул азыкны?
Кем алса да, барыбер бетми бит!
Синең ашавыңнан файдаланып,
Дәүләт сине шулай этли бит!

**Җиденче бүлек**

Кич. Шулай сезнең шәһәрдә
Урамнарны карап йөргәндә[3],
Таш урамга килеп кергәндә,
Зур магазин алдында
Бер сакчы күреп, хәйран калдым;
Ник, бер сакчы куелган, дип,
Тирән-тирән уйга калдым.
Ник, дияргсез?
Бик гаҗәп бит:
Ишеккә зур йозак салынган.
Шул яхшы саклый бит инде,
Нигә тагын сакчы куелган?
Бу йозак – хиссез йозак бу,
Хисле булса, үзе үк ачып,
Ярлыларга бирер иде,
Барлык малын таратып.
Их, йозак! Тимер йозак!
Хиссез йозак, юк бит җаны.
Ник товарны тараттың, дип,
Үтереп тә булмый аны.
Хиссез йозак, сакла, сакла,
Ләкин ышаныч юк сиңа,
Сине ватулары мөмкин, –
Сакчы кирәк тимер сакчыга!
Шуңар, әнә, синең өстеңнән
Тагын җанлы сакчы куелган.
Син ул сакчыны саклыйсың,
Ә ул саклый сине башкадан...

**Сигезенче бүлек**

Сездә бик күп форма-киемнәр бар,
Шул киемнәр булды бик гаҗәп:
Кайберсе вак тимер такканнар,
Ник такканнар моны, ни сәбәп?
Әллә «мин – зур!» дигән сүзме?
Тимергә ник зурлык тагылган?
Әллә кеше зур булган өченме?
Ничек уйлыйк, кайсы ягыннан?
Зур булган өчен тимер тагылса,
Ник тагалар бик вак кешеләр?
Ник соң тимер таккан кешегә
Нәфрәт белән карый эшчеләр? <...>
Бу форма – бу «мин – кан эчүче» дигән сүз.
Шул ис килә, шулай аңлыйм мин.
Шуңар андый формаларга
Зур нәфрәт белән карыйм мин.
Алар әллә җанлы мәетләрме?
Шулай сизәләрме? Ничек диярга?
Аларның кайбер эшләрен күреп,
Килеп каласың шундый фикергә:
Алармыни шундый кешеләр, –
Мәрхәмәтсез, –
Башкаларны тотып көчлиләр?
Табигый хис – организм үлгән,
Нерв белән дә эш итмиләр,
Димәк, алар үлек кешеләр. <...>
Крестьяннар да, эшчеләр дә
Табигый хис белән эш итәләр.
Табигый хис белән яшиләр, –
Шатлана да, кайгыра беләләр.
Бу – аларның иң матур сыйфаты.
Шуңар аларны бик дус күрәм мин,
Шуңар аларны өзелеп яратам,
Шуңар аларны өзелеп сөям мин...[4] ■

---

[3] Бу юл шулай гына язылган. – ***Ә.Ш.***

[4] Текст шунда өзелә. Димәк, поэма тәмамланмый калган. – ***Ә.Ш.***

**«ТАТМЕДИА» республика матбугат**
**һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы**
**Татарстан китап нәшрияты,**
**«Безнең мирас» журналы редакциясе**

## ТАССРНЫҢ ҺӘМ ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫНЫҢ 100 ЕЛЛЫКЛАРЫНА БАГЫШЛАП, «ХӘТЕРГӘ УЕЛГАН КИТАП» ИСЕМЛЕ КОНКУРС ИГЪЛАН ИТӘ

**КОНКУРСНЫҢ МАКСАТЫ** – татар китап мирасын пропагандалау, республикабызда телләрне саклау һәм үстерү, яңа авторларны табу, алар белән хезмәттәшлек итү.

**Конкурс 2019 елның 1 апреленнән 2019 елның 15 декабренә кадәр** үткәрелә.

**Конкурска** үзегез бик тә яратып укыган, тормышыгызда мөһим роль уйнаган, хәтергә уелып калган яки сез «өстәл китабы» буларак файдалана торган китап турында татар телендә язылган очерк, эссе, мәкалә кабул ителә. Күләме А4 форматында 12 нче кегельдә 2 биттән дә артмаска тиеш.

**Конкурста** катнашучылар үзләренең эшләрен «Безнең мирас» журналына 2019 елның 2 нче ярты еллыгына яки 2020 елның 1 нче ярты еллыгына язылу турындагы квитанция фотосын (скан вариантын) беркетеп, yanamiras@mail.ru электрон почтасы адресына «КОНКУРСКА» дигән сүз белән җибәрергә тиеш.

**Конкурска** юлланган эшләр Татарстан китап нәшриятының генераль директоры һәм «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире раслаган жюри әгъзалары тарафыннан бәяләнеп, җиңүчеләр 2019 елның 1 декабрендә игълан ителә.

Җиңүчеләргә акчалата премияләр, Татарстан китап нәшриятыннан китап алу өчен сертификатлар, «Безнең мирас» журналы редакциясеннән конкурста призлы урын алучыларга сертификат һәм барлык катнашучыларга дипломнар биреләчәк.

Барлык материаллар да «Безнең мирас» журналында яки http://beznenmiras.ru/ сайтында басылачак.

Конкурс турындагы мәгълүмат **http://beznenmiras.ru/** сайтына урнаштырыла.

Безнең мирас №11 ноябрь 2019

# ГОМӘР БӘШИРОВ *көндәлегеннән*[1]

## ФАТЫЙМА ИЛЬСКАЯ (1902-1984)

Сулдан уңга: Фатыйма Ильская, Әхмәт Ерикәй, Фәтхи Бурнаш, Муса Җәлил. 1928 ел

Бүген кайгылы көн – Фатыйма ханым Ильскаяны соңгы юлына озату көне.

Фатыйма ханым байтактан бирле авыру иде. Аның аяклары авырта, ул бик кыенлык белән йөри башлаган иде инде. Әмма ул, гомеренең соңгы көннәренә дип үк әйтмим, соңгы айларына кадәр үзен халыкның дәрәҗәле кешесе, ихтирамга лаеклы күренекле артист итеп тотты. Фатыйма ханым халыкның аны яратуын һәрдаим сизеп, үзен чиксез ихтирам итүен күреп тора, үзе дә халык арасында үзен тотуы, хәтта тышкы кыяфәте, йөреш-торышы белән дә һәрьяктан шул ихтирамга лаек булырга тырыша иде. Шундый бер хәл истә калган. Кемнеңдер юбилей кичәсендә, президиумда бергә булганнан соң, без Фатыйма Ильская белән кайтырга чыктык. Ул, гәүдәсен төз тотып, горур кыяфәттә атлап бара, каршы килеп аны сәламләп узучыларга бик килешле генә, ихтирам белән, баш ия иде. Мин аның, аяклары авыру булуга карамастан, шундый артистлар йөреш-торыш затлылыгын саклый алуына, шул яшьтә дә матур, ягымлы, нәзакәтле булуына сокланып бардым.

– Сезгә күз тия күрмәсен, узган-барган Сезгә сокланып карап уза, – дидем.

Фатыйма ханым, матур тешләрен күрсәтеп, гадәтенчә яшь-яшь тавыш белән бик матур итеп көлде. Мин тагын аңа хәйран калдым.

Әмма шуннан соң күргәнем мине таң калдырды, хәтта кызгану хисе уятты. Фатыйма ханымның квартирасы Академия театрыннан бер генә йорт аша (ул йортта радиокомитет урнашкан) иде. Фатыйма, миннән аерылып, ишегалдына кереп китте, мин үз

Дәвамы. Башы журналның 8 нче (2019) санында.

[1] Бәширов Г.Б. Күңел дәфтәре: көндәлек язмалар [төзүчесе, кульязмаларны һәм искәрмәләрне әзерләүчесе Зөфәр Бәширов]. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2011. – 464 б.

«Ике хуҗаның хезмәтчесе» спектакленнән бер күренеш. Рольләрдә – Галимә Ибраһимова һәм Фатыйма Ильская. 1950 нче еллар

юлыма юнәлдем. Берничә адым атлагач, тимер челтәр (койма) арасыннан ишегалдына күз салсам, шаккаттым. Баягы матур буй-сынлы артистка урынына ишеккә таба аякларын көч-хәл белән сөйрәп атлаучы, бераз бөкресе дә чыккан хәлсез карчык бара иде. Шулкадәр дә үзгәрә алыр икән кеше! Аның сокландыргыч талантлы артист булуы әнә шунда да күренеп калды. <...>

Менә бүген аның – гомере буена эшләгән, үзенең зур таланты белән Академия театрын озак еллар буе нурландырып торган бу бинада соңгы мәртәбә булуы, аны чын күңелдән ихтирам иткән, аның сокландыргыч таланты алдында баш игән меңнәрчә тамашачылар белән соңгы мәртәбә бәхилләшүе. Ул театр фойесында чәчәкләргә күмелеп ята. Аны бик күп оешмалар куйган веноклар әйләндереп алган. Аның баш очында митинг бара. Язучылар союзыннан Туфан Миңнуллин сөйләде.

– Театр зур таланттан мәхрүм калды, – диде ул. – Театр зур белем сорый, театр сәхнәсенә югары театраль белем белән менәләр. Әмма Фатыйма апа бу яктан да ифрат үзенчәлекле шәхес иде. Ул югары белемле Габдулла Кариев һ.б. янына укый-яза белмәгән килеш килеп керде. Формаль яктан белеме булмауга карамастан, ул дөнья классикларының катлаулы рольләрен башкарды. Чөнки ул сокландыргыч талант һәм табигый акыл иясе иде. Фатыйма апа кабатланмый торган талант, сәхнә йолдызларының иң яктысы иде.

Театрның баш режиссеры Марсель Сәлимҗанов сөйләде:

– Фатыйма ханым безнең театрның тарихы иде. Театрның тарихын ул үзенең искиткеч таланты, уеннары белән иҗат итте, җитмеш ел буена гомеренең һәр сәгате, һәр минуты театрга багышланган булды. Әле күптән түгел, гомеренең иң соңгы көннәрендә дә ул театр хәле белән танышып торды.

Композиторлар союзыннан Бату Мулюков, Зур театрдан Ингвар һ.б. сөйләделәр. Театр бинасының фойесында оркестр матәм көйләре уйнап торды.

Халык бик күп җыелган иде. Аны зиратка кадәр озата баручылар да биш-алты автобуска сыймады.

Фатыйма ханымның мәетен татар зиратына күмделәр. <...>

Бик аяныч хәл. Соңгы могикан да китте, зур талант ияләренең соңгы йолдызы да сүнде.

*1984, 17 ноябрь* ■

ДРАМАТУРГ ШӘРИФ ХӨСӘЕНОВНЫҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

# Дин кушканча яшәде

Нәкыя Гыйләҗева

**Шәриф Хөсәенов (уңда) һәм Аяз Гыйләҗев. 1979 сентябрь.** Мидхәт Шакирҗанов фотосы

*Шәриф Хөсәенов атлы илаһи татар җанлы күренекле табиб, гаҗәеп тирән мәгънәгә ия булган әдәби әсәрләр авторы, киң колачлы фикер иясе булган дустыбызның тууына шушы елның ноябрь аенда 90 ел тулу уңае белән аның хакындагы җылы фикерләремнең исемә төшерә алган кадәресен барлап, кәгазь битенә төшерим, дип компьютер артына утыруым. Бер Аллам ярдәменнән ташламасын! Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи раббил гааләмиин. Ярабби, урының җәннәттә булсын, Шәриф дустыбыз! Амин!*

Шәриф Аязымның тормышындагы иң якын гомерлек дусларыннан берсе булды. Алар арасындагы дуслык мөнәсәбәтләре гаҗәеп тә җылы һәм эчкерсез иде. «Еракка китеп кара!» дигән гыйбарә бар. Чыннан да, араларыбыз ерагайган саен, безнең арадагы мөнәсәбәтләрнең чын-чын дустанә булганлыгына, җаным-тәнем белән сагынып, инана барам. (Шушы юлларны язганда күземнән яшьләр сыгылып чыкты, күңелемнең дә әлеге хисне раславыдыр инде бу, дип уйладым. Һичшиксез шулай.)

Минем үзем өчен Шәриф Хөсәенов белән танышу «Профессор кияве» пьесасы беренче куелган спектакльнең Г.Камал театрында уйнала башлавыннан булгандыр. (29.12.1953.) Унынчы класста укып йөргән чагым, «медицина институтында укучы студент шундый шәп комедия язган», имеш. Бу безнең ише авыл кабартмалары колагы-

на да сокландыру уятырлык булып килеп кергәндер инде, шулай булмаса, гомерлеккә күңелемә сеңеп калмаган булыр иде. Сарман урта мәктәбен тәмамлаучылар шул елларда ябырылып медицина институтына бара башладылар. Мин үзем дә шулар сафындагы бер бәндә булдым... Алланың рәхмәте, миңа анда кереп уку насыйп булмады! Ни өчен шулай, дип әйтәм, әгәр мин анда кергән булсам, Аяз белән кавышмый һәм Шәриф белән якын дустанәдә яшәп алу бәхетенә дә ирешми идем. Язмыш, шулай итеп, һәрнәрсәне үз урынына урнаштырган!

Аязым ул елларда (1950-55) тоткынлыкта иде. Тоткынлыкка эләккәнче, ул Шәриф белән таныш булмаган. Тоткынлыкка кадәр Аяз театр техникумы укучылары белән нык аралашкан. Мәсәлән, Вәкил Закиров Аязның якын дусты иде. Ул шул елларда анда укыган һәм театр техникумында укуын 1951 елда тәмамлаган. Ә 1953 елда Г.Камал театрында куелган «Профессор кияве»ндәге төп герое – Рөстәм образын уңышлы башкарган. Аяз тоткынлыктан кайткач, Вәкил белән нык аралашты, без гаилә дуслары идек. Вәкил Закиров (06.05.1928-12.10.1969) нәкъ күтәрелеше чорында мәңгелеккә китеп тә барды. Урыны җәннәттә булсын! Амин!

Бу урында шуны әйтәсем килә: Аяз белән Шәриф арасын тоташтыручы ролен Вәкил башкаргандыр. Шәриф үзенең пьесаларында уйнаган шәхесләрне ихлас хөрмәт итте, яратты, шулай итеп ул Вәкил белән чын дус та булып киткән. Һәм Вәкил төрмәдән кайткан сердәше Аяз белән Шәрифне дә таныштырган. Аяз, тоткынлыктан кайту белән, театрларга йөри башлаган һәм дусты Вәкил чакыруы буенча «Профессор кияве»нә барган, менә шунда Аяз Шәриф белән танышкан. Алар шулай якынаеп киткәннәр...

Аяз юкка гына театр техникумы студентлары белән аралашмаган ич инде, аның күңелендә сәхнә әсәре тудыру хыялы кымырҗыган. Җитмәсә, Аяз кулга алынасы елда (1949), Мәскәүдә ГИТИСның татар студиясен тәмамлаган кыз Рауза Габдулловна Уральская Казанга кайтып төшә. Рауза Уральская Әстерханда туып, шунда яшәп үскән затлы кыз булган (1924-14.10.1957). Аязның андый кызларга күзе төшсә дә, якынаеп китәргә базмагандыр инде, ләкин ул аны зур талант иясе итеп искә төшерә иде. Аяз 1950 елда кулга алына, ә тормыш дәвам итә. Шәрифнең студент еллары. Шәриф – җете күзле, зиһенле, акыллы-фәлсәфи фикер йөртә белә торган шәхес табиблыкка әзерләнүе белән янәшә иҗат эшенә дә керешә. Нәтиҗәдә, ул беренче әсәрен тамашачыга тапшыра. Андагы төп геройлар: Гөлсинә ролендә – Рауза Уральская, Рөстәм ролендә – Вәкил Закиров. Аязым тоткынлыктан кайткач караган «Профессор кияве»ндә Раузаны янәдән «очрата».

Бу урында Рауза Уральскаяны телгә алгач, аның турындагы фикерләремне дә теркәп китим әле. Шәриф – Рауза Уральскаяга гомере буена мәхәббәт саклаган шәхес. Рауза, әйтүләренә караганда, гаҗәеп мөлаем-сөйкемле, музыкаль, чибәр бер илаһи зат булган. Бу хакта аны күреп белгән кешеләр миңа да җиткерә килделәр. Шәриф аңа багышлап «Мәхәббәт сагышы» повестен иҗат иткән. (Ни кызганыч, 33 яшендә мәңгелегенә китеп тә барган!) Аязым да аны күреп белгән бит инде. Ул да яшьлегендә Раузаның исеменә булса да гашыйк иде. Аяз миңа: «Син кыз бәби алып кайтсаң, без аңа Рауза исеме куярбыз, яме», – ди торган иде. Шушы затлы мәрхүмнәребез рухына риясыз дога кылырга гына кала инде безгә. Урыннары һәрбарчасының җәннәттә булсын! Амин!

Язып үткәнчә, Аяз, тоткынлыктан кайткач, пьесалар язу белән мавыкты. Көннәрдән беркөнне драматурглар секциясендә аның «Хәдичәнең кече улы» исемле пьесасын укыйлар. Аяз үзе бу хакта: *«Булды ошатучылар, ләкин күпчелек мине аямады, тетеп салды. Ә Шәрифнең чыгышыннан бер фикер гомергә истә калды. «Аязда Чехов драматургиясенең тәэсир көче нык сизелә», – диде ул, мине чәйнәп ташлаган кайберәүләрнең авызын ямап. Чыннан да, Чехов пьесаларына мөкиббән киткән кеше буларак, Шәрифнең сизгерлегенә*

*чиксез сөендем... Тәүге проза әсәрләремне дә кульязмада укып барды Шәриф. Шуларга нисбәтле рәвештә, дөнья хәлләрен, илдә булып торган үзгәрешләрне үзебезчә бәяләп, ачыктан-ачык сөйләшә, хаклык дигән югарылыкка менеп җитәргә тырыша идек. Без танышып якынайган еллар эчендә Рәсәй кырыкка төрләнде, власть көчләре адәм балаларын әле бер якка, әле тегә, әле бу якка баш орып яшәргә мәҗбүр итте. Кара йөзле Иблисләр, җаен табып, Фәрештә кыяфәтенә керделәр, каргалар сандугач булып сайраштылар, дөнья туктаусыз буталды. Шәриф Хөсәенов исә берчакта да үзгәрмәде, властька омтылмады..., вак-төяк әсәрләр язып, татарның беркатлы өлешен аңгырайтмады»,* – дип яза[1].

Шәриф Хөсәенов гаҗәеп итагатьле, ярдәмчел кеше иде. Бу сүзләрне аның шәхесен бизәп күрсәтү өчен генә язуым түгел, үзе сөйләгәннәрдән дә чамалап әйтүем. Табиб буларак эшләгән чорында аңа пациентларның төрлесе очраган: бае булган, хәллерәге, бик ярлыларына да тап булган. Чарасызлыкта калган авыруларын күреп, елап җибәргән чакларын да хәтерлим. Аны түбәнсетмичә ничек итеп ярдәм итәргә икән, дип борсаланганын, өзгәләнгәнен беләм. Җаен табып, мохтаҗ авыруларга акчалатамы, азык-төлек беләнме – гел ярдәм итеп тора иде...

Инде килеп, мәчетләргә, дингә җылы мөнәсәбәт туа башлагач, Шәрифнең күңеле сөенгәнен күреп, тоеп, Аяз белән мин аның шәфкать иясе булуына соклана идек. Мисалын да әйтим әле. Ул безне бик еш кына, каз кыздырып, кунакка чакыра торган иде. (Бу һөнәрне ул миннән үзләштерде.) Шул чакыруларының берсендә Шәриф безгә «бер чудо» күрсәтергә булган. «Аяз, «чудо» күрсәтәм, килмәсәгез, үпкәлим», – дип, алдан чакыру булды. Безгә инде шул гына кирәк, тормышны төрләндереп торуны бер дә читкә куймый идек. Бардык. Дөрестән дә «чудо» – искитмәле затлы бәллүр шәмдәл (люстра) икән. Күрдек тә, аптырашып, Аяз белән бер-беребезгә карашабыз: «Менә тиле Шәриф, бәләкәй генә, түшәме Шәрифне басам дип торган фатирга шундый люстра алган». Үзе елмая, үзе исә безгә сынап карый. «Ник аптыраштыгыз? Ник сокланмыйсыз?» Аптырамаган кая инде... «Аяз, аптырама, дустым, мин аны туган авылым мәчетенә бүләккә алдым!» – ди бу. Һәм шушы люстраны мәчеткә илтеп тапшыру хәстәрен күрү турында уйлана башлады. Күрсәткән танышлары, дус-ишләре аңа: «Бу люстраның чукларын авылдашларың берәм-берәм хатын-кызга алка ясарга чүпләп бетерәчәкләр», – дип, күңелен борчырлык сүз әйткәннәр. Шәриф шунда аптырап калган иде. Үзе дә, шундый хәл булырмы, диебрәк, туктап торды... Васыятен үтәп, соңыннан ул люстраны, Шәрифнең вафатыннан соң, мәчеткә Наза кайтарып элде.

Наза, дигәннән, ул Шәрифнең ак бәхете булып тарихта калырлык шәхес: гаҗәп үзенчәлекле, ихлас-саф, эшлекле, ярдәмчел, дөнья агышы юнәлешен бөтен тирәнлеге белән чамалап ала белә торган затлы хатын. Искәртеп үтим: Наза – Шәрифнең иң өлкән бертуган апасының кызы. Ул Мәскәүдә үскән. Шәрифнең апасы сугыш алды елларында, бәхет эзләп, Мәскәүгә киткән булган. Шулай итеп, анда төпләнеп, бәхетен таба алмаса да, гомер кичергән. Наза яшьтән үк тормышның ачысын-төчесен татып үсә һәм гомер буе әнисе туып үскән төбәккә тартылып яши. Казанда гомер итүче Шәриф абыйсы аның күңелен җылыта. Ул шулай Казан белән элемтәдә булып, мәхәббәтен дә Казанда таба. Язмыш аны гомерлек юлдашы, мәхәббәте, үзе кебек үк эшчән, хезмәттән тәм табып, киләчәккә җылы өметләр баглап яши торган Әсхәт Сафин белән кавыштыра. Булса да булыр икән тәңгәл килгән юлдашлык, мәхәббәт, бер-береңне ярты сүздән аңлау үрнәге. Бу гаилә, дәвамчылары итеп, бер кыз, бер малай үстерде. Балалары да нәкъ

[1] Аязның 1999 елның сентябрь аенда язган мәкаләсе. (Әдәби-нәфис басма «Шәриф Хөсәенов». Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2006. – 283-284 бит).

**Театрның яңа бинасы ачылу тантанасында. Аяз Гыйләҗев (сулда), Шәриф Хөсәенов һәм Туфан Миңнуллин. 1987 ел.** В.Зотов фотосы

аларча яшәргә тырыша торган эшлекле, кешелекле затлар булып, үз балаларын да Наза белән Әсхәткә хас сыйфатлар үрнәгендә тәрбияләп, оныклар үстерәләр. Наза белән Әсхәт Шәрифне, мөселманча – шәригать кануннары кушканча җиренә җиткерергә тырышып, зур ихтирам белән мәңгелегенә озаттылар. Татар зиратын зиярәт кылган кешеләр, Шәрифнең каберенә күз салып, сүземнең хак икәнлегенә ышанырлар. Аның кабере өстендә, кар астыннан зиратта беренчеләрдән булып, тюльпаннар ашыга-ашыга чәчәк ата. Аязымның кабере дә аның белән янәшәдә генә, мин дә аларча – ирем кабере өстендәге чәчәкләрне иртәрәк күрергә телим, ләкин, ни кызганыч, алай ук булдыра алмыйм! Кояш иртә яздан Шәриф каберен ныграк җылыта сыман! Чөнки аны Назалар чын күңелдән яратып, Шәриф теләгәнчә догада һәм назда тоталар. (Монда үземнең дә Аязымны гел догада тотарга тырышуымны әйтәсем килә.)

Шәриф үзенең вафатына әзерлекле китте. Ул үз кулы белән шушы шигырьне язып, Назага тоттырган. Һәм ул шигырь Шәрифнең кабер ташына язылып та куелган:

*«Мин үлгәч, каберем өстендә*
*Сиреньнәр чәчәк атсын.*
*Узган-барган юлыксын да*
*Кайгыларын онытсын».*

Сиреньнәр, ул кушканча утыртылып, аның амәнәтен үтәгән Назаларга рәхмәт укып, Шәрифкә мәңгелек йокысында тынычлык теләп үсәләр. Ә инде Шәрифне – дөньялыкта әдәбиятта, табиблык өлкәсендә, дисеңме – гел якты эз калдырган затны милләттәшләребез, кабере янына тукталып, дога белән искә алырлар дип өметләнәм.

Әйтергә теләгән җылы сүзләрем Шәрифнең рухына дога булып ирешсен! Амин! ■

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕНЕҢ ОЕШУЫНА 85 ЕЛ

Рәсемдә (уңнан сулга): М.Җәлилнең кызы Чулпан, хатыны Әминә Җәлилова, Андре Тиммерманс һәм аның хатыны. «Казан» кунакханәсе: 15 февраль, 1966 ел. М.Шакирҗанов фотосы

# Сурәтле хатирә

Әгъзам Фәйзрахманов

## ГАДЕЛЛЕК БАРЫБЕР ҖИҢДЕ

Фотограф Мидхәт Шакирҗановның бу фотосында Бельгия патриоты Андре Тиммерманс белән аның хатыны, Муса Җәлилнең хатыны Әминә ханым һәм кызы Чулпан сурәтләнгән. Фото 1966 елның 15 февралендә «Казан» кунакханәсендә төшерелгән. Алар герой-шагыйрьнең 60 еллыгы тантаналарына килгән иде. Әгәр Тиммерманс фашистлар төрмәсеннән Җәлилнең шигырьләре язылган дәфтәрен исән-имин алып чыгып совет илчелегенә тапшыра алмаган булса, шагыйрьнең даны бөтен дөньяга тарала алмас та иде.

Илебездә Җәлилгә мөнәсәбәтнең нинди булуы күп очракта аның Моабит дәфтәрләренә бәйле. Мәгълүм булганча, беренче дәфтәр Татарстан Язучылар берлегенә 1946 елның 2 апрелендә килеп ирешә. Аны әсирлектән элекке легионер Габбас Шәрипов алып кайта.

Икенчесен 1949 елда безнең илчелеккә Андре Тиммерманс тапшыра.

Өченчесенең эзе 1991 елда ачыклана. Аны Тышкы разведканың Рим резидентурасы таба. Тик ул СМЕРШ архивларында югала. Ни кызганыч, кулъязма әлегәчә табылмаган.

Әлбәттә, Г.Шәриповның Муса Җәлилне яхшы белүе аңлашыла. Ә менә Тиммерманс ничек шундый хәвефле адымга барырга җөрьәт итте икән? Куен дәфтәрен бихисап төрмә тикшерүләреннән ничек саклап кала алган? Монысы гаҗәбрәк. Тагы да искитмәлесе – җаваплылыкны үз өстенә алып, бер кешене өченче куен дәфтәре белән фронт сызыгы аша чыгарып җибәрүче – безнең разведканың Италиядәге резиденты Н.Горшковның үзебезнең КАИ шәкерте булып чыгуы.

Җәлилне аклау тарихы да гаҗәеп серле. ВКП(б) өлкә комитеты секретаре З.Моратов 1946 елдан 1952 елга кадәр республика КГБсын Муса турында запрослар җибәреп тинтерәтә. Югыйсә, сугыштан соңгы репрессияләр тәгәрмәче нык әйләнгән чор була бу. Моратов КГБда тупланган, шагыйрьне аклый торган документлар белән таныша барып, Җәлилнең гаепсезлегенә инанган булырга тиеш.

Җәлилнең дусты, галим һәм язучы Гази Кашшаф легионга һәм Идел-Урал комитетына кагылышы булган кешеләрне эзләп табып, алардан истәлекләрен язып ала. Моны КГБ да сизә. Нәтиҗәдә, туктаусыз сорау алулар башлана. Шулай да Гази Кашшаф иректә кала. Мөгаен, аны Моратов яклап килгәндер. Хрущев «җепшеклеге» башлангач исә, Г.Кашшаф язмаларын КГБга тапшыра.

1952 елның август башында Муса һәм аның көрәштәшләренә кагылышлы шикләнүләргә нокта куела. «Югарыдан» бирелгән күрсәтмәләргә, тикшерүләрнең объектив булмавына карамастан, Җәлилне һәм аның дусларын акламый кала алмыйлар. Хәтта җәлладның да җәллады дип саналган республика КГБсы генералы Д.Токарев та җәлилчеләрнең гаепсезлеген танырга мәҗбүр була.

Шулай итеп, гаделлек барыбер җиңде. ■

Моабит дәфтәре






Безнең мирас №11 ноябрь 2019

# Истә, һаман да истә!

## *Шагыйрь Шәрәф Мөдәрриснең туууына 100 ел*

Шагыйрь, хикәяче, публицист һәм тәрҗемәче Шәрәф Хасиятулла улы Мөдәррисов 1919 елның 1 ноябрендә Татарстанның Чүпрәле районындагы Түбән Каракитә авылында туган.

Ш.Мөдәррис 1935 елда Казанга килә һәм Педагогия институты каршындагы рабфакка укырга керә. Тәүге шигырьләре 1933 елда ук матбугатта күренә башлаган егетнең 1937 елда «Үскәндә» исемле беренче шигъри җыентыгы басылып чыга. Яшь шагыйрьнең әдәби тәрҗемә өлкәсендәге беренче тәҗрибәләре дә шушы чорда башлана. 1941 елның язында Ш.Мөдәррис гаскәри хезмәткә алына һәм Бөек Ватан сугышының беренче көннәреннән үк алгы сызыкта була: әүвәл – минометчы, ахырга таба фронт газеталарының хәрби мөхбире сыйфатында сугыш юлын уза, яралана, контузияләр ала, шәхси батырлыклары өчен орден-медальләр белән бүләкләнә.

1946 елның язында хәрби хезмәттән кайткач, Ш.Мөдәррис Казанда республика газеталары редакцияләрендә әдәби хезмәткәр булып эшли. 1956 елда, читтән торып, Мәскәү Әдәбият институын тәмамлый. Ул зур күләмле поэмалар (мәсәлән, «Тупчы Ваһап», 1943), шигъри повестьлар («Биш минут», «Яшел тасма», «Үлемсезлек», «Кызыл мәйдан», «Яшәү көче», «Йолдыз атыла» һ.б.) яза, памфлетлар, хикәяләр, «Әбдүш Ялаяпов» дигән каһкаһәле повестен иҗат итә. Шагыйрь тәрҗемә өлкәсендә дә актив эшли: инглиз теленнән Шекспир сонетларын, «Король Ричард» трагедиясен, Байрон, алманчадан Һ.Һейне шигырьләрен, урысчадан А.Пушкин, Н.Некрасов, чуашчадан К.Ивановның поэтик әсәрләрен («Нарспи» поэмасы) татарчага тәрҗемә итеп бастыра.

1946 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы булган Ш.Мөдәррис 1963 елның 28 апрелендә вафат булды.

## *Режиссер Гали Хөсәеновның туууына 100 ел*



Актер, театр һәм телевидение режиссеры, ТАССРның һәм РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1966, 1972), Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (1979) Гали Кәрим улы Хөсәенов 1919 елның 2 ноябрендә Казан губернасының Зөя өязендәге (1920-1927 елларда Зөя кантоны, хәзерге Яшел Үзән районы) Күгәй авылында туган.

Г.Хөсәенов1949 елда Мәскәү татар театр студиясен тәмамлый.

1949-1952 елларда – Г.Камал исемендәге татар дәүләт академия театрында артист, Татарстан Министрлар Советында сәнгать эшләре идарәсенең театр бүлеге мөдире, 1952-1969 һәм 1972-1975 елларда исә Татарстан радиосында – мөхәррир, Казан телевидение студиясендә режиссер (алга таба – баш режиссер) булып эшли. 1969-1972 һәм 1975-1983 елларда Әлмәт театрында баш режиссер вазыйфасын башкара.

Г.Хөсәенов тарафыннан телевидениедә һәм театрда куелган спектакльләр: «Анам кыры» (Ч.Айтматов, 1965), «Муса» (Ш.Маннур, 1966), «Әниемнең ак күлмәге» (Ш.Хөсәенов, 1971), «Кар астында кайнар чишмә» (А.Гыйләҗев, 1976), «Ай булмаса, йолдыз бар» (Т.Миңнуллин, 1978) һ.б.

Бүгенге көндә Татарстанның Яшел Үзән районындагы Күгәй авылы мәдәният йорты Г.Хөсәенов исемен йөртә.

Г.Хөсәенов 2001елның 1 мартында вафат булды.

## *Рәссам Илдар Зариповның тууына 80 ел*

Россия Федерациясенең халык рәссамы (2002), ТАССРның һәм РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1976, 1983), Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (1974), Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының Б.Урманче исемендәге премиясе лауреаты, Россия Сәнгать академиясенең көмеш медале иясе Илдар Касыйм улы Зарипов 1939 елның 13 ноябрендә Казанда туган.

1956-1961 елларда – Казан сәнгать училищесында, 1962-1968 елларда исә В.И.Суриков исемендәге Мәскәү сәнгать институтында белем ала. Рәссамның «Өйдә» (1971), «Нефтьче Әхәт абый» (1974), «Казан чибәре Зөлфия» (1984), «Катюша», «Батыр» (1985), «Кырлай моңы» (1986, 1988), «Авылда» (1987), «А.С.Пушкин» сериясеннән пейзажлар» (1980 еллар) кебек гүзәл әсәрләре аеруча киң танылу алды.

И.Зарипов 2012 елның 14 июнендә вафат булды.

## *Артист Фәрит Мәмәшнең тууына 75 ел*

Актер Фәрит Исмәгыйль улы Мәмәш (Мәмәшев) 1944 елның 17 ноябрендә Казанда туган.

1970 елда Ф.Мәмәш Казан театр училищесын тәмамлый һәм Әлмәт драма театрында эшли башлый. 1982 елдан вафатына тиклем – Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артисты.

Ф.Мәмәш башкарган кайбер рольләр: Бики – «Хуҗа Насретдин» (Н.Исәнбәт), Гаврило – «Бирнәсез кыз» (А.Островский), Мортый – «Бәхетсез егет» (Г.Камал), Хаҗи – «Миңлекамал» (М.Әмир), Марат – «Ахырзаман» (Ч.Айтматов), Дивана – «Ай тотылган төндә» (М.Кәрим), Хәйрүш – «Ат карагы», Тамада – «Илгизәр + Вера» (Т.Миңнуллин), Гата – «Кишер басуы» (З.Хәким), Дәрвиш – «Идегәй» (Ю.Сафиуллин), Корнехо – «Биюче» (Лопе де Вега), Шаһиәхмәт – «Артист-шоу» (Г.Кариев), Катиелло – «Гаугалы гаилә» (Эдде Филиппо), Ләззәт – «Баскетболист» (М.Гыйләҗев) һ.б.

Ф.Мәмәш 2004 елда вафат булды.

*Сәхифәне* ***Ләбиб Лерон*** *әзерләде.* ■

Безнең мирас №11 ноябрь 2019

# МӘКТӘПЛӘР ҺӘМ САБАКТАШЛАР

Ләбиб Лерон

## ЮГАРЫ ЯХШЫЙ МӘКТӘБЕ. СЫЙНЫФТАШЛАР

Югары Яхшый мәктәбендә укыган сыйныфташлар утыз сигез елдан соң кабат очрашты. Олы Имән авылы. 13 апрель, 2019 ел. Ленар Гобәйдуллин фотосы

Югары Яхшый мәктәбе гербы

...Шулай итеп, 1972 елның 1 сентябрендә без – төрле авыллардан (Олы Имән, Тәкмәк, Табанлы Күл, Югары Яхшый, Түбән Яхшый, Наратлы-Мәчти) җыелган балалар Югары Яхшый авылының агач мәктәбендә укый башладык. Безне төрле елларда Гали абый Шәйхин (тарих), Әбүгали абый Вәлиев (татар теле һәм әдәбияты, рус теле һәм әдбияты, сызым), Римма апа Разова (математика, алгебра, геометрия), Миргалим абый Әпсәләмов (рәсем), Шамил абый Латыйпов (физкультура), Энҗе апа Разова (география, җыр), Фәһиянур апа Вәгыйзова (тарих, җыр), Энгель абый Әһәдуллин (хезмәт), Фирдәвис абый Лаисов (физкультура), Әлфия апа Басыйрова (рус теле һәм әдәбияты), Фәнүсә апа Ситдыйкова (ботаника, зоология), Әхнәф абый Сәлахов (физика), Әлфинур апа Исламова (рус теле һәм әдәбияты), Гүзәлия апа Латыйпова (химия, биология), Зинфир (Динфир) абый Солтанов (физика), Дилшат абый Мөхәммәдиев (сызым, физкультура), Гайниямал апа Гыйльмуллина (биология, география), Мария апа Сәлахова (рус теле һәм әдәбияты), Галимә апа Галләмова (рус теле һәм әдәбияты ), Нина апа Петрова (рус теле) һәм Оркыя апа Хәмидуллина (татар теле һәм әдәбияты) укытты. Бу елларда безнең сыйныф җитәкчеләре булып: 4-6 сыйныфларда – Әбүгали Вәлиев, 7 сыйныфта – Галимә Галләмова, 8 сыйныфта берьюлы өч укытучы – Гөлсинә Исламова, Гүзәлия Латыйпова һәм Дилшат Мөхәммәдиев торды.

---

Дәвамы. Башы журналның 8 нче (2019) санында.

Шушы урында, форсаттан файдаланып, мөгаллимнәребезнең барчасына да чиксез рәхмәтләремне җиткерәм һәм сыйныфташларымның туган авылларына, шулай күп укытучыларыбызга бәйле кайбер кызыклы фактларга тукталып үтәм.

Оренбург Мөселман диния нәзарәтенең бишенче мөфтие Мөхәммәдьяр Солтанов

XVIII гасыр урталарында нигез салынган һәм элек Уфа губернасының Минзәлә өязендәге Бүләр волостена караган Мәчти (ягъни «мәчетле»; «поместье» дигән урыс сүзеннән ясалган, дигән фараз да бар; авылның урысча исеме – Мастеево) авылы бүген юк инде. Без укыган елларда аны, Мәчти исемен үзгәртеп, Наратлы дип йөрттеләр. Бу авылда ике зур шәхес – чыгышы белән морзалар нәселеннән булган дин эшлеклесе, Оренбург Мөселман диния нәзарәтенең бишенче мөфтие Мөхәммәдьяр Солтанов (1836-1915) һәм аның туганы – татарлар арасыннан беренче булып музыкаль белем алган флейтачы, фольклорчы, Саратов консерваториясе укытучысы, музыка профессоры Мансур Солтанов (1875-1919) дөньяга килгән. Табанлы Күл авылында исә Татарстанның атказанган артисты (1989), күренекле җырчы Хәнәви Шәйдуллин (1938-2001) туган.

Югары Яхшыйда беренче мәктәп 1924 елда Хәерлеәнем Мәкыймов йортында ачыла. Язучы Сәмига Сәүбәнова, ветеринария фәннәре докторы, профессор Дөлфәт Шәрипов шушы авылда туган. Түбән Яхшый тумасы, композитор Илһам Хисмәтуллин, Олы Имән авылы егете, «Ялкын» һәм «Сабантуй журналларының баш мөхәррире Илназ Фазуллин, шулай ук, журналист һәм Татарстан китап нәшрияты мөхәррире, Түбән Яхшый кызы Айсылу Галиева (Галиәхмәтова) – Югары Яхшый авылы мәктәбен тәмамлаган шәхесләр.

Укытучыларым Гайниямал апа Гыйльмуллина, Нина апа Петрова, Дилшат абый Мөхәммәдиев

**Укытучым Римма Разова белән. 13 апрель, 2019 ел.** Ленар Гобәйдуллин фотосы

Бертуган Энҗе һәм Римма Разовалар – укытучылар династиясеннән. Аларның әтисе Миргаяз абый Киров мәктәбендә тарихтан укытты. Миргаяз абыйның улы Рим исә Пучының данлыклы мәктәбендә, вафатына тиклем, директор вазыйфасын башкарды. Физкультура укытучысы Фирдәвис абый – әдәбият галиме, тәнкыйтьче һәм педагог Наип Лаисовның бертуган энесе. Гайниямал апа Гыйльмуллина – Әнәк авылы кызы, ул Татарстан Республикасының Беренче Президенты Минтимер Шәймиев белән бер сыйныфта укыган (мин бу хакта күп еллар узгач кына белдем, әлбәттә). Рәсемнән укыткан Миргалим абый Әпсәләмовның (аның хатыны Әлфия апа интернатта тәрбияче булып эшләде) кияве – язучы, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, тарихи романнар авторы Вахит Имамов. Физкультура укытучысы Шамил абый Латыйпов – спортка, ә Фәһиянур апа Вәгыйзова тарих белән җырга мәхәббәт уяткан укытучыларым. Фәһия апа (гадәттә, без аңа, исемен кыскартып, шулай дәшә идек) баянда үзе уйный, үзе җырлый иде. Аның безгә өйрәткән бер җыры әле дә истә:

Линейка вакытында (сулдан уңга): укытучыбыз Фәһиянур Вагыйзова, сыйныфташлар – Әхсән Закиров, Флүс Нургалиев, Илһам Нәҗмиев, Фирдәвис Имамов, Илдар Насретдинов, Согъдә Гыйльфанова, Зиннур Бәдретдинов, Айрат Камалов, Марат Галиев, Шәүкәт Газетдинов, Дөлфинә Камалова, Гөлүсә Шәйхелисламова, Диләә Хәсәнова, Равилә Хәбирова, Гөлфая Нуретдинова, Нурания Гыймазетдинова, Фәнзия Хәбирова, Дания Бәхтиева, Гөлдәмия Харрасова, Хәния Имамова, Энҗе Ситдыйкова, Сәвия Әмирова, Римма Шакирова, Мәрвә Әһлиева, Нәфисә Солтанова, Рәфинә Әхмәтова, Дәнирә Нигъмәтуллина.

Тәкмәк авылы укучылары (уңнан сулга): Флүс Нургалиев, Альберт Галиев, Илһам Нәҗмиев, Дания ..., Вера Сәлахова, ..., Дилә Хәсәнова, ..., Гөлүсә Шәйхелисламова, Энҗе Ситдыйкова, Согъдә Гыйльфанова, Нурания Гыймазетдинова, Фәнзия Хәбирова, Фирдәвис Имамов, ..., Әгъләметдин Зиннәтуллин, Роберт Заһиров, Фазыл Һашимов (култык таяклары белән), Радик Ситдыйков, ..., ... . Өлкәннәр арасында Югары Яхшый мәктәбендә безгә дә белем бирәчәк укытучыларыбыз Мария апа Сәлахова белән Нина апа Петрова да бар. 1 сентябрь, 1969 ел

*Сагыш дигән сүзләр алар*
*Миңа да бик таныш лар.*
*Чит җирләргә китеп кенә*
*Басылмый ул сагышлар.*

*Кичке һаваларны яра*
*Ямансу тавышлары.*
*Кошларның да була икән*
*Моңнары, сагышлары...*

Без бик яратып җырлаган әлеге җырның сүзләрен язган кеше шагыйрь Рәшит Гәрәй булуын мин 1980 нче еллар ахырында – Актаныш районының Иске Сәфәр мәктәбе укучылары белән очрашкан вакытта, авторның үзеннән ишетеп белдем. Рәшит абый шушы шигырьне укыганда, нинди хисләр кичергәнемне чамалыйсыздыр.

Язмамның алдагы өлешләрендә мин Олы Имәндә бергә укыган сыйныфташларымның исем-фамилияләрен атап үткән идем инде. Тәкмәктән Югары Яхшыйга

Алтынчы сыйныфта укыганда төшкән фото. Утырганнар (сулдан уңга): Заһид Гыйльфанов, Айзирәк Хәтимова, Әбүгали Вәлиев (сыйныф җитәкчесе), Мөнирә Ганиева, Дәнирә Нигъмәтуллина, Мәрвә Әһлиева; икенче рәттә (басканнар): Рәдиф Наҗаров, Ленарис Леронов (Ләбиб Лерон), Азат Каюмов, Индус Хәйретдинов, Илдар Саматов. 1974 ел

Сыйныфташым, Мәчти (Наратлы) авылы кызы Нәфисә Солтанова

йөреп укыган сыйныфташларымны да (Сәвия Әмирова, Нурания Гыймазетдинова, Роберт Заһиров, Әгъләметдин Зиннәтуллин, Фирдәвис Имамов, Салават Нәгыймов, Илһам Нәҗмиев, Гөлфая Нуретдинова, Равилә Хәбирова, Фазыл Һашимов) онытмадым шикелле. Инде менә башка авыллардан килеп, Югары Яхшый мәктәбендә бергә укыган сыйныфташларымны барлыйм: Мәчтидән (ягъни Наратлыдан) – Нәфисә Солтанова (хәзерге вакытта ул Казандагы даруханәләрнең берсендә эшли), Дилүсә Шәвәлиева, Нурсинә Айдарова, Альберт Җиһангиров (Янгиров), Рәсим Шәвәлиев; Түбән Яхшыйдан – Гөлнур Гарипова, Шәүкәт Газетдинов (бүгенге көндә Чаллы катыргыкәгазь комбинатында токарь булып эшли),

Рус теле укытучысы Әлфия апа Басыйрова. 1975 ел

Югары Яхшый мәктәбендә бергә укыган сыйныфташлар: утырганнар (сулдан уңга) – Мөнир Әһлиев, Рәдиф Наҗаров; басканнар – Ленарис Леронов (Ләбиб Лерон), Азат Каюмов. 1974 ел

Хәния Имамова, Марат Галиев (озак еллар эретеп ябыштыручы булып эшләгән, хәзер Нефтекамскида яши), Рәйханә Вәҗетдинова, Дөлфинә Камалова, Гөлдәмия Харрасова, Айрат Камалов, Әхсән Закиров, Илдар Насретдинов (инде мәрхүм); Югары Яхшыйның үзеннән – Альберт Галиев, Вера Сәлахова (укытучыларым Мария апа белән Әхнәф абыйның кызы), Энҗе Ситдыйкова, Согъдә Гыйльфанова («КамАЗ» ААҖнең двигательләр заводында эшләгән, хәзер пенсиядә), Хәмит Хәсәнов, Гөлүсә Шәйхелисламова, Флүс Нургалиев, Дилә Хәсәнова, Зиннур Бәдретдинов (башта – Чаллыда, аннары «Норильский никель»дә (Норникель) эшләгән, хәзерге вакытта Норильскида яши, туган якка кайтып төпләнергә җыена), Дания Бәхтиева...

Югары Яхшый мәктәбендә укыган чакларны гына кәгазьгә төшерсәң дә, тулы бер китап тәшкил итәр иде. Кем белә, исән-сау булсак, андый китап та язылыр әле, шәт! ■

# БОРЫНГЫ ТАТАР МИЛЛИ МУЗЫКА УЕН КОРАЛЛАРЫ

Ринат Гыйләҗев,
*«Сорнай» фольклор ансамбленең сәнгать җитәкчесе*

## ЯТАГАН

*Борынгы моң онытылса,*
*Көйсез була замана.*
*Ләис Зөлкарнәй*

Ятаган, чатхан, җетаген – җиде кыллы уен коралы.

XVIII йөздә Идел, Урал, Себер якларын өйрәнүче галимнәр И.Лепехин, И.Георги, П.Паллас, П.Рычков үз хезмәтләрендә төрки халыклардагы тагаракка охшаш музыкаль инструмент турында яза. Алар аны төрлечә атый: ятаган, ятага, елтага, җетаган. Игътибар итик: бу төшенчәнең нигезендә җиде һәм аһәң сүзләре ята.

XIX гасыр башларында Оренбург татарларының көнкүрешен өйрәнгән А.Масловның бер хезмәтендә болай диелгән: «Татарларда гөслә еш очрый, ләкин гөсләгә кадәр аларда

Дәвамы. Башы журналның 1 нче (2019) санында.

шуңа охшаш җиде кыллы үзгә уен коралы булган. Алар аны етиган дип йөрткәннәр». А.Маслов әлеге уен коралының якынча үлчәмнәрен дә күрсәтә: озынлыгы – 102 см, киңлеге – 14 см, биеклеге – 14 см. Кылларының көйләнелеше билгеле түгел.

И.Георги Әстерхан һәм Идел-Урал татарларында да шундый ук уен кораллары булуын искәртә: «Алар үзләренең яткан арфага охшаш уен коралларында уйныйлар һәм аны елтага дип атыйлар».

Халык авыз иҗатында ятаганның килеп чыгышы турында гаять гыйбрәтле риваять бар.

Бик борынгы заманнарда бер карт белән карчык яшәгән. Алар бик тату гомер итеп, берсеннән-берсе баһадиррак, мәһабәтрәк җиде угыл тәрбияләп үстергәннәр. Көннәрдән беркөнне күрше илнең патшасы, шушы матур тормышның ямен җибәреп, болар иленә яу чаба. Ил-җир өчен авыр көннәр башлана. Дошманга каршы көрәштә карт белән карчыкның өлкән уллары шәһит китә. Ата-ана бик кайгырыша, елаша. Шунда карт, бер такта кисәген алып, аңа угылы атланып йөргән аттан бер кыл тарттырып куя. Айлы озын кичләрдә моңланып-сагышланып утырганда ул шушы кылны чиртеп карый һәм, аның тавышына кушылып, тулгау әйтә:

«Тудың илгә ир булып, әү,
Ир булып, терәк булып,
Үз илеңдә көн күрдең,
Гадел булып, пакь булып,
Бүген безне калдырдың, әү,
Батыр атлы дан булып,
Мәңге үлмәс җан булып».

Күп тә үтми, боларның икенче угыллары да шәһит китә. Бабай тактага янә бер кыл тарттыра, янә тулгау әйтә:

«Илең, халкың хакына, әү,
Илең, халкың хакына
Курыкмадың, дан булдың,
Туган җирең хакына,
Куркак ирдән ни калыр, әү,
Ирмен, дигән батыр ирдән
Мәңге үлмәс җыр калыр».

Ил-җирнең азатлыгы, ыругның бәйсезлеге өчен көрәштә карт белән карчыкның өченче, дүртенче, бишенче, алтынчы угыллары да бер-бер артлы шәһит китәләр. Карт аларның һәрберсе өчен аерым кыл тарттыра һәм тулгау әйтә:

«Кыш салкынын җәй иткән, әү,
Җәй чилләсен май иткән.
Ир-егеткә дәрт биреп,
Иленә тугры ир иткән
Җыр булмыйча, ни булсын, әү,
Аны сезгә җиткергән,
Мин булмыйча, кем булсын».

Канлы күз яшьләре, бихисап каһарман ир-атларның өзелгән гомерләре бәрабәренә,

карт белән карчык яшәгән ил гаскәре дошманны җиңә. Әмма соңгы, хәлиткеч сугышта аларның төпчек – җиденче угыллары да шәһит китә. Бу кайгыны ата-ананың ничек кичергәннәрен тел белән сөйләп, каләм белән язып кына аңлатып буламыни?! Шунда карт үзенең тактасына тагын бер кыл тарттыра. Кылларны чиртеп, алар белән серләшә, сөйләшә, хәсрәтен тарата икән. Шулай итеп, дөньяда җиде кыллы җетаган, җиде аһәң, ятаган дигән җиде тавышлы музыка коралы барлыкка килгән, ди.

Истәлекләрдән күренгәнчә, борынгы ятаганның формасы озынча тагаракка охшаган, өске тактасы булмаган. Кылларын тарттырып кына бәйләп куйганнар. Соңрак өске ягына да такта куеп эшли башлаганнар. Һәр кылның бер башына күтәртмә-мендәрчекләр куелган. Аларны күчереп, һәр кылны билгеле бер тавыш югарылыгына көйләгәннәр. Кылларының көйләнелеше сакланмаган.

Гадәттә, ятаганда уйнап, үзләү (горловое пение) алымы белән халыкның батырлыгы турында героик җырлар җырланган, батырларны мактап тулгау әйтелгән, риваятьләр сөйләнгән. Яхшы үзләүче, шаманнар кебек үк, аерым бер камлау көченә ия булып, нинди дә булса бер уен коралына кушылып камлаган. Үзләүче уен коралын тере, изге итеп күргән, аның белән сөйләшкән. Тавышы һәр кешенең йөрәгенә барып ирешсен, беркайчан да утырмасын (бетмәсен) өчен, уен коралын кымыз һәм башка эчемлекләр белән «сыйлаган»...

Соңгы елларда онытыла төшкән ятаганны төрки халыкларның күбесе яңадан өйрәнеп, тагын да камилләштереп ясый башладылар. Традицион җиде кыл урынына кылларының саны да унбишкә, егерме бергә кадәр җитте.

Татарстанда беренче тапкыр ятаганны, тарихи чыганакларга һәм галим Рәгъде Халитов киңәшләренә нигезләп, «Сорнай» ансамбле өчен 1980 елда Арча педагогика училищесы укытучысы Ринат Алмаев ясады. Аның озынлыгы – 90 см, киңлеге – 30 см, биеклеге 15 см булып, өске тактасына җиде металл кыл тарттырылган иде.

1989 елда Казакъстанның Павлодар каласында яшәүче оста Шакен ага Рәхишев, без биргән сызымнар буенча, унике кыллы ике ятаган эшләп бирде. Аның берсе хәзерге вакытта Казан дәүләт консерваториясендә саклана.

2000 нче елдан башлап, Казанда ятаганны уен кораллары остасы Таһир Вәлиуллин ясый.

Ятаганның озынлыгы – 133 см. Кыллар беркетелгән бер башының киңлеге – 28 см, боргычлар урнашкан икенче башының киңлеге – 26 см. Уртасы, киңәеп, 29 см тәшкил итә. Өске, аскы һәм ян-як тактаалары 2-3 мм калынлыктагы ботаксыз ак чыршы агачыннан ясалган. Биеклеге – 10 см. Аңарга әзер гитара колоклары куелган, 12 кыл тарттырылган. Кыллар махсус боргычлар ярдәмендә кирәкле тавышка көйләнелә. Түбән тавышлы өч кыл урынына – 0,9 мм калынлыктагы капрон җеп (леска), уртадагы җиде кыл урынына – 0,7 мм, югары тавышлы ике кыл урынына 0,5 мм калынлыктагы металл кыллар тарттырылган. Кылларның арасы – 2 см. Һәр кылның астына махсус күтәртмәләр (мендәрчекләр) куелган. Аларны күчереп, тавышларны тагын да төгәлрәк итеп көйләргә була. Кылларның көйләнелеше түбәндәгечә:

түбән тавышлы өч кыл (бака кыллар) зур октаваның соль, ля, си;

урта кыллар (көй кыллары) кече октаваның ре, ми, фа, соль, ля, си, до;

югары тавышлы ике кыл беренче октаваның ре, ми тавышларына көйләнә.

Уйнаганда ятаганның бер башын сул аякның тезенә, икенче башын урындыкка яисә идәнгә куябыз. Сул кул белән бас кылларын, ә уң кул белән көй кылларын чиртеп уйныйбыз. Аның тавышы түбән, ягымлы. Аккомпанемент яисә бас партияләрен уйнау өчен бик килешеп тора. Ятаган – төрле зурлыктагы ансамбльләр өчен алыштыргысыз милли уен коралы. ■

Безнең мирас №11 ноябрь 2019

# ТУКАЙГА ЯКЫНАЮ ЮЛЫНДА

Әхтәм Зарипов

*Сәнгатьтә даһи шәхескә – Тукайга якынаю юллары күптөрле. Чәчмә әсәрләрнең үз юлы, шигъриятнең, музыканың, театрның – һәркайсының үзенә генә хас якынаю баскычлары бар. Ул баскычлар буйлап һәр сәнгать төре вәкилләре күтәрелергә омтылса да, күтәрелде, максатына иреште, дип әйтү – алардан соң күтәрелергә теләүчеләргә «юл ябык», дигән кебек булыр иде. Юллар ачык!*

Тукайга якынаерга омтылу – мәңгелек процесс ул. Даһига якынаерга, аның даһилык серен ачарга омтылучыларның иң күбе шигъриятә һәм сынлы сәнгать вәкилләре арасындадыр. Музыкаль дөньяда шагыйрьгә багышланган, аның шигъри җәүһәрләре белән рухланып иҗат ителгән җырлар, симфония, опера-балет әсәрләре булу да сәнгатьнең бу өлкәсендә иҗат итүчеләрнең Тукайга якынаерга омтылулары турында сөйли. Мин бу язмамда үземә һөнәри якын булган театр сәнгатендә шагыйрь образын тудыруга, аңа якынаерга омтылыш баскычларына гына тукталырга ниятлим. Үзең катнашкан эшләр турында объектив фикер йөртү читенлегеннән, мине ул хәлләрнең инде ярты гасыр элек булуы коткармаса да, үзебезнең иҗатка читтән карап бәһаләү мөмкинлеге бирер, дип өметләнәм һәм игътибарымны ерак яшьлек елларына юнәлтәм.

...1961 елның язында безне – Мәскәүдә укып ятучы татар студиясе шәкертләрен, диплом эшебезне күрсәтер өчен, Казанга кайтардылар. Спектаклебез, Әхмәт Фәйзинең «Тукай» драмасы буенча Камал театры корифейлары катнашында куелып, репертуарда ныгып калырга тиеш иде. Рольләргә без – шәкертләрдән тыш, Хәлил Әбҗәлилов, Камал III, Ибраһим Гафуров кебек артистлар билгеләнүе – спектакльнең уңыш казанып, озын гомерле булачагына гарантия, диделәр.

Яз. Гагаринның космоска очкан көннәре. Тукайның тууына 75 ел тулуны лаеклы каршылау өчен, республикада гына түгел, ил күләмендә дә әзерлек чаралары күрелә.

Ниһаять, премьера. Спектаклебез турындагы хәбәрләр, Гагаринның космоска очуыдай тиз таралып, телләрдән телләргә күчәр дип көтсәк тә, яшьләр газетасында Барлас Камалов язган кечкенә мәкаләдән тыш башка язма материаллар күренмәве «кикрикләребезне шиңдерсә» дә, студиянең театр штатына тулы составта кабул ителүгә ышанычны сүндермәде. Спектакльнең премьерадан соң уздырыла торган «худсовет» җыелышында (анда, ни өчендер, безне кертмәделәр) артистлар уенына уңай бәя биреп, тиздән «академия театры труппасына талантлы яшь көчләр кушылу Тукайны Тукай итеп күрү ихтималына өметләр уята» дигән сүзләр яңгыраса да, «Тукай» спектакленең бусы да көтелгән эффектны бирмәде, дигән фикернең өстенлек итүе – без шәкертләрнең өмет үсентеләренә кырау суккандай тәэсир итте. «Артист» дигән диплом әле кесәгә



Тукай – Дамир Хәйруллин, Галиәсгар Камал – Ринат Таҗетдинов. 1961 ел

кермәгән, киләчәгебез турындагы шик-шөбһәләр күңелгә кадалып, үз эшенә керешкән шомлы уйлар белән Мәскәүгә кайтып, яңа спектакль әзерләүгә имитация ясыйбыз.

Хәлфәләребез тарафыннан инде диплом эшләребезгә бәһа бирелгән, татар теле укытучыбыз Юныс Әминевне рәнҗетмәс өчен генә аның әсәре буенча спектакльгә репетицияләргә йөрибез, яңа җырлар өйрәнергә Әгъзам Фәттах дәресләрендә булгалыйбыз, дөресе – диплом көтеп, вакыт уздырабыз.

Шулай вакыт үткәрүен бер чарасы буларак, хатыным Җәмилә белән, авылда яшәүче бер яшьлек улыма посылка салу өчен витаминлы ризыклар эзләп, Пушкин урамындагы «Детское питание» кибетендә тиешле ризыкларны алырга акча саный башласам, кибет почмагындагы урындыксыз өстәл артында какао эчеп торучы бер кеше: «Зачем так много, обрати внимание на срок годности», – димәсенме! Андый сүзне ишеткәнем юклыктан гына: «На какой срок?» – дигәч, какао эчүче абзый, татарча: «Балалар ризыгына сак карарга кирәк. Беткәннән беткәнгә генә алсаң да, дефицит нәрсә түгел», – диде.

– Авылда дефицит алар, – дидем.

– Гаиләгез авылдамыни?

– Мин авыл малае ич.

– Шулай инде – безнең талантларыбыз чыгышлары белән күбесе авылдан. Тукай булып Тукай да авыл җимеше бит!

– Шулай шул – талантлар авылда туа, шәһәрдә үлә.

– Сезгә әле үлем турында түгел, яшәү турында, мәрхүм даһиларыбызны сәхнәдә терелтү турында уйларга кирәк.

– Кызганычка каршы, мин доктор түгел шул, абзый, актер гына.

– Сез, актерлар – җәмәгать докторлары. Сезнең «Мунча» спектаклен дә, «Ике фикер»егезне дә, «Тукай» спектаклен дә караган тамашачы буларак әйтәм: Тукаегызның Тукайлыгы тышкы охшашлыкта гына иде. Шагыйрьнең рухына ераклыгы спектаклегезне «школьный» ясалма, җансыз тамаша итте, шагыйрьдән социалист ясарга тырышу аннан ерагаюга этәрде. Ә менә син уйнаган шәмче Галигә мин ышандым.

– Әгәр минем белән янәшә Тукайны уйнаган Дамир Хәйруллин басып торса, Сез аңа да «ышандым», дип ышандырыр идегез.

– Мин бит Дамир начар уйнады, димәдем. Дөрес трактовать ителмәгәнлегенә генә

игътибарны юнәлттем. Моңа, актер түгел, автор җаваплы. Автор һәм режиссер. Тукайны мин Камал III, Ибраһим Гафуров, Габдулла Шамуковлар башкаруында да күрдем. Берсе дә Тукай була алмадылар. Дамирдагы тышкы охшашлык аның киләчәктә эчке охшашлыгына да өмет уята. Ташламасын гына.

– Һәр буынның Тукайны үзенчә күрсәтергә омтылуы гаепмени?

– Гаеп түгел – хата. Тукай бар иде, бер иде. Аны заман таләбенчә үзгәртү – хата гына түгел, җинаять. Мин үзем Тукайны якыннан күреп белгән, аның белән сөйләшкән, аңа хезмәт күрсәткән кеше – Мансур Мозаффаров булам.

– Моны ничек аңларга?

– Ничек ишетсәгез, шулай. Малай чакта мин «Болгар» номерларында яшәүчеләргә газета-журналлар керткәли идем. Шәкерт чагым. Шунда еш кына Тукай белән очраша идем. Әлбәттә, ул минем өчен хәзер аңлаган Тукай түгел, ә номерда яшәүче бер юмарт абый гына иде...

...Сүз моның белән генә бетмәсә дә, мин инде шоковый состояниедә калган идем. Бераздан, «Волга» машинасында килеп, бер кәттә кеше Мансур абыйны үзе белән алып китте. Бу очрашу турында композитор Әгъзам Фәттахка сөйләгәч, ул Мансур Мозаффаровның талантлы композиторларыбызның иң өлкәне булуы, хәзерге вакытта Тукайга багышлаган опера язуы белән янып йөрүе турында сөйләде. Әйе, ул сөйләде, мин тыңладым һәм эш шуның белән бетте дә.

Бу очрашуның дәвамы Казанга кайтып, театрда һәм параллель рәвештә радиода эшләгәндә булды. Беркөнне минем белән бер бүлмәдә утырып эшләүче Исмай Шәмсетдинов янына Мансур абый килеп керде. Гөлшат Зәйнашева сүзләренә язылган «Тукайны сагыну» җырын монтажлашырга килгән икән. Үзе сүз кузгатмагач, Мәскәүдәге очрашудан соңгы хәлләр турында сөйләшәсем килсә дә, «исәнмесез»дән тыш сүз булмады. Шомландым да, уйландым да. Ике композиторның килешеп эшләүләренә кызыгып утырсам да, эшләре беткәнче сүз катышмадык.

Яңа җыры әзер булып, аны тыңлагач, Мансур абый миңа карады да:

– Йә, шәкерт, җиттек Казанга, эшләр ничек? Кайныйбызмы? – диде.

Аптырап калуымны күргәч, Исмай абыйга карап: «Нигә сәхнәдә түгел, ә синең бүлмәдә бу малай?» – дигәч, Исмай абый:

– Театрда да, монда да өлгерә ул! – диде. Бу җаваптан соң, Мансур абый озак кына дәшми торды. Чыгып китәргә җыенгач кына:

– Бүлгәләнүләрне Тукай кабул итәр идеме икән? Итмәс иде, – диде дә, күрешергә кулын сузды.

Аның ни өчендер тирләп юешләнгән суык кулын әлегә кадәр хәтерлим.

Соңгы очрашуыбыз Тукай ролен уйнаган артистыбыз Дамир Хәйруллин үлгәч, аны җирләү көнендә, театрның фойесында булды. Кыска гына нотыгында: «Нәкъ Тукаебыз яшендә булган икән», – дигән сүзләре әле һаман колагымда. Шуннан соң Мансур абый да озак яшәмәде – кинәт кенә мәрхүм булды.

...Ул күңелсез көннәрдән соң бүгенгәчә ярты гасырдан артык вакыт узган. Мансур абый күрергә теләгән Тукай образын күрдекме соң? Дөрес, Тукай премияләрен алдылар алуын. Ә Тукай күренмәде дә, ишетелмәде дә. Хәтерем ялгышмаса, Әхмәт Фәйзидән соң, персонажлары исемлегендә Тукай булган 7 пьеса язылып нәшер ителсә дә, шулардан ике пьеса гына сәхнәгә менде. Кызганыч ки, алардагы Тукайлар Дамир тудырган Тукайдан да ераграк иде. Шулай итеп, әлегә Дамир Тукае шагыйрьгә иң охшаган артист булып кала.

Ләкин бу эзләнүләрне туктатуга сәбәп түгел. Иң элек драматурглардан әсәр көтәбез, аннары гына артистлардан.

...Тукаебызның сәхнәләрдә «чагылышы» хакында кыскача белешмә биргәндә,

күрәсең, ул заманнарда безнең театрда рольгә карап артист билгеләү булмаган, ә артистка, аның дәрәҗәсенә, театрда тоткан урынына карап роль биргәннәр. (Камал III – Хлестаковны (Гогольнең «Ревизор»ында), Отеллоны (Шекспир әсәрендә), Хәлилне («Галиябану»да) уйнаган артист Тукайны гына уйнамасмы?)) Мәрхүмнәр турында сөйләгәндә аларның фәкать яхшылыкларын гына искә алган кебек, татар артисты кайсы спектакльдә нинди роль башкарса да, аның уенын мактап кына телгә алу яисә бөтенләй телгә алмау – безнең театр «белгечләребезнең» төп сыйфатыдыр. Бүген Тукай ролен башкарган Камал III һәм Ибраһим Гафуровлар иҗатына багышланган мәкаләләрне укысак, андагы мәдхия терминнарының муллыгыннан «күзләр камашып», «башлар әйләнә»: «Рольне бөтен барлыгы белән романтик рухта ачты», «иң алдынгы прогрессив идеяләрне, үзе тапкан вак кына тормыш детальләре аша образ тудырды»... Кыскасы, шартлатырлык мактау сүзләре тезмәсеннән оешкан мәдхия. «Рольнең бөтен барлыгын», «аның романтик рухын», «алдынгы идеяләр чагылышы»ның ничек булырга тиешлеген бердәнбер белүче булып артист уенына «керләймә» сугып бәя бирү гаҗәпләндерә дә, күп сораулар да тудыра. (Күрәсең, шуңадыр, сәхнәдә образлар урынына муляжлар хөкем сөрә.) Ул чор мәкаләләрендә фикерне дәлилләү дә, пьеса мотивлары белән спектакль концепциясен чагыштырып, аермасын күрсәтү дә юк – бәһа генә бар.

...Әгәр артист үз уеныннан үзе канәгать булмаса? Әллә инде мактаучыга Шекспирның, яисә Гоголь белән Островскийның калдырган «шпаргалкалары» ярдәмгә киләме? Шулай булмаганда, Отелло белән Хлестаковның күңелендә тамашачы күрмәгәнне ничек күрә ул «белгеч»? Камал III, Тукай ролен уйнап, үзе турындагы мәдхияләр белән танышкач, шагыйрь ролен Ибраһим Гафуровка тапшыра. Бу гамәлен Камал III «шагыйрь образын дөрес күрсәтү өчен артистның эчке халәте белән тышкы кыяфәте дә тәңгәл килергә тиеш», дип аңлата. Артистны якыннан белүчеләр дә аны хуплыйлар. Чөнки Камал III олы авыр гәүдәсе, тәненең шигырьне «әйләндерүе» авырлыгы белән бегемотның тиен булырга тырышып сикерүен хәтерләтәдер. Ә Ибраһим Гафуров башкаруындагы Тукай образга казның аккошны хәтерләткәне кебек якынайса да, Ибраһим Гафуровның үзе әйтүенчә, «Тукай булып уйнар өчен, шагыйрь гомеренең 27 яшеннән бер елында булса да үзеңә яшәп карарга кирәк. Сезнең Дамир әнә шул гомерне үзе яшәгәнлектән, шагыйрь образы аңа якын да, үз дә иде».

Әгәр исән булса, Дамир татар театрының иң күренекле, иң данлыклы артистларының берсе булыр иде. Нибары биш еллык иҗади гомерендә аңа берсеннән икенчесе җаваплырак рольләр тапшыралар. Радиода да, фильмнар тәрҗемә итүдә дә, телевидениедә дә иң кирәкле, көтелгән, популяр артист була ул.

1966 елның февралендә Муса Җәлилнең 60 еллыгына телевидение куйган күп серияле спектакльдә Абдулла Алиш ролен уйнап кайткан төндә кинәт үлүе дә аны шул данлы шәхесләр рәтенә куя...

...Укытучылар гаиләсендә туган (Вятка-Нократ Аланы районында) Дамир, иртә ятим калып, әбисе тәрбиясендә үсә. Сабый чагыннан ук бик эшчән, үз теләгәненә ирешергә омтылган, китап укырга яраткан бала була. Үзе белән укыган Мәсхүдә исемле кызга өйләнеп, ике уллары туа, «квартира бирергә» дигән карар чыга. Әмма Дамир, фатирын күрә алмыйча, мәңгелек фатирына күчәргә ашыга.

Бүген Дамир Хәйруллин аны күргән-белгәннәрнең күңелләрендә яши.

«Тукайга якынаю юлында» дип аталган бу язмамны шушы урында түгәрәкләп, укып чыккач, мәкаләм, ничектер, өтек сыман, артистны бер рольгә генә бәйләп хәтерләү аны кимсетү кебегрәк тоелды да, шул уйлардан котылу өчен, артистның биографиясенә дә, башка рольләренә дә кыскача күзәтү ясап узарга булдым. Салулаган, буразнадан чыккан урыннар булса, укучымнан гафу үтенеп, имзамны куям. ■

# ОКТЯБРЬ

Фотолар һәм видео beznenmiras.ru сайтында

● 1 октябрьдә Казанда бер төркем зыялылар мәшһүр галим Лев Гумилев (1912-1992) бюстына чәчәкләр салды.

● 1 октябрьдә Г.Тукай исемендәге филармония янындагы скверда Татарстанның халык артисты Римма Ибраһимова үз агачын утыртты.

● 2 октябрьдә Башкортстанның халык шагыйре Мостай Кәримнең кызы Әлфия ханым Уфадагы тарих музеена мәшһүр әтисенең шәхси әйберләрен – өстәл лампасы, сәгать, каләм һәм дүрт шигырь кульязмасы тапшырды.

● 6 октябрьдә Казан шәһәренең Ленин исемендәге мәдәният сараенда, «Идел-Йорт» төбәкара халык театрлары фестивале кысасында, Мөслим халык театры Мостай Кәримнең «Ай тотылган төндә» спектаклен күрсәтте. Спектакль башланыр алдыннан тамашачыларны Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры директоры Илфир Якупов, Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты җитәкчесе Ринат Закиров, ТР Традицион мәдәниятне үстерү үзәге директоры Алсу Мифтахова, Г.Кариев исемендәге Татар дәүләт яшь тамашачылар театрының баш режиссеры Ренат Әюпов һәм «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире Ләбиб Лерон сәламләде.

● 10 октябрьдә ТР Фәннәр академиясендә Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты оештырылуга 25 ел тулуга багышланган тантаналы утырыш булып узды. Анда ТР Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Марат Әхмәтов, ТР Фәннәр академиясе президенты Мөгъзүм Сәлахов, БТК Башкарма комитеты рәисе Ринат Закиров һ.б. чыгыш ясап, институт коллективын әлеге юбилей

белән котлады. Утырышның икенче өлешендә ТР Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Марат Әхмәтов институтка һәм аның фәнни хезмәткәрләренә дәүләт бүләкләрен тапшырды.

● 10 октябрьдә бер төркем дин әһелләре һәм татар зыялылары Башкортстанның Туймазы шәһәрендә яшәп иҗат итүче каләм әһелләре һәм журналистлар белән очрашты. Шул ук көнне Татарстан кунаклары Төмәнәк авылы мәчетендә булдылар һәм Төмәнәк авылы янында урнашкан «Бабай утары» музей-комплексы белән таныштылар.

● 11 октябрьдә Татарстан Республикасының Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев Төркия Республикасының Казандагы яңа Генераль консулы Исмет Эрикан белән очрашты.



● 11 октябрьдә Татарстан дин әһелләре һәм зыялылары, Татарстан Диния нәзарәте рәисе, мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин җитәкчелегендә, Башкортстан башкаласы Уфада булып, җәмәгатьчелек белән очрашты.

● 14 октябрьдә Г.Кариев исемендәге Татар дәүләт яшь тамашачылар театрында «XXI гасыр тавышы» аудиоҗыентыгын тәкъдим итү чарасы узды.

● 15 октябрьдә язучылар Данил Салихов, Ләбиб Лерон һәм Рәдиф Сәгъди, Питрәчтәге 2 нче мәктәптә һәм районның Татар Тау Иле авылында булып, китап сөючеләр белән очрашты.

● 18-19 октябрьдә Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары Данис Шакиров, Ислам дине кабул ителүгә 1000 ел исемендәге Казан югары мөселман мәдрәсәсе ректоры Ильяс хәзрәт Җиһаншин, Бөтендөнья татар конгрессының Аксакаллар шурасы рәисе Рәүф Хәсәнов, Бөтендөнья татар конгрессының Казан бүлеге җитәкчесе

Фәрит Мифтахов, «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире Ләбиб Лерон, Ульяновскида һәм Иске Кулаткыда булып, Э.Ганиев исемендәге XX Иске Кулаткы укуларында катнашты һәм чыгыш ясады. ■

# Мирасворд

Ат җигү дирбиясе

Кар-шылык, тискәре-лек

Татар халык җыры

4047 ква-драт метр

Олы ир туган, абый

Борынгы ур-так баба, кан кардәшлеге нигезендә берләшкән кешеләр төркеме

Харрас Әюпнең 1980 елда чыккан тәү-ге шигырь җыентыгы

Яфрак рәвешен-дәге бизәк

Зөянең сул кушыл-дыгы

... туздыру

Чокып ясалган зур агач табак (диал.)

Сүз төркеме

Нияз ... (татар шагыйре, прозаик)

Аксак ... (җиһангир, Сәмәрканд әмире)

Әләк (диал.)

... Низами

Мәшәкать, комачау, ыгы-зыгы

Һади Такташ-ның улы

Татар артис-ты, язучы, тәрҗемәче

Оканың уң кушылдыгы

Билбау

Язучы Рәфкать ...

Шагыйрь Газинур ...

Японнарның милли киеме

Петр Чайковский операсы

Балавыз (иск.)

Матема-тик гамәл

Рәссам ... Абзгиль-дин

Газиз Кашапов-Үзиле повесте

Фени-мор ... (Америка әдибе)

Француз компо-зиторы

Дедал улы

Җәелеп, тарма-кланып үскән

Гаскәр (иск.)

Аты-... чыгу

Җеп эрләү коралы

Морза

Аксыл кызыл

Борынгы Спартада: игенче

Николай Гогольнең тәхәллүсе

Кәримул-лин, Сәгыйди

Явызлык, ачу

**10 нчы санда дөнья күргән мирасвордның җаваплары:**
**Сулдан уңга:** «Сабах», Руми, Рәмис, троп, җөббә, Брехт, «Ил», кактөш, Гафур, аса, мезолит, өмә, «Аклан», Ея, нам, амани, Карпов, Саттар, Лу, Ярмәки, лори, кәләвә.
**Өстән аска:** Сиражи, «Манас», өлге, БАМ, азамат, фок, ялт, Хисмәтуллина, Риан, Рамил, Кант, әрә, баз, Маликов, кратер, ару, илә, мате, Мао, Хөсәенов, патша.

*Рәис Габдулла* төзеде.

Ш.Усманов урамы, 9.
ТНВ бинасы



# «Безнең мирас»
## елъязмасы /ноябрь

**660 ел элек (1359)**

Магулстан ханы Тимер Туглук, таркау яткан Мавараэннаһерне әүвәлгечә Чагатай олысына кушу өчен, бирегә яу чаба.

**600 ел элек (1419)**

Туктамыш хан угыллары Идегәй мирзага каршы яуга күтәрелә. Хәлиткеч канлы бәрелеш Җаек тирәсендәге Сарайчык каласы (соңрак – Нугай йорты башкаласы) янында була. Каты яраланган Идегәй мирза Җаек елгасы буенда дөньядан кичә...

**390 ел элек (1629)**

Ноябрь башларында бараба татарлары яу белән килгән баскынчыларга каршы баш күтәрә. Аблайкәрим җитәкчелегендәге гаскәргә, тора-бара, бу якларда яшәгән калмык кардәшләр дә кушыла.

**135 ел элек (1884)**

Томски епархиясендә епископ Исаакий җитәкчелегендәге «Мөселманнарга каршы миссия үзәге» ачыла.

**125 ел элек (1894)**

17 ноябрьдә тел галиме, педагог, филология фәннәре докторы, профессор Латыйф Җәләй (1894-1966) дөньяга килә.

**100 ел элек (1919)**

Мәркәз Хәрби һәят хозурындагы «Сәйяр» труппасы 7 ноябрьдә Казанның Пороховой бистәсендә, шундагы эшчеләр өчен, «Октябрь революциясенең икееллык бәйрәме шәрәфенә», Шамил Госмановның (Усмановның) «Беренче адым» исемле инкыйлаби әсәрен сәхнәләштерә.

**75 ел элек (1944)**

Беренче Белоруссия фронтында «Кызыл Армия» исемле татарча газета чыга башлый. Гадел Кутуй, Ибраһим Гази һәм Гариф Галиев ошбу матбагада хәрби хәбәрче булып хезмәт итә.

**55 ел элек (1964)**

«Совет әдәбияты» журналында Нурихан Фәттахның «Бала күңеле – далада» исемле романы басыла башлый.

**25 ел элек (1994)**

1 ноябрьдә Татарстан Язучылар берлегенә язучы Ринат Мөхәммәдиевнең АКШның Төньяк Каролина штатында урнашкан Америка биография институтының Халыкара мәртәбәле дипломы белән бүләкләнүе турындагы телеграмма килә.

*Журналга* ***Марат Закир*** *әзерләде.* ■

## СОДЕРЖАНИЕ. НОЯБРЬ 2019

**И останется в мире слово моё…:** Дардменд.

**Историческое наследие:** «Этруски – римские умельцы». С.Шамси; «Татарские слободы и их история»; «Музей чатских татар в Умаре»; «Татары «Алты авыл» и братья Хамитовы». И.Биккинин; «Служилые татары Томска во время строительства Кузнецкой крепости». А.Аширов; «Татарская слобода в Симбирске». Р.Вилданова; «Жизнь татар города Томск на страницах газеты «Сибирия»; «История татарского театра в Томске». Н.Савельева; «Татарский квартал» в Екатеринбурге и торговцы Агафуровы». Л.Коновалова; «Древнее татарское кладбище в Екатеринбурге».

**Татарский мир:** «Борцы». Р.Сагди.

**Религиозное наследие:** «Исламский мир». Габдурашит Ибрагимов.

**Литературное наследие:** «Озеро – это людские слёзы». С.Сунчаляй; «Неизученное произведение Дардменда». Л.Хамидуллин; «Хусаин Мирза». Ф.Бурнаш; «Публицистическая поэма Сирина». А.Шарипов.

**В глубинах памяти:** «Школы и одноклассники». Л.Лерон.

**Художественное наследие:** «Древние национальные музыкальные инструменты». Р.Гилязов.

Журнал регулярно освещает все значимые события в жизни нашей нации.

## CONTENT. NOVEMBER 2019

**There will be left my word in the world…:** Dardmand.

**Historic heritage:** «The Etruscans are the Roman craftsmen» by S.Shamsi; «The great history of the Tatar settlements»; «The museums of the Chat Tatars in Yurt-Ora»; «The Tatars of «Alty avil» and the brothers Khamitovs» by I.Bikkinin; «Tomsk's service Tatars during of Kuznetskiy fortress's construction» by A.Ashirov; «The Tatar settlement in Simbirsk» by R.Vildanova; «The life of Tomsk's Tatars in the columns of «Sibiriya» newspaper»; «The history of Tatar theatre in Tomsk» by N.Savelyeva; «Tatar residential quarter in Ekaterinburg and the Agafurovs merchants» by L.Konovalova; «The ancient Tatar graveyard in Ekaterinburg».

**Tatar world:** «The extirpators» by R.Sagdi.

**Religious heritage:** «Islamic world» by Gabdurashit Ibragimov.

**Literary heritage:** «A lake is human tears» by S.Sunchalyay; «Dardmand's uninvestigated piece of work» by L.Khamidullin; «Khusain Mirza» by F.Burnash; «Sirin's publicistic poem» by A.Sharipov.

**From the deepest store of memory:** «Schools and classmates» by L.Leron.

**Creative heritage:** «The ancient Tatar national musical instruments» by R.Gilyazov.

The magazine constantly brings to light all the most important events of our nation's life.

# Челтәрле дә бизәкле

Томск шәһәренең Татар бистәсеннән фоторепортаж журналның 42-45 битләрендә

## АЛДАГЫ САНДА УКЫГЫЗ:

Рәсемдә (сулдан уңга): телевидение режиссерлары Эдмас Утәганов, Эмиль Ключарев һәм телеоператор Әнвәр Миңнуллин (Ә.Фәйзрахманов. «Тылсымлы тартма»ның беренче адымнары )

**«Тылсымлы тартма»ның беренче адымнары. Әгъзам Фәйзрахманов**
**Гыйлем үзәге... бар иде. Тәлгат Галиуллин**
**Рухи хәзинәбезне барлаганда. Хатыйп Миңнегулов**
**Әдип-галим-артист Габдулла абыйга мәдхия. Әхтәм Зарипов**
**Моңлы ядкяр. Рәдиф Сәгъди**

ИНДЕКС:
ТАТАРСТАНДА – П2343
РОССИЯДӘ – П7074
www.beznenmiras.ru

«БЕЗНЕҢ МИРАС»
журналына башкача язылу:
•uslugi.tatarstan.ru сайты ярдәмендә
• редакциядә
• podpiska.pochta.ru сайты ярдәмендә электрон версия

4 612750 670172

«БЕЗНЕҢ МИРАС» журналын башкалабыз Казандагы «Книги-Китаплар» кибетеннән (Бауман ур., 19 һәм 29/11), «ТАТМЕДИА» бинасының китап кибетеннән (Декабристлар ур., 2), республикабыз киоскларыннан сатып алырга мөмкин.